# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ТР Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер ШӘЙМИЕВ, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИН, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар СӘЛИМГӘРӘЕВ, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Шамил САДЫЙКОВ котлаулары. ........ 3-8

*Баш мөхәррир сүзе:* Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Рухи ЙӨЗебез. ........ 9

*ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР:*

Фатих ӘМИРХАН. Чәчәкләр китерегез миңа! *Нәсер*. ........ 13

Шәриф КАМАЛ. Курай тавышы. *Хикәя*. ........ 43

Гадел КУТУЙ. Тапшырылмаган хатлар. *Повестьтан өзек*. ........ 55

Әмирхан ЕНИКИ. Кем җырлады? *Хикәя*. ........ 63

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ. Бәхилләшү. *Повестьтан өзек*. ........ 92

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Йәгез, бер дога! *Роман-хатирәдән өзек*. ........ 98

Нурихан ФӘТТАХ. Тәнкыйтьче. *Сатира-юмор*. ........ 101

Марсель ГАЛИЕВ. Хыянәткә – кыямәт. *Эссе*. ........ 131

Әхәт ГАФФАР. Карачкылар. *Хикәя*. ........ 142

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Сирень чәчәге. *Хикәя*. ........ 145

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. «Сатлыкҗан». *Хикәя*. ........ 158

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Кайтаваз. *Хикәя*. ........ 183

*ШИГЪРИЯТ*. ........ 10, 40, 52, 58, 71, 86, 126, 153, 179

*ПУБЛИЦИСТИКА:* Гаяз ИСХАКЫЙ. Безнең хәлләр. ........ 16

Рәфикъ ЮНЫС. Референдум: халык «әйе» диде. ........ 151

*ТАРИХ:* Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Калын журнал. ........ 18, 76, 148

*ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ:* Галимҗан ИБРАҺИМОВ. Яңа әсәрләр. ........ 37

Хатларда – өлкәннәр сүзе *(Хатлар Рәдиф Гаташ архивыннан алынды)*. ........ 67

*ХӘТЕР:* А. Шамов, Г.Бәширов, Г.Кашшаф, Ф.Хөсни, Ә.Еники, Г.Әпсәләмов, З.Нури, А.Расих, Г.Ахунов, И.Юзеев, А.Гыйләҗев, Р.Фәйзуллин хатирәләре. ........ 103

*СӘНГАТЬ:* Туфан МИҢНУЛЛИН. «Әлдермештән Әлмәндәр». ........ 123

*«Казан утлары» минем язмышымда:* Вахит ИМАМОВ. 100 еллык әдәбият бакчасы. ........ 172

Зиннур ХӨСНИЯР. Татар утлары. ........ 174

*Шаян сәхифә:* Зөлфәт ХӘКИМ. Уйлар уйнавы... ........ 187

*Печән базары:* Камил КӘРИМОВ. Мин дә булдым... *Юмористик хикәя*. ........ 189

ЗӨЛФӘТ. Яшәр безнең журналыбыз. ........ 191

«Казан утлары» архивыннан. ........ 48,80,175

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 5 (1195) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 20.04.2022, график буенча 27.04.2022, басылып чыгу вакыты 25.04.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1187. Тираж 7896.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2022 ел



**Рөстәм**
**МИҢНЕХАНОВ,**
**Татарстан**
**Республикасы**
**Президенты**

*Хөрмәтле дуслар! Татар халкының кадерле журналы «Казан утлары»ның чыга башлавына 100 ел тулу уңаеннан аның барлык авторларын, редакция хезмәткәрләрен, әдәбият сөюче тугрылыклы укучыларын чын күңелемнән котлыйм!*

*Илебез тормышында шактый катлаулы чорда – гражданнар сугышы, Идел буендагы ачлык афәте, сәяси үзгәрешләр вакытында – 1922 елның май аенда «Безнең юл» исеме белән журналның тәүге саны дөнья күрә. Бер гасыр дәвамында төрки дөньяда, Бөтенроссия күләмендә иң абруйлы, иң өлкән басмаларның берсе булган, халкыбызның чын мәгънәсендә җан азыгы, тугры юлдашчысы һәм киңәшчесенә әверелгән, татар әдәби хәрәкәтенең әйдәп баручы рухи байрагына әйләнгән «Казан утлары»ның бүгенге көндә дә Россиядәге калын әдәби журналлар арасында иң зур тиражлы булуы, мәдәни тормышыбызда мәртәбәле урын биләве аның нигез ташларының ныклыгыннан, редакция эшендә катнашкан шәхесләрнең милләтебезгә ихластан хезмәт итүеннән килә.*

*XX гасыр башында нәшер ителгән «Әл-гасрел җәдит», «Шура», «Аң» журналларының традицияләрен саклап, аларның лаеклы дәвамчысы буларак, «Казан утлары» бүген дә мәдәниятебезнең, әдәбиятыбызның, тормышыбызның якты көзгесе сыйфатында, дөньяга сибелеп яшәгән татар укучыларына нур тарата.*

*Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси басмага хас булганча, «Казан утлары» театр, музыка, сынлы сәнгать мәсьәләләрен дә эзлекле яктырта, халкыбызның иҗтимагый-сәяси фикерен үстерүне, фән-мәдәният тарихын барлап-теркәп бару бурычын да фидакарьләрчә үтәп килә, төрле кыйтгаларга сибелгән татар халкын рухи берләштерүдә үзеннән зур өлеш кертә.*

*Кадерле дуслар! Бүгенге четерекле чорда каләм әһелләренә, редакция хезмәткәрләренә, милләт учагын күз карасыдай саклаган татар гаиләләренә – зыялы укучыларга ана телебезне киләчәк буыннарга тапшыру эшендә зур өметләр баглыйбыз. Бу юнәлештә затлы, саллы, милли журналыбыз «Казан утлары» алга таба да терәк баганаларыбызның, рухи байлыкларыбызның берсе булыр дип ышанам! Редакция хезмәткәрләренә, каләм осталарына, әдәбият сөючеләргә илһамлы бәхет, ныклы сәламәтлек телим!*



## Минтимер ШӘЙМИЕВ,
### Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе

*Без – татарлар, «Казан утлары» журналы белән чын мәгънәсендә горурлана алабыз. Чөнки безнең әдәбиятлы, китаплы, мәдәниятле, иҗатлы халык булуыбызны йөз ел буе күрсәтеп-раслап тора ул! Шушы гасыр дәвамында бу басма татарның җан азыгына, ышанычлы таянычына, тугры юлдашына, татар әдәби хәрәкәтен әйдәп баручы рухи байрагыбызга әверелде.*

*Журналның һәр санын укып барам. Романмы ул, повестьмы, шигырь, хикәяме – уңышлы әсәргә юлыксам, журнал битендә билгеләп куя торган гадәтем дә бар. Соңгы вакытта яшьләр иҗаты куандыра.*

*«Казан утлары» халкыбызның иҗтимагый-сәяси фикерен үстерү, милли үзаң, милләткә мәхәббәт һәм әдәби зәвык тәрбияләү белән беррәттән, дөньяга сибелеп яшәгән татарларны берләштерә дә. Мин аны «татар халык журналы» дип атар идем, чөнки ул каләм тибрәтү сәләтенә ия милләттәшләребез өчен һәрвакыт ачык, телебез һәм әдәбиятыбыз кадерен белүче укучылары фикеренә гел игътибарлы.*

*«Казан утлары»ның 100 еллык юбилее котлы булсын!*

*Яраткан журналыбызны хәзерге катлаулы һәм интернетлы заманда да югары кимәлдә тотучы шагыйрьләребезгә, язучыларыбызга, тел галимнәренә, әдәбият белгечләренә һәм редакция коллективына барлык укучылар исеменнән зур рәхмәт җиткерәсем килә. Журнал үзенең икенче йөз еллыгында да тирән эчтәлекле әсәрләр чыгаруын дәвам итеп, халкыбызның теле, әдәбияты, мәдәнияте, гореф-гадәтләре сагында нык торыр дип ышанам.*



**Фәрит МӨХӘММӘТШИН,**
**Татарстан Республикасы**
**Дәүләт Советы Рәисе,**
**Татарстан халыклары**
**Ассамблеясе рәисе**

*«Казан утлары» журналына – 100 ел! Бер гасыр эчендә тормышыбызда нинди генә чорлар, нинди генә иҗтимагый-сәяси вакыйгалар булып узмады?! Ни генә булмасын, «Казан утлары» һәрвакыт заман белән бергә атлады, халкыбызга хезмәт итте, фаҗигале репрессияләр һәм дәһшәтле сугыш елларында да милләтнең әдәби сүз мөнбәре, иҗтимагый фикер мәйданы, йөз аклыгы, намус көзгесе булып калды.*

*Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси басма буларак, журнал бүген дә үз миссиясенә тугры. Ул бүген дә әдәби процессның байрагы! Туган телебезне, мәдәни мирасыбызны, гореф-гадәтләребезне, әхлак кануннарын саклап калу, үстерү, татарны мәдәниятле, мәгърифәтле итү юлында авыр йөкне төпкә җигелеп тарта. Милләттәшләребезнең күңел җәүһәрләрен, рухи кыйммәтләрен барлап, халкыбызның рухын саклап тора.*

*Дөньяның төрле төбәкләренә сибелеп яшәүче татар халкын берләштерүдә дә «Казан утлары»ның роле бәяләп бетергесез. Шул ук вакытта ул төрле милләт язучылары, шул исәптән төрки кардәшләр белән әдәби-мәдәни багланышларны ныгыту максатында да нәтиҗәле эш алып бара. Илебездә гомер итүче халыклар арасында, Татарстанда гына да 173 милләт вәкиле яши, дуслык-туганлык мөнәсәбәтләре урнаштыруга, үзара хөрмәт тәрбияләүгә үзенең саллы өлешен кертә.*

*«Казан утлары»ның 100 еллык юбилее котлы булсын! Ул киләчәктә дә тарихи елъязма булып яшәвен, халкыбыз рухы сагында торуын лаеклы дәвам итсен! Журналны нәшер итүчеләргә нык сәламәтлек һәм иҗади уңышлар телим.*



**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА,**
**Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстан Язучылар берлеге рәисе**

*XX гасырның егерменче елларыннан соң татар әдәбиятының елъязмасы турыдан-туры «Казан утлары» журналы белән бәйле. Төрле елларда төрле исемнәр белән чыкса да, ул татар язучыларының төп журналы булып кала бирә. Татарстан Язучылар берлеге оешкач, журнал аның җитәкчелегендә чыга башлый. Бу табигый да, әдәби процесс басма сүзсез була алмый. Егерме беренче гасырның башында булган үзгәрешләрдән соң журнал Язучылар берлеге органы булудан туктаса да, әлеге бергәлек бүген дә дәвам итә, хәзерге язучыларның иң яхшы әсәрләре «Казан утлары» журналында дөнья күрә.*

*Һәр татар язучысының иҗади биографиясе яраткан журналыбызга барып тоташа. Әсәренең «Казан утлары» битләрендә дөнья күрүе һәр каләм иясе өчен мәртәбә! Хәзерге татар әдәбиятының нинди сыйфатта булуын, ни рәвештә үсүен, үзгәрүен без журналны укып беләбез. Шуңа күрә дә әлеге басмада эшләүче мөхәррирләрнең эше бик җаваплы. Шөкер, татар телендә әдәби әсәрләр әле күп языла, сайлау мөмкинлеге бар. Сүземә дәлил итеп, Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән әдәби ярышны искә төшерәсем килә. Анда мең ярым әсәр катнашты, арада унбиш роман булуы да – зур горурлык. Ярышта җиңүче әсәрләрнең күбесе, әлбәттә, «Казан утлары» журналында нәшер ителәчәк. Укучыбыз аларның кимәлен үзе бәяләр.*

*Соңгы елларда журналның укучылары да сизелерлек артты. Бу шулай ук чыккан әсәрләрнең сыйфаты белән дә бәйле дип ышанасым килә. Һәр нәрсәне чагыштырып кына бәяләп була. Журналның электрон архивын булдыру да моңа нык ярдәм итә, татар әдәбиятының гына түгел, татар мәдәниятенең дә нинди юлдан баруын ачыклау мөмкинлеге туа.*

*Бер гасырлык гомерендә журнал төрле сынаулар аша үтте. Шактый еллар хакимлек иткән ялган идеология сөреме дә журнал сәхифәләренә җитәрлек сеңгән. Ләкин әдәби сүз, сурәтле тел барыбер өстен калган. Бүген дә журнал шул югарылыкка омтыла. Шик юк ки, барыбыз бергә хәзерге кыенлыкларны да җиңеп чыгарбыз, «Казан утлары»ның балкышы киләчәк буыннарның да иманлы күзен нурландырыр!*



## Айдар СӘЛИМГӘРӘЕВ,
### «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе

*«Казан утлары» журналы – тарихы зур, мирасы бай, әдәби-мәдәни, рухи йөге саллы, заман үзгәрешләренә сизгер булган иң абруйлы басмаларның берсе. 100 ел буена халкыбызга милли әдәбиятыбызның асыл җәүһәрләрен ирештереп торган, әхлакый тәрбия, җәмгыяви белем бирү, иҗтимагый фикер уяту кебек авыр, мактаулы, игелекле миссия башкарган «Казан утлары» бүген дә республикабызның медиакырында тотрыклы урын алып тора. Аның бүген дә даими укучысы, көтеп ала торган дуслары бар.*

*Шунысын да әйтергә кирәк, каләм әһелләренең иҗатын стимуллаштыру максатында соңгы елларда журнал редакциясе республика министрлыклары, ведомстволары, акционерлык җәмгыятьләре, иҗтимагый оешмалар белән берлектә әдәби конкурслар үткәрә, үзе дә Россия, Татарстан күләмендә узган иҗат бәйгеләрендә актив катнаша, дәүләт грантлары системасы мөмкинлекләреннән нәтиҗәле файдалана.*

*Хөрмәтле хезмәттәшләр!*

*Бәйрәмебез котлы булсын! Сезгә сәламәтлек, тынычлык, илһам, иҗат уңышлары, «Казан утлары»ның киләчәктә дә дәрәҗәле, саллы басма, халкыбызның тарихи елъязмасы булып калуын телим!*



## Шамил САДЫЙКОВ,
### «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры

*Безнең республикабызда татар телендә дөнья күргән һәр матбугат чарасының үз йөзе, үз юлы, үз тарихы, үз укучысы бар. Шулар арасында «Казан утлары» журналы аерым урын алып тора. Әлеге басмада һәрвакыт халкыбызның күренекле шәхесләре эшләде, аның авторлары да татар милләтенең сөекле ул-кызлары – танылган шагыйрьләр, прозаиклар, драматурглар, әдәбият тәнкыйтьчеләре, галимнәр булды. Шуңа күрә «Казан утлары»н без, һичшиксез, ана телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап, татар халкының киләчәге өчен борчылып яшәүчеләрне үзенә җыеп, туплап торган милли утрауларыбызның, терәк баганаларыбызның берсе дип әйтә алабыз.*

*Традицияләргә тугры калган хәлдә, редакция бүгенге заман шартларына да җайлаша алды. Хәзерге «Казан утлары» – мультимедияле редакция. Ул традицион рәвештә, йөз ел элек билгеләнгән кыйбласына тугры калып, әдәбият сөючеләргә кәгазь форматта барып ирешә. Россиядәге әдәби журналлар арасында иң зур тиражларның берсе белән чыккан журнал илнең утызга якын төбәгенә тарала. Сайт һәм социаль челтәрләр эшчәнлеге дә югары дәрәҗәдә куелган, караучылар арасында чит илләрдәге һәм төбәкләрдәге милләттәшләребезнең өлеше зур булу «Казан утлары» яктысының дөньяны иңләве турында сөйли. Редакциянең үз китапханәсе сериясен булдырып, ай саен кесә китаплары бастырып чыгаруы һәм һәр елны әдәби конкурслар уздыруы – киләчәкне күздә тотып, заман таләпләренә җавап биргән гамәлләр.*

*«Казан утлары» журналының киләчәге нурлы булсын, аннан таралган яктылык алга таба да милләтебезнең барыр юлын яктыртып торсын!*

*Баш мөхәррир сүзе*

# Рухи йөзебез



*...Киткән аның очы әллә кая*
*Шактый ерак, байтак, озын юл...*

*Бер гасыр элек журналыбызның тәүге санында дөнья күргән Зәйнәп Бәшированың «Безнең юл» шигырендәге әлеге юллар, әйтерсең лә, басмабызның озын гомерле, катлаулы-гыйбрәтле, шанлы-шөһрәтле булачагын алдан күреп язылган. Шөкер, йөзьяшәр журналыбыз иң беренче саннарыннан татар халкының газиз баласыдай көтеп алынган, һәм ул бүген дә милләтебезнең рухи йөзе булып тора.*

*Редакция, нинди генә чорлар кичсә дә, кайсы гына вазгыятьтә дә халкыбыз алдындагы олы вазифасын, зур җаваплылыкны тоеп эш иткән. Совет әдәбиятының яңа тәпи атлап киткән чоры булсынмы, үзгәрешләр вакыты, туксанынчы еллар күтәрелешеме – журнал һәрвакыт элгәреләребезнең ак максатын хаклап яши. Гомумән алганда, бүген дә, киләчәктә дә «Казан утлары»ның мөхәррирләре, баш мөхәррирләре, гамәли хезмәткәрләре басмабызны алга таба яшәтү, сыйфатын яхшырту уңаеннан нинди генә ысуллар, алымнар куллансалар да, редакциянең иң төп казанышы – журналның калыплашкан традициясен саклау, ныклы нигез ташларын җимермәү, шул ук вакытта заман белән бергә атлау булып калачак.*

*Укучыга югары сәнгать дәрәҗәсендә язылган камил әсәрләр тәкъдим итү, каләм язган сүзнең җәмгыять тормышында дәрәҗәсен, язучыларның социаль активлыгын күтәрү, әдәби процессны, аның үсеш тенденцияләрен ачыклау, традицияләрне үстерү, иҗат әһелләрен мөкатдәс идеяләр тирәсендә туплау – болар басмабызның төп бурычлары. Әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал буларак, аңа халкыбызның иҗтимагый фикерен үстерү, иманын, рухын, әхлагын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау да йөкләнгән.*

*Журналыбызның тәүге санын нинди күтәренкелек белән каршы алган булсалар, 100 еллык юбилейны да шундый ук зур өмет, якты хыял белән көтеп алабыз. Шөкер, бер гасыр дәвамында, нинди генә давылларга тарыса да, «Казан утлары» җилкәнен һәрчак туры тотты, үз юлыннан тайпылмады. Киләчәктә дә шулай булыр, иншалла! Үзебездә шундый ышаныч тоя алганыбыз өчен без халкыбызның талантлы каләм ияләренә, редакциядә эшләгән элгәреләребезгә, тугрылыклы укучыларыбызга, басмабызга һәрчак игътибарлы җитәкчеләргә рәхмәт әйтәбез!*

*«Казан утлары»ның балкышы күңелләребезне гел яктыртып, җылытып, киң юлы алга дәшеп, чакырып торсын!*

**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН**

# Габдулла Тукай

## Мөхәрриргә*

*(Кыйтга)*

И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа[1]!
И мосаувир[2]! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!
Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!
Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилях[3],
Сәүдәгәрлектер зыялылык[4] вә сәүдәдер зыя[5].
Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.
Алты ел торды чупансыз[6], айрылышты яшь көтү;
Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.
«Ул Гомәрдән курка шәйтаннар» диган төсле рәсүл,
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя…

# Дәрдемәнд

## Без

Гасырлар кичте китте... кичте еллар!
Нәбиләр[7], падишаһлар, сөрде дәвран[8]...
Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,
Килеп кичте җиһандан канча илләр!..
Сүнеп, вәйран булып[9] мәгъмур[10] тиякләр,
Җир астында тезелде ку[11] сөякләр!..
Исә җилләр, күчә комлар... бетә эз...
Дәрийгъ[12], мәхзүн[13] күңел, без дә бетәбез!

---

[1] Кибриа – олылык, дан.
[2] Мосаувир – сурәт ясаучы, сүз остасы, художник.
[3] Лөгать, истилях – сүзләр, атамалар.
[4] Зыялылык – интеллигентлык.
[5] Зыя – яктылык, аң-белем.
[6] Чупан (чабан) – көтүче, җитәкче.
[7] Нәби – пәйгамбәр.
[8] Дәвран (дәверан) – гомер, чор.
[9] Вәйран булу – җимерелү, харабә хәленә килү.
[10] Мәгъмур – төзек.
[11] Ку – кипкән, коры-буш.
[12] Дәрийгъ (дәригъ) – үкенеч.
[13] Мәхзүн – аянычлы, кайгылы.

---

* Ред. иск: Тукайның вафатына 23 көн кала язылган соңгы шигырьләренең берсе. Ул Г.Исхакыйны күз уңында тотып язылган.

Мөсафир, кем, җиһанга басты ботны,
Биетте ажгырып аны замана...
Өеп чергән өмидне... төртте утны –
Йотып утларны китте... яна-яна...

# Сәгыйть Рәмиев

## Пәйгамбәр

Эчемнән ут янып торган чагымда
Күрәм: Җибрил була пәйда янымда...
Күземне бер йокы баскан шикелле
Булам, бугълам үзем, шашкан шикелле.
Тоям: Җибрил яра күңлем ярасын,
Яра да рух сала, алгач карасын.
«Пәйгамбәр син!» ди дә шунда китә ул
Очып күккә, миңа күргәзә дә юл.

Калам, тетрәп ятам, мин хәл җыйганда
Килә күктән аваз, тетри җиһан да:
«Курыкма, тор, алып хикмәт кылычын,
Тагып билгә баһадирлар кынысын,
Биреп күкрәк ачуга бар, сугыш ач,
Бөтен җиргә мәхәббәт орлыгын сач!
Корыт җирдән языкның кортларын син,
Очыр җилгә аларның йортларын син,
Йөре, әйлән бөтен җирне, сулар кич,
Кеше адлы еланнар калмасын һич!» –
Ди дә күктән аваз, сикереп торамын,
Китеп, бер тау башында утырамын;

Бизәм шунда тәмам чын-чын күңелдән
Бу дөньяның бөтен җир һәм күгеннән.

# Сәгыйть Сүнчәләй

## Яшә!*

Көл – көлалсаң, янма юкка, шат яшә – шат булса җан,
Ал бәхеттән тәм, рәхәтлән, качма якты дөньядан!
Иң кадерле чак – хәзерге хәл! Сөялсаң – сөй, яшә,
Тор – гөлең шиңмәс борын. Әйдә, гомердән файдалан!

Каршыла сөйнеп ни бар рәхмәтне – иңсә Тәңредән!
Мәңге күзлек аркылы бак дөньяга – төшмә түбән!
Нинди эштән булса да, күңлең җуансын – үлмәсен!
Гел исер хезмәт белән, дустлар белән, ямь-тәм белән!

Яшь түгәргә көч кирәкми, гел җылау, әрнү – һөнәр
дип саналмый. Яшь гомер тормас терәлеп, ул үтәр!

* Ред. иск.: Әлеге шигырь «Совет әдәбияты» журналының 1946 елгы 4 нче санында Габдулла Тукай әсәре буларак басылган. Әмма соңгы дәвердә әдәбият галиме Зөфәр Рәмиев аның Сәгыйть Сүнчәләй шигыре булуын исбатлады. Ул әүвәл 1912 елда «Йолдыз» газетасында дөнья күргән.

Җәйге ямьнәр, җәйге нурлар бар чагында бик рәхәт!
Җәй – гомер, ул тиз үтәр, салкын, газаплы көз җитәр.

Сөй гөмерне, сөй халыкны, сөй Ходаның дөньясын!
Без үләрбез, билгеле. Тик үкенечкә булмасын!
Киң күңелле бул! Чыда мыскыл ишетсәң – «вак!» диген!
Таптасыннар, хурласыннар! Тик җаның хурланмасын!

# Мәҗит Гафури

## Үзем һәм халкым

Бер адым алга басам да
Әйләнәм мин артыма.
Кайда басканнар икән дип,
Күз саламын халкыма.

Шул вакыт мин бик югары
Кош кебек очсам әгәр.
Ә алар һаман шулай
Баскан урында торсалар...

# Шәехзадә Бабич

***

Мәңге сүнмәс, ахры, бу җәһәннәм,
Һаман янар, һаман кыздырыр...
Газиз илең синең, әй, каһарман,
Һаман ауыр көнләр уздырыр!..

Һич кайгырма, шатлан әүвәлгечә!
Бәхет йитәр әле, иншалла;
Җәһәннәмләр аша узмаенча,
Оҗмах табарбыз дип ышанма...

# Нәҗип Думави

## Үтте, үтә...

Аһ-ваһ килеп, кайгы илә сүзгә башлап,
Эчемнән хәсәдләрнең барын ташлап,
Язарга каләм алсам хакыйкатьне, –
Ничек тә лязем була гаеп ачмак.
Гаепне ачар булсаң, хәзер бездә
Тиештер ватаныңнан ерак качмак;

Юк исә башың бетте, үзеңне тиз
Ясарлар төбе төшкән агач башмак!
Гомерләр коштай очып узып бара,
Артыннан кара туфрак чыгып кала;
Белемсез: ахырлары ни булачак,
Хәзергә түзәлмаслык йөрәк яна!..

Фатих
Әмирхан

# ЧӘЧӘКЛӘР КИТЕРЕГЕЗ МИҢА!

НӘСЕР

*Гражданнар сугышын галәбәле[1] тәмам итеп, хезмәт мәйданына кайта торган иптәшләргә багышлана.*

Ләтыйф төсләр, хуш исләр... Табигатьнең шулардан гүзәл тезеп барлыкка китергән шигъриятен үз алдымда күрергә, хис итәргә телим мин: китерегез миңа чәчәкләр!

Язгы сәрен янгырлардан соң күк йөзендә чыккан салават күперендәге нәзек төсләрнең барысы да ул чәчәкләрнең яңа ачылган гүзәл телкәйләрендә, ләтыйф барлыкларында шәүләләнсеннәр; табигатьтә булуы мөмкин хуш исләрнең барысы да ул чәчәкләрдән аңкып торсыннар да бөтен хуш исләр шигъриятен гәүдәләндерсеннәр.

Сүзләрдән, төсләрдән, музыка нәгъмәләреннән[2] шигърияләр гәүдәләндермәсмени? Китерегез миңа хуш исле чәчәкләр! Чәчәкләр китерегез миңа!

Аларның бөреләре миңа каршы елмайсыннар да эчләрендәге ал-зәңгәр-кызыл-сары-күгелҗем-миләүшәләрнең барысын берьюлы эченә алган төсләрен күрсәтеп куйсыннар; аларнын ләтыйф тулып җиткәннәре үзләренең гаҗәеп йөзләре белән миңа каршы шат көлсеннәр дә хуш исләрдән каһкаһәләрен[3] миңа үткен тойдырсыннар. Яңа ачылып килә торган ул бөреләр миңа яшьлегемнең алтын хыяллар белән мәңге исерек үткән мазыйларын[4] хәтерләтсеннәр. Ачылып җиткән ул көләч чәчәкләр миңа бөреләрен ача алмый шиңгән яшьлегемнең гыйвазы[5] булсыннар.

Миңа чәчәкләр китерегез! Мин аларны үземнең каләмнәрем, язылып бетмәгән һәм бетмәячәк дәфтәрләрем тирәсенә тезәрем. Мин аларны бөтен тирә-ягыма сибәрем, төсләре белән шагыйранә тәртипсез бер салават күпере, исләре белән хыялый-шигъри бер хуш ис диңгезе вөҗүткә[6] китерерлек итеп сибәрем: күзләр, шаммәләр[7] ирексез аларга омтылалар!

Китерегез, китерегез миңа чәчәкләр! Аларның гаҗәеп исләре мине исертсеннәр; мине, исерткечләр эчеп тә гомеремдә бер теләгәнчә исерә

[1] Җиңүле.
[2] Музыка парчалары – Ф. Ә.
[3] Кычкырып көлүләрен.
[4] Узган заманнарын.
[5] Яшьлегем урынына тора торган – Ф. Ә.
[6] Барлыкка.
[7] Ис сизү әгъзасы – Ф. Ә.

алмаган, гыйшык, мәхәббәт көннәрендә дә лаякыл исерек булмаган мине исертсеннәр, мәст итсеннәр[8]. Аларның шатлыклы көләч төсләре минем мәңге карарсыз, мәңге эзләнә, ләкин нәрсәсендер мәңге таба алмый торган күзләремне үзләрендә карарландырсыннар; мәңге пошына, мәңге офыкларның аргы якларына омтылып та, омтылганнарына ирешә алмый торган йөрәгемнең хәсрәтле карарсызлыгына шигъри бер сәкинә[9] бирсеннәр, шул пошынуымны хуш исләрдә шагыйранә коендырсыннар!

Энҗе чәчәкләр китерегез миңа! Алар яшь кызның муәффәкыятьсез беренче гыйшыктан тамган күз яшьләре шикелле саф булсыннар, алар сөт тамчыларыдай тамып-тамып торсыннар. Аклыклары белән күзләрне чагылдырсыннар. Яшьлегемнең алсу таңында, әле егетлек тормышын ярым өн, ярым төш рәвешендә, керфекләре йомылган күзләремнең эчендәге нәсими[10] буларак кына торып уздырган чагымда, мин аларны төшләремдә күрә идем. Алар ул вакытта хәзерге шикелле ап-ак кына түгелләр иде; аларның аклыгы өстендә энҗеләр өстендәге шикелле сып-сыек зәңгәрсу вә ул шәүлә эчендә алсу дулкыннар йөгергән була иде.

Китерегез миңа энҗе чәчәкләр! Мин шул бәхетле көннәремнең шигъри төшләрен исемә төшерермен. Миңа энҗе чәчәкләр китерегез! Аларның газаплы исертүчән салкынчарак исләре минем тирә-ягымны аңкытсын, бәлки, шул газаплы ләтыйф истә мин бәхет мөмкин булып та бәхетсез уздырган яшьлегемнең назирасын[11] табармын!

Ясмин чәчәкләре, резедалар китерегез миңа! Кайчандыр боларның исләре мине киң, йомшак-үткен, аксыл-алсу дулкыннар булып чолгыйлар да бөтен барлыгыма үтәләр, әллә кайларга, офыкларның аргы якларына, күгелҗем, алсу җиңел болытларның өске якларына тартып өндәп, кызыктырып торалар иде. Беренче мәхәббәт миңа резедалар хуш исенә төренеп килгән иде – сирпегез минем тирәмдә резедалар хуш исен! Беренче мәхәббәтнең ләззәтле пошыну, шигъри хәсрәт һәм хыялый бәхеттән гыйбрәт беренче сагышы миңа ясмин чәчәкләренең хуш исле дулкыннары өстендә килгән иде. Китерегез миңа ясмин чәчәкләре, китерегез миңа резедалар! Аларның гакылдан шашкан гашыйк серенадасы шикелле йомшак һәм хыялый җәелә торган исләре миндә түзәлмәслек бер теләк, бәхет, гыйшык теләге тудырсыннар! Сез беләсезме, музыка нәгъмәләре белән чәчәкләр хуш исләре арасында гаҗәеп бер тәнасеп[12] бар бит!

Миңа гөл чәчәкләре китерегез! Шагыйранә мәһабәт Кавказ тауларының итәкләрендә үскән чәчәкләр булсыннар. Аларның ак, саргылт, ал, кара, зәңгәр һәм ялкын төсендәгеләрен мин кызыл чәчәкләрем белән аралыштырып тезәрмен, мин аларның, тереклекнең беренче шатлыгыннан елмайган яшь бала йөзе шикелле, куаныч тулы йөзләренә сәгатьләр буенча өзлексез карап торырмын. Китерегез мина гөл чәчәкләр! Аларның ләтыйф аңкуларында, аларның шаммәләрне сыйпап, иркәләп чолгый торган исләрендә гаҗәп бер тынычлык, җанны ял иттерә торган рәхәт тынычлык бар бит. Туфаннар, зилзиләләр, күк күкрәүләр, яшен яшьнәүләр белән үткәрелгән яшьлектән соң мин һәр нәрсәләрдән артык, гел чәчәкләр исендәге тынычлыкка мохтаж.

[8] Бик каты исертсеннәр.
[9] Тынычлык.
[10] Эфирный – Ф. Ә.
[11] Охшашын – Ф. Ә.
[12] Бәйләнеш.

Китерегез мина гөл чәчәкләр! Мин аларның хуш исләре дулкыннарында, тәфәккергә[13] чумып тирбәнермен!

Гарлем[14] кырларын каплап үсә торган гаҗәеп кыяфәтле лаләләр нәселләр чолганышыннан дөньяга чыккан йөзләрчә төрле тюльпаннарның матурлыкларын миңа хикәя итәләр. Китерегез миңа гөл чәчәкләр! Мин аларны күз алдымда җәелгән киң кырларга сибәрмен, шул кырларда мин аларны назлап, иркәләп үстерермен. Минем гөл чәчәк кырым Гарлемның гасырлар буенча килгән нәфасәт шөһрәтен күләгәдә калдырыр. Минем гөл чәчәк кырымнан таралган хуш ис бөтен арган, талганнарга шагыйранә ял бирер!

– А, ишетсәгез лә, китерегез, китерегез миңа чәчәкләр!

*1921 ел.*

[13] Уйга.
[14] Бөтен Европага иң нәфис чәчәкләр үстереп тора торган кечкенә бер шәһәр.

## *Безне котлыйлар*



**Әкбәр ГОШАЛЫ,**
Азәрбайҗанның халык шагыйре, Азәрбайҗан Республикасы Милли Мәҗлесе мәдәният комитеты әгъзасы, халыкара Алаш премиясе иясе

*Хөрмәтле «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре!*

*Нигез ташларын татар халкының күренекле язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов салган әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси «Казан утлары» журналының чыга башлавына бер гасыр – 100 ел гомер узып киткән. Журнал бу чорда Татарстан һәм Азәрбайҗан язучылары арасында элемтәләрне ныгыту, аларның әсәрләре аша халыкларыбыз арасында ныклы бәйләнешләр урнаштыру буенча гаять зур эш башкарган басма. Без аның авыр сугыш елларында да тукталмыйча чыгып баруын, тыл хезмәтчәннәрен совет солдатларының фронтлардагы тиңдәшсез батырлыклары хакында татар язучыларының язмалары, шигырь-хикәяләре белән таныштырып баруын, җиңүгә рухландырып торуын яхшы беләбез. Сугыштан соңгы еллардан бүгенге көннәргә хәтле «Казан утлары» әдәбият сөючеләр өчен кадерле, көтеп алган журнал булды. Аның битләрендә кардәш төрки әдәбиятлар, шул исәптән азәрбайҗан язучыларының әсәрләре дә даими басылып килә.*

*Хөрмәтле каләмдәшләр! Сезне олуг юбилеегыз белән кайнар котлыйбыз! Журналның әле тагын татар халкының милли рухын саклап, озак гомерләр дөнья күрүен, аны бүген нәшер итүче каләмдәшләребезнең сау-сәламәт булуын, кардәш төрки-татар халкының Җирдә мәңге яшәвен телибез!*

Гаяз Исхакый

# БЕЗНЕҢ ХӘЛЛӘР*

Тарих көпчәгенең әйләнүе алдымызда нинди генә мәсьәлә ачмасын, тормышымызның барышы алдымызда нинди генә милли, дини, мәдәни сөальләр куймасын, һәммәсенең дә җавабы бер замиргә[1] кайта. Һәммәсенең дә милли бертөсле булып каплана.

Матбугатымыз, халкымыз алдында җәмгыятьләр съезды ясау мәсьәләсе килеп басты. Матбугат язды, халык укыды. Гакыллы башлар гакыл сатты. Шуннан соң һәммәсе дә үзенең вазифасын үтәде кебек хис итте дә башка эшкә тотынды. Матбугатка яңгы мәсьәләләр туды, укучыга яңгы сүзләр табылды, фәлсәфә сатып, сагыз чәйнәп йөрүчеләргә яңгы фаразлар башка килде. Җәмгыятьләрнең ясаган комитеты да зур лазарет ясарга карар чыгарды.

Шул озын хезмәттән соң бар да арыды да хәл җыярга тотынды. Татар тарихы тагы кечкенә генә иттереп, көпчәген селкетте. Тагы берәр дини мәсьәлә – казыйлык мәсьәләсе туды. Тагы язылды, тагы укылды, тагы сөйләнде, тагы тыныш куелды, тагы «хәл җыю» башланды…

Татар тарихының тагы бер бите ачылды, канлы күз яшьле бер мәнзарә күренде. Русиянең бер читендәге туганнарымыз, кардәшләремез, диндәшләремез ач-ялангач, йортсыз-йирсез, мәзлум көенчә күз алдымызга басты. Тагы язарга керештек, тагы сөйләргә тотындык, тагы фәлсәфә чәйнәшергә башладык. Менә озакламас тагы шул куркынычлы мәнзарәне онытырмыз, тагы яңгы бер мәсьәлә туганча хәл җыярмыз. Тагы яңгы эш килеп чыккач та, «менә шул инде иң әһәмиятле мәсьәлә» дигән кебек каршы алырмыз. Тагы сагыз чәйнәрмез-чәйнәрмез дә, эчемез пошар да, туярмыз да ташлармыз. Тагы яңгы мәсьәләне, яңгы бер эшне күтәргә тотынырмыз. Тагы аңгарга ябырылып, бөтен көчемез, куәтемез берлән ябышырмыз да тагы ашап туйган үрдәк кебек яныннан борылып китәрмез. «Җәмгыяте хәйрия»ләр киңәшенең юлда калуы, казыйлык мәсьәләсенең бер нәтиҗәгә ирешмәенчә туктавы**, Карс мөселманнары хәленең бертөрле адәм гакыллы юлга куела алмавы*** – болар барысы да иттифакый гына бер эшләр түгел. Мәгаттәәссеф, болар менә шулай тугры килгәндә, менә шулай уңмаенча калган гына түгел. Болар – безнең бөтен эшемез, бөтен хәлемезнең килеше барышыннан туган табигый бетешләремез, бөтен уемыз, бөтен төшенчәмез, бөтен мантыйкымызның тудырган нәтиҗәләре, бөтен тирә-юнемездәге эшләремез, кыланышларымызның үстергән йимешләре. Шуның өчен бу бәхетсезлекләрдә, бер тарафтан караганда, беркем дә гаепле түгел. Җәмәгать хадиме булган кеше гаепле түгел, чөнки аның мохите тиен кебек – бер агач башыннан икенче агач башына сикереп йөри торган иттереп тәрбия иткән; матбугат гаепле түгел, чөнки аны укучылар көннән-көн яңгы мәсьәләләр чыгарып торырга, яңгы ласкутлар сатарга мәҗбүр иткән, иске сагызны әле авызның бер ягына, әле бер ягына әйләндереп чәйнәргә өйрәнгән.

Укучы, уйлаучы, әфкяре гомумия гаепле түгел, чөнки аны милләт хадимнәремез, матбугатымыз эшкә җитди иттереп, эш итеп карарга өйрәтмәгән. Ул укучы алдында хәлфә, йитәкче була алмаган гына түгел, ул аның кәефен китәрер өчен, аның хөббе нәфесен[2] кытыклар өчен клоунлык вазифасын иткән…

---

[1] Замиргә – нәрсәгә.
[2] Хөббе нәфес – мин-минлек.

Беркемдә, бернидә гаеп юк. Һәммәсе үз урынында, үз вазифасында.

Икенче яктан караганда, һәммәсе гаепле: җәмәгать хадимнәре, матбугат, әфкяре гомумия, халык – һәммәсе гаепле һәм дә һичбер төрле кичерерлек түгел дәрәҗәдә гаепле. Җәмәгать хадимнәре үзләре үзләренең дәрәҗәләрен белмәгән өчен, үзләренең халык алдына куя торган мәсьәләләрен җитди иттереп аңлап бетмәенчә, үзләренең нишләргә теләгәннәрен күреп җитмәенчә эш башлаганнары өчен, үзләренең кая таба бара торган, кайдан килә торган юлларын белмәгән өчен гаепле. Үзләренең иптәшләре, юлдашлары кемнәр икәнен аера алмаган өчен уңга, сулга борылганда, чикләре кая икәнен кистерә алмаган өчен, үзләренең дөрест дигәннәрендә нык торырлык иманнары булмаган өчен гаепле. Алар мәсләкләре юклыкта гаепле. Матбугат үзенең вазифасы йитәкче булуда икәнен белмәгән өчен, үзенең бурычы халыкның алдыннан мәдәният нуры күрсәтеп бару икәнен белмәгән өчен, үзенең бурычы җил кайдан килсә, шунда аумаенча, туп-тугры иттереп алган кыйбланамәсе берлән бармаган өчен гаепле. Үзенең гайбәтче карчык түгел икәнен аңламаенча, үзенең эшсезләрне җуатыр өчен уенчык түгел икәнен аңламавы өчен гаепле, төпсезлектә, мәсләксезлектә гаепле.

Әфкяре гомумия үзенең бурычы җәмәгать хадимнәренең вә матбугатның алып бара торган эшендә койрык булып, аны боручы икәнен белмәүдә, яхшы берлән начарны, файдалы берлән зарарлыны аерырлык дәрәҗәгә җитмәүдә гаепле.

Әфкяре гомумия шарлатан берлән чын хезмәтчене, лыгырдау берлән чын сүзне, җил иләү берлән чын эшне аермауда гаепле.

Халык шул эшләргә тамга сала белмәүдә үзенең вөҗдан тавышын шул кешеләргә тәэсир иттерә алмауда гаепле.

Менә шуның өчен, менә шул бөтен иҗтимагый, мәдәни, милли, дини гамилләремез һәммәсе дә зәһәрләнгән өчен, без, нинди генә эш башласак та, очлый алмыймыз. Нинди генә фикерне мәйданга суксак та, аның бисмиллясыннан үтә алмыймыз. Нинди генә план корсак та, шуның нигезен корыр өчен иске бинаны ватудан уза алмыймыз. Һәм дә уза да алмаячакмыз… Шуның өчен киләчәктә тарих көпчәкләре әйләнгәндә тагы шул лыгырдап калмас өчен, тагы шул тиен кебек бер мәсьәләдән сикереп, икенчесенә кунып йөремәс өчен бөтен мәдәни, милли хәрәкәтнең үзәген пакьләргә, сафларга тиештер.

Бөтен мәдәни эшләремезнең нигезен үзгәртеп, төплелек, җитдилек, мәсләклелек ташларына бинаны куярга тиештер. Һәм дә һичбер вакыт әрәм итмәенчә эшләргә тиештер. Юл бер генәдер. Юл шул гынадыр. Шуннан башка юл да юктыр. Шуннан башка эш тә мөмкин түгелдер. Шуның өчен тарихның зур имтиханнары алдында торганымызны хәтерләп, тарихның алдында бер милләт булып яшәргә хакымыз бармы-юкмы, имтиханына керергә вакыт җитәчәген уйлап, тәһарәткә керешергә тиештер. Тәяммем берлән башларга ярамаганын белеп, алдан тәһарәтләнергә, казасы, кәффарәте булмаячагын аңлап, вакытында акланырга, пакьләнергә тиештер.

---

**Искәрмәләр һәм аңлатмалар:**

* Безнең хәлләр (Тарих көпчәгенең әйләнүе…). «Ил» газетасының 1915 елгы 6 февраль (70 нче) санында «Гаяз» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

** …казыйлык мәсьәләсенең бер нәтиҗәгә ирешмәенчә туктавы… – казый булып, Благовещенск имамы Салихҗан Урманов сайлап куелуны Гаяз Исхакый хупламаган булса кирәк. («Казыйлык мәсьәләсе» исемле мәкаләгә язылган аңлатма һәм искәрмәләрне карагыз.)

*** …Карс мөселманнары хәленең бертөрле адәм гакыллы юлга куела алмавы… – Россиянең төрле җирләрендә халыктан, аерым алганда мөселманнардан, акча җыю, җибәрү кебек гамәлләр ясалса да (берара «Ил» газетасының үзендә дә кемнең, кайда күпме акча тапшыруы турында хәбәрләр дә басылган. Мәсәлән, Мәскәүдән Хөсәен Ширинский – 25 сум, Габдулла Такташев – 20 сум, Сафа Виргазов – 2 сум. Шакир Акбулатов, Габдулла Йунысов, Кәрим Әхмәдуллиннар берәр сум биргәннәр.), бу эш киң масштабта алып барылмаган, билгеле.

# КАЛЫН ЖУРНАЛ

## «Казан утлары» – татар мәдәниятенең асылташы

«Казан утлары» журналы тарихы – вакытлы матбугатның бер басмасы тарихы гына түгел! Татар телендә өзлексез 100 елдан артык нәшер ителеп килгән әдәби «калын журнал» буларак, ул халыкның иҗади фикерләвен, әдәби барышны җитәкләп барган, әдәбият ярдәмендә милли үзаң ныгуны, татарларның берләшүен-бердәмлеген тәэмин иткән, тормыш-яшәешкә, үткәнгә-хәзергегә һәм киләчәккә карашларны формалаштырган. Шулай итеп, бер милләт өчен юл салучы, юнәлеш билгеләүче рухи маяк хезмәтен башкарып килгән һәм бүген дә Казанның шушы яктылыкны, җылылыкны таратучы «уты-учагы» булып кала.

Гомумән, Россия мәдәни мәйданында «калын журнал» атамасы, Михаил Булгаковның «җиңел кулыннан», әдәби, калын-күләмле даими чыгып килүче басмаларга карата гына кулланыла! Аның төп билгеләреннән берсе – әдәби-иҗади процессны, иҗтимагый-мәдәни фикерне әйдәп бару дип күзаллана. Эдвард Радзинскийның мондый басмага биргән сыйфатламасындагы аның зыялыларга адреслануын, элитар журнал хисаплануын; монда идея-эстетик яктан зур кыйммәткә ия булган текстларның гына басылып чыга алуын күрсәтүен, әгәр ниндидер язма цензура тарафыннан тоткарланып ята икән, аның бәһасе күп тапкырлар күтәрелә, дигән сүзләрен (*https://info.wikireading.ru/16053https://info.wikireading.ru/16053*) Россиядә теләсә кайсы чорда, теләсә кайсы телдә нәшер ителгән «калын журнал»га карата кабатларга мөмкин.

Татар зыялылары өчен ул, моннан тыш, милләтне үстерүне, шуның күрсәткече булган – әдәбиятның актив күтәрелешен тәэмин итәргә тиешле мөһим бер шарт булып тоела. Равил Әмирхановның: «Татар телендә вакытлы матбугат тусын өчен 100 елга якын (1808 елдан башлап) көрәш бара» (*Амирханов Р. Татарская дореволюционная пресса (в контексте «Восток – Запад» (на примере развития русской культуры). Казань: Татар.кн.изд-во, 2002. Б.34*) дигән сүзләре мондый басма булдыру өчен әзерлекнең 200 елдан да элгәрерәк башланып китүе турында сөйлиләр.

## Татар телендә журнал чыгару өчен көрәш

Мәгърифәтчелек хәрәкәтен кузгатып җибәргән, милләт булып оешу юлына чыккан татар җәмгыятендә әлеге хәрәкәтне җитәкләп, әйдәп баручы зыялылар берничә иң мөһим максатны билгелиләр. Шуларның берсе – татар вакытлы матбугатын булдыру, бигрәк тә «калын журнал» – киләчәккә мәдәни үсеш юлларын билгеләрлек әдәби журнал чыгару була. Чөнки күз алдында – рус дөньясы, андагы беренче әдәби журналлар – «Вестник Европы», «Русское богатство», «Отечественные записки», «Современник», «Русская мысль»; рус зыялылары арасында чын мәгънәсендә «журнал культы» хөкем сөрә. Казанның үзендә дә рус телендә «Казанский вестник» (1821 елдан), «Заволжский муравей» (1832 елдан) кебек журналлар нәшер ителә. Әлеге басмалар, мәгълүмат чыганагы булудан бигрәк, хөр иҗади фикер әйтү урынына әверелгәнне аңлаган татарларның да шундый мәйдан булдырырга омтылуы гаҗәп түгел!

Әлеге омтылышны җентекләп күзәтеп, Р.Г. Әмирханов 1905 елга кадәр татарлар

тарафыннан вакытлы матбугат ачарга рөхсәт сорап, 20дән артык гариза кергәнне күрсәтә. Шунысы кызык: татар телендә басма нигезләргә теләгән татарларга гына түгел, шул фикер белән үтенеч язган башка милләт вәкилләренә дә рөхсәт бирелми. Бу өлкәдә гаҗәеп, көтелмәгән хәлләр дә булып тора. Әйтик, 1808 елны Казан университетының адъюнкты, рус һәм татар телләрендә газета нәшер итәргә исәпләгән И.И. Запольскийның үтенече бер яклы – рус телендә басма чыгару өчен генә канәгатьләндерелә. Мондый омтылышларның үкенечле нәтиҗәләргә китерүе дә мәгълүм: 1834 елны татар телендә «Бәхер әл-әхбәр» («Хәбәрләр диңгезе») дигән газета чыгару турында гариза язган өчен Казан университеты укытучысы М.Г. Никольский шәһәрдән үк сөрелеп, Әстерхан губернасына җибәрелә (*Амирханов Р. Татарская дореволюционная пресса ... Б. 34-36*).

Шушы хәлләрдән хәбәрдар татарлар, гариза язу белән чикләнмичә, үзгә юллар эзләргә керешәләр. XIX гасырның икенче яртысында күпләп басыла башлаган татар календарьлары шуның бер чагылышы, дия алабыз. Мисалга, 1863 елны беренче тапкыр литография хуҗасы М.Яхин белән бергәләп, газета чыгарырга рөхсәт сораган күренекле мәгърифәтчебез Каюм Насыйри, тискәре җавап алгач та, күп еллар дәвамында гаризалар бирүдән туктамый. Шул ук вакытта ул еллык «Казан календаре» (1871-1898) чыгаруга керешә, әлеге басма 30 елга якын халыкның үз телендә мәгълүматка, әдәби сүзгә ихтыяҗын күпмедер дәрәҗәдә канәгатьләндереп килә. Мөгаллим, язучы һәм тәрҗемәче Ш.Рәхмәтуллинның өстәл календарьлары 1891 елдан башлап, 10 ел буе нәшер ителә. Беренче драматургыбыз Ф.Халиди 1893 елдан төзи башлаган дивар календарьлары 30 ел дәвамында татар укучысын рухи азык белән тәэмин итә. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Календарьлар тарихын өйрәнгән Ләйсән Миңнуллина күрсәткәнчә, 1841-1917 еллар аралыгында татарларда 30 кулъязма һәм 202 басма календарь әзерләнгәне билгеле. Басма календарьларның гомуми тиражы 1 113 104 данә тәшкил итә! (*Миннуллина Л.З. Татарские печатные календари XIX – начала XX вв. Казань: Изд-во «Заман», 2015. С. 153-154*).

Тагын бер юлны 1900 елны күренекле сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, фикер иясе Габдерәшит Ибраһимов (1857-1944) таба: «Миръат, яхуд Көзге» дигән альманах нигезләп, бер яктан, татарлар арасында «калын журнал» чыгаруга ихтыяҗ барлыкны дәлилли, икенче яктан, альманах битләрендә әдәби журнал чыгару өчен иң әһәмиятле шарт булган милли әдәбиятны үстерү хакында да сөйләшү башлап җибәрә. Барлыгы 22 сан чыккан альманахның 6 нчы санында Ф.Кәриминең татар әдәбиятының бүгенгесе һәм киләчәге хакындагы уйланулары дөнья күрә, 8 нче санда Г.Р. Ибраһимов әдәбиятның, китапның милләт үсешендәге роле турында үз фикерләре белән уртаклаша, нәкъ менә әдәбият – милләт хәленең көзгесе дип белдерә һ.б.

Татарча журнал яки әдәби журнал буларак карала алмаса да, альманах шушы юлда ясалган зур адым дип бәяләнә ала. Әйтик, 1883-1918 елларда беренче булып төрки һәм рус телләрендә «Тәрҗеман-Переводчик» газетасын чыгарган И.Гаспралының (1851-1914) хезмәте турында Җ.Вәлиди болай дип язган була: «И.Гаспралы тел-әдәбият мәсьәләсендә үзенең максатына ирешмәсә, ягъни барлык төрки халыкларны уртак әдәби тел ярдәмендә берләштерә алмаса да, аның төп фикере тормышка аша: ул 30 еллык хезмәте белән бу халыкны мәдәни үсеш юлына чыгарып, шул юлга бастырып калдыра» (*Валидов Дж. Очерки истории образованности и литературы татар. Казань, 1998. С. 80*). Күрәсең, Г.Р. Ибраһимов хезмәтен дә «шушы юлны» табып калдыру дип әйтергә буладыр.

1905 ел алып килгән үзгәрешләр дулкынында татар вакытлы матбугатын оештыру мөмкинлеге туугa, зыялылар газета-журналлар ачу артыннан йөри башлыйлар. 1906 елның 15 гыйнварында беренче булып күренекле җырчы, журналист булып танылачак Камил Мотыйгый (1883-1941) Уральск каласында «Әл-гасыр әл-җәдид» (Яңа гасыр) дип исемләнгән беренче иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журнал ача. Шул рәвешле, татар

телендә беренче журнал 1906 елдан нәшер ителүне ассызыкларга мөмкин. Басма 1907 елның маена кадәр чыгып килә һәм татар җәмгыятен берләштерү юлында хезмәт куя.

Шунысы кызык, Истанбул һәм Каһирәдә белем туплап, 1902 елда илгә әйләнеп кайткан К.Мотыйгый 1903 елдан этисе Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин мәдрәсәсе шәкертләре белән бергәләп, кульъязма «Әл-мәгариф» газетасын һәм «Әл-гасыр әл-җәдид» кульъязма журналын булдыра, ул исә сөекле шагыйребез Г.Тукай өчен тәүге каләм сызу мәйданы буларак ат казана! Бу эшләренең сәбәбен аның үз сүзләре бик ачык күрсәтеп тора: «Бары тик нәшерлек юлы белән генә халыкның рухи омтылышларын канәгатьләндерергә мөмкин», дип яза ул. (*Амирханов Р. Татарская дореволюционная пресса ... Б. 40).*

Бу журнал артыннан ук, июнь аенда Уральскида «Уклар», Казанда «Әд-дин вә әл-әдәп», Оренбургта «Чикерткә», аннары «Чүкеч», «Карчыга», «Дөнья вә мәгыйшәт» һ.б. басыла башлый. Болар – беренче тәҗрибә, сынау узу чоры басмалары; «калын» дип бәяләнә торган әдәби журналдан ерак торалар. Алар, нигездә, аерым бер төркем, катлау укучыларга адресланып, шуларның ихтыяҗларын исәпкә алып чыгарыла. Татарлар арасында, бигрәк тә, көлке журналлары (мәгърифәтчелек хәрәкәте дәвам итә – тәнкыйть алдынгы!) күпләп пәйда була; акрынлап хатын-кызлар, балалар өчен, икътисад яки мәгариф мәсьәләләренә багышланган басмалар нигезләнә. 1917 елга кадәр Россиядә татар телендә 30 журнал нәшер ителүе мәгълүм.

Әмма зыялылар өчен махсус басма булдыру идеясе дә көн тәртибеннән төшми. 1908 елның 10 гыйнварында Оренбургта «Шура» журналын нигезләгән Мөхәммәтшакир (1857-1912) һәм Мөхәммәтзакир Рәмиевләр (1859-1921) аны әдәби, гыйльми, тарихи журнал итеп күзаллыйлар. Атаклы промышленниклар, алтын приискалары хуҗалары, алар бу эшкә максатчан, махсус керешәләр. Әйтик, Шакир Рәмиев әле ерак 1881 елны Истанбулдан 21 яшьлек энесе Закирга җибәргән хатында татар милләте өчен иң кирәкле мәгърифәт чарасы – басма сүз, китап булуны ассызыклый, типография хәрефләрен сатып алып, илгә кайтаруны кайгыртуын үтенә (бу хат тексты «Шура» журналының 1913 елгы алтынчы санында басылган).

Журнал, чыннан да, татарларның гына түгел, төрки-мөселманнарның тормышы, узганы, мәдәнияте турында да, гомумән сәясәт, дин, фән, мәгариф, мәдәният турында да гаять төпле, фундаменталь мәгълүматлар тупланган иң алдынгы басма булып чыга. «1908-1917 елларда чыккан «Шура» (Киңәш) журналы XX йөз башында нәшер ителгән татар газета-журналлары арасында тематик киңлеге, эчтәлегенең байлыгы, мәгълүматлылык бәһасе, эшләнеш җәһәтеннән нәфасәте һәм затлылыгы белән иң күренекле урыннарның берсен алып тора. Журнал айга икешәр мәртәбә чыккан. «Шура»ның 1908 елның 10 гыйнварында дөнья күргән иң беренче саны һәм 1917 елның 31 декабрендә чыккан иң соңгы санынннан кала, барлык саннары да, тәртипле рәвештә, һәр айның 1 һәм 15 нче көннәрендә басылганнар. Шул рәвешле, бер елга 24 сан чыгып килгән. Ун ел дәвамында нәшер ителгән «Шура» журналының барлыгы 240 саны дөнья күргән» (*Госманов М., Мәрданов Р. «Шура» журналының библиографик күрсәткече. Казан: Милли китап, 2014. Б. 3-4*).

Баш мөхәррире, галим һәм язучы, дин белгече Ризаэддин Фәхреддин (1859-1936) аны әзерләүгә чорының мәгълүм зыялыларын тартырга омтылган. Редакциядә төрле елларда Фатыйх Кәрими, Шәриф Камал, Зариф Бәшири, Җамал Вәлиди, Ярулла Вәли, Кәбир Бәкер һәм башкалар хезмәт куйганы билгеле.

Әлбәттә, «Шура» журналында да, башка журналлар, газеталарда да татар әдәбиятына, мәдәниятенә караган материаллар, фольклор үрнәкләре, әдәби әсәрләр төп урынны алып тора. Әмма аны, әдәби журнал диюдән бигрәк, иҗтимагый-мәдәни комплекслы-энциклопедик басма дип атау дөрес булыр. Махсус әдәби журнал чыгару соңрак насыйп була, ул Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәнов (1883-1933) исеме белән бәйләнгән.

## «Аң» журналы – беренче әдәби басма

XX йөз башы мәдәни тормышында иң күренекле урын тоткан «Гасыр» нәшриятының хуҗасы, язучы, драматург, тәрҗемәче Әхмәтгәрәй Хәсәни – Г.Тукайның, Ф.Әмирханның, Г.Кәрамнең, Г.Гобәйдуллинның, Г.Рәхимнең, Г.Ибраһимовның дусты, мәсләктәше, фикердәше була. Университетларда белем алган, рус, Европа мәдәниятен яхшы белгән, җитеш гаиләләрдә тәрбияләнгән татар яшьләренең рухи-фикри лидеры, аларны милли мәдәнияткә хезмәткә тартучы, интеллектуал һәм эстет, тыныч, сабыр холыклы, эзләнүчән һәм максатчан, матурлыкны яратучы, йомшак күңелле кеше.

Татар укучысын заман сәнгате белән таныштыруны, шулай гакълый-мәдәни яктан камилләштерүне максат итеп куйган, XX йөз вакытлы матбугаты мәйданында иң эчтәлекле һәм иң югары сыйфатлы «Аң» журналын чыгару карарының кабул ителү вакыйгасы Т.Мамлиевның 1912 елның 31 июлендә язылган доносында түбәндәгечә сакланып калган: «Татар әдәбият түгәрәге июльнең 26-сында Евангелистовский урамда Хәсәнев йортында җыелды. Җыелыш тиз көннән калын рус журналлары шикелле бер әдәби, сәяси журнал чыгарырга карар бирде. Бу журнал яшь татар милләтчеләрен берләштерергә тиеш булачак. Журнал Хәсәневлар исеменнән чыгачак. Җыелышта булган кешеләр: Гәрәй, Барый Хәсәневлар, Фуат Туктаров, Габдулла Гыйсмәтуллин, Габдулла Тукаев, Фатих Әмирхан, учитель Гафур Колахмәтов, Исмәгыйль Аитов, Гыйльметдин Шәрәф, Галимҗан Ибраһимов, Габдеррахман Кәрам» (*Мансуров Г. Татар провокаторлары. М., 1927. Б. 51).*

Ә.Хәсәни журнал оештыру идеясен күп еллар күңелендә йөртә. Аның «Гасыр» нәшрияты да татар халкына күп игелекле эшләр башкара: 1907-1921 еллар аралыгында биредә 153 исемдәге китап 437 500 тираж белән дөнья күрә! С.Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» комедиясе, Ф.Кәриминең «Морза кызы Фатыйма»сы, Г.Ибраһимовның «Сөю – сәгадәт»е, «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»се, Ф.Әмирханның «Татар кызы» һәм «Фәтхулла хәзрәт»е, С.Җәлалның «Дим буенда»сы, Г.Камалның «Беренче театр», «Безнең шәһәрнең серләре» – һәм башка татар әдәбиятының иң күренекле әсәрләре шушы басмаханә аша татар укучысына барып ирешә. Югары сыйфатлы күпсанлы тәрҗемәләр, фәнни әдәбият (әйтик, Г.Ибраһимовның тел белеменнән китаплары), дәреслекләр, халык авыз иҗаты җәүһәрләрен туплаган җыентыклар, балалар әдәбияты, сүзлекләр, хәтта аш-су, медицинага караган китаплар, татар язучыларының, сәнгать эшлеклеләренең портретлары белән почта открыткалары – ниләр генә юк аның репертуарында! 1916 елны «Гасыр» хуҗасы халыкка бушлай өләшү өчен мең данә Сөембикә рәсемен эшләтә. Халыкның милли аңын кем шәүкәте-авторитеты ярдәмендә күтәрү, милләтне кайсы шәхесләр тирәсенә туплау мәсьәләсендә дә аның алдан күрүчән булганлыгы бәхәссез.

**Исемен Г.Тукай тапкан «Аң» журналы иң талантлы иҗатчыларны үз тирәсенә берләштерә. 1912 елның 15 декабреннән 1918 елның мартына кадәр айга ике тапкыр басыла килеп, 123 сан тәшкил иткән «әдәби, фәнни, сәяси вә иҗтимагый рәсемле журнал» татар халкы өчен мөһим идеологик, рухи, мәдәни проблемаларны күтәрә, яңалыкларны мәйданга чыгаручы гына булмыйча, бәлки әдәбиятта тәҗрибәләр (экспериментлар) ясаучы үзәккә әйләнә, татарларда беренче «калын журнал», «әдәби журнал» булып чыга. Ул, асылда, бүген «Казан утлары» исеме белән йөртелә торган төп басмабыз тарихы 1912 елның 15 декабреннән санала башланырга тиешлекне искәртә.**

Журнал ачылуга ихластан шатланып, Г.Тукай аның беренче санына «Аң» дигән шигырь багышлый. «Аң»ның тәүге, 1912 елгы 1 (15 декабрь) саны шушы шигырь белән ачыла. «Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән» дип башланган шигырь, әйтерсең лә, милләт өчен көрәшнең катлаулы-каршылыклы юлын күзәтеп уза, ул болай дип төгәлләнә:

*Үтте инде, дустларым, ул үткән эш, ни булса ул;*
*Инде эшлик саф, ачык күзләр белән – чын «Аң» белән.*

Шул рәвешле, әйтерсең лә, «Аң» журналы ачылу шагыйрь тарафыннан бер дәвернең – төгәлләнүен, яңа дәвер башлануны хәбәр иткән эпохаль бер вакыйга итеп бәяләнә.

Журнал, чын-чынлап, заманча нәшер ителә! Басманың сыйфаты, шрифты, бизәлеше – берсе дә тел-теш тидерерлек түгел. 1912-1914 елгы номерлар әсәрләрнең идеясе белән бәйле урнаштырылган репродукцияләргә бай булса, 1914-1915 елларда фотоматериаллар журналның бизәгенә, мәгънәви тәэсир көчен арттыру чарасына әверелә. Журнал чыгаручылар әдәбиятны алга җибәрү, үзгәртү, татар укучысының зәвыгын камилләштерү максатында сәнгатьнең башка төрләрен мөмкин кадәр киңрәк файдаланырга тырышалар. Журнал белән чикләнмичә, 1914 елны редакция әдәби әсәрләр тупланган «Әдәби альманах», 1915 елны күренекле рәссамнарның иҗат үрнәкләре җыйналган «Альбом (Сәнаигы нәфисә мәҗмугасе)» эшли һәм «Аң» мөштәриләре-әбунәчеләренә һәдия-бүләк итеп тарата. Шулай редакция әдәбият-сәнгать үрнәкләрен халыкка җиткерүнең яңадан-яңа юлларын эзли. Боларның башында, әлбәттә, акыллы һәм максатчан Хәсәни тора.

«Аң» исеменә тугры калып, журнал татар кешесенең аңын, дөньяга карашын үзгәртүгә хезмәт итә. Журналда даими рәвештә, әдәби әсәрләр белән беррәттән, фәнни, сәясәт, икътисад мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр, сәнгать, театр, музыка өлкәсендәге яңалыкларга күзәтүләр, тарих һәм дин, мәгариф һәм тәрбия, матбугат торышы, аерым шәхесләргә кагылышлы язмалар тәкъдим ителә. Ләкин иң мөһиме – яшь авторлар югары мәдәниятне чит телдәге басмалардан эзләгән милләттәшләре өчен дә кызыклы булырлык мәгълүмат бирә, татар укучысын дөнья мәдәниятендә барган процесслар белән таныштыра.

Әйтик, Ә.Хәсәнинең үзенең (әдәби тәхәллүсе Г.Ильяс), М.Хәнәфинең һ.б. язмаларында һинд, кытай, юнан, рум фәлсәфәләре, Шопенгауэр һәм Ницше, Кант һәм Джон Стюарт Миль карашлары чагылыш таба. Күренекле тәнкыйтьче һәм галим Җ.Вәлиди мәкаләләрендә татарларга рус, Европа мәдәниятенә якынаю кирәклегенә басым ясый, моны «тарихи вә иҗтимагый канун тудырган мәҗбүрият» саный. Хуҗалык итү, фән, техника өлкәләрендә артта калган татарлар Европага ияреpгә тиешләр, шул вакытта фәлсәфә, әдәбият үсү өчен шартлар туар иде, дип ассызыклый. «Аң» битләрендә милләтнең иртәгесе, киләчәге турында сөйләшү бара, иҗтимагый-мәдәни яңарышның милли үсеш-үзгәреш ихтыяҗына буйсындырылырга тиешлеге ачыклана. Моның теоретик нигезләре күзаллана.

1913-1914 елларда «Аң» журналы «Милләтне ничек аңлыйсыз?» дигән анкета уздыра, шуның җавапларында милли рух, «милли вөҗдан» – үзеңне этник бердәмлекнең аерылгысыз бер кисәге итеп хис итү, миллилек – «миллият» мәсьәләләренә кагылып, «миллиятле милләт дөньядан югалмый» дигән караш ныгый.

Журнал битләрендә әдәбиятның нинди булырга тиешлегенә караган бәхәсләр оештырыла, Г.Ибраһимовның, Х.Кәримнең, Г.Рәхимнең, Н.Хәлфинның һ.б. әдәбиятчыларның теоретик характердагы язмалары дөнья күрә. Аларда татар сүз сәнгатен үгет-нәсихәтчелектән арындырырга, әдәбиятның сәнгатьлелеген күтәрергә чакыру фикере яңгырый.

Әлбәттә, әдәбиятта үзгәрешләр пәйда булу, үзенчәлекле әсәрләр язылу өчен сәләтле, әзерлекле язучылар булу шарт. Тәҗрибәләрне әйдәп баручы, «Аң» журналының һәр санында берничәшәр әсәр белән катнашучы Фатих Әмирхан, Шәриф Камал нәкъ менә шундый сыйфатларга ия булалар. Дөнья әдәбиятындагы идея-эстетик эзләнүләр кимәлендә әсәрләр язып, әдипләр аларның милли, бер язучыны да кабатламый торган, яңгыраш һәм моң җәһәтеннән укучыга үз һәм якын булуына ирешә. Филологик әзерлекле, укымышлы, әдәбият тарихы һәм тәнкыйте өлкәләрендә дә актив эшләп

килүче, әдәби күренешләргә бик сизгер, тоемлы, зәвыклы Газиз Гобәйдуллин һәм Гали Рәхим әсәрләре эшкәртелү дәрәҗәсе, төгәлләнгәнлеге белән аерылып тора. Алар артыннан журнал битләрендә Фәйзи (Вәлиев), Ә.Тангатаров, К.Тинчурин, Н. Гасрый һәм башкалар иҗаты күренә. Гасыр башы әдәбиятында яңарыш олы бер хәрәкәткә әверелә.

Журнал татар мәдәниятендә фәлсәфи әдәбият тудыручы үзәк булып танылa. Татар фәлсәфи әдәбиятында җир тормышының чикләнгәнлегенә, яшәешне танып белә алмауга нисбәтле метафизик сагыш, кеше гомеренең мәгънәсенә, хакыйкатькә төшенә алмау кайгысы, рухи камилләшүгә омтылыш һәм тормышны үзгәртә алуга ышаныч, яшәешнең чиксезлеге алдында баш ию алга чыга. Илаһи башлангычны тергезү, шәхесне камилләштерү аша дөньяны агарту фикере яңа әдәбиятта яңа идеяләр тудыра.

Никитин типографиясен сатып алып, журнал чыгару өчен 1917 елның октябрь аенда Хәсәни «Аң» дигән типография оештыра. Казандагы иң яхшы басмаханә буларак, 1918 елдан ул яңа хөкүмәткә вакытлыча хезмәткә (арендага) алына. 1919 елны хуҗалары Ә.Хәсәни һәм Г.Рәхмәтуллин аны рәсми рәвештә үз теләкләре белән дәүләткә тапшыралар. Китап-журнал бастыру өлкәсендә иң әзерлекле белгечләрдән булган Әхмәтгәрәй эшсез кала. Дуслары Хәсәнине шәхси басмаханә оештырырга үгетлиләр. Заманча – «Яңа китап» дип исемләнгән бу басмаханә 1926 елны эшли башлый. Оештыручылары арасында – «Аң»да тәрбияләнгән сәләтле шәхесләр: Ф.Борнаш, К.Нәҗми, М.Гали, К.Тинчурин, С.Җәлал, З.Нуркин, Ш.Байчура, М.Бөдәйли, Ф.Әмирхан, Б.Бикколов һ.б. 1929 елны эшчәнлеге тукталган бу оешма Ә.Хәсәнине 1931 елны кулга алуга, аның гаиләсенә килгән җәфаларга формаль сәбәп була. 1932 елның маенда 3 елга хөкем ителеп, Беломор каналын төзергә җибәрелгән Әхмәтгәрәй, срогын тутырып кайтканда, 1933 елны тиф авыруыннан үлә. Аңа бу вакытта бары 50 яшь. Гаиләсе, хәтта, каберенең кайда икәнлеген дә ачыклый алмый. Исеме РСФСР Югары Судының 1959 елның 29 сентябре карары нигезендә аклана (*Әхмәтгәрәй Хәсәни: Фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2011. 408 б.).*

Күрәсең, совет чорында татарларда әдәби «калын журнал» тарихын билгеләгәндә, мөхәррирнең сыйнфый чыгышы, фаҗигале язмышы хәлиткеч роль уйнагандыр: «Казан утлары» журналының оешуын 1922 елдан, «Безнең юл» журналы ачылудан башлап санау кабул ителгән.

## «Безнең юл» – совет чорындагы беренче әдәби «калын журнал»

1917 ел революциясеннән соң татар телендәге газета-журналлар ябылып, мәдәни күренешләр – буржуаз эчтәлекле дип игълан ителгән шартларда әдәби «калын журнал»лар да юкка чыгар, мәдәният мәйданыннан алып ташланыр кебек тоела. Әмма мондый басманың иҗади-җәмгыяви фикергә юнәлеш бирү мөмкинлекләрен яхшы аңлаган Советлар рус телендә дә, башка халыклар телләрендә дә әдәби журналлар чыгару эшен тергезәләр.

«Безнең юл» журналы 1922 елның май аенда гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый айлык журнал итеп ТССР Халык комиссарлары советының Үзәк башкарма комитеты органы буларак гамәлгә куела. 1923 елдан ТАССР Мәгариф халык комиссариаты органына әйләнә. 1934 елдан – ТАССР Язучылар берлеге органы.

1934 елны Язучылар берлеге оешканга кадәр журнал татар әдипләрен, журналистларын һәм галимнәрен берләштерүче үзәк ролен башкара. Беренче санынннан алып, анда әдәби әсәрләр өстенлек итә. Ул укучыларны Г.Газиз, М.Гафури, М.Җәлил, Ш.Камал, Г.Кутуй, Һ.Такташ, Х.Туфан һ.б. әсәрләре белән таныштыра. Үзләренең тәнкыйди, гыйльми язмалары белән Ф.Борнаш, Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Г.Рәхим, Г.Сәгъди һ.б. чыгыш ясый. Театр, рәсем һәм музыка сәнгате үсешенә, татар мәдәнияте

тарихын өйрәнүгә кагылышлы мәсьәләләр, башлыча, шушы журналда яктыртыла (*Айнетдинов Р.А. «Казан утлары» //Татар энциклопедиясе. 3 том. Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты, 2012. Б. 151).*

Әлбәттә, журнал бик катлаулы сәяси-мәдәни шартларда ачыла. Илдә советлар хакимияте урнаштыру канлы көрәш юлы белән алып барыла. Бу процессны идеологик яктан җитәкләү өчен совет әдәбияты булдыруга аерым әһәмият бирелә. XX йөз башында үз традицияләрен урнаштырган, тизләнеп үсү юлына чыккан татар әдәбияты юллар чатында кала. Татар язучылары төркемнәргә бүленә: инкыйлабны яклаучылар, ике арада бәргәләнүчеләр, большевиклар идеологиясен кире кагып, мөһаҗирлеккә китүчеләр пәйда була. Классик әдипләр иҗатына карата тискәре мөнәсәбәт, аны искелек чагылышы итеп карау, милли әдәбиятның рус мәдәниятенә йөз тотып үсәргә тиешлеге хакындагы фикерне көчләп урнаштыру иҗат эшен тоткарлый. 1921 елны Ф.Әмирхан болай дип яза: «Мин Николай цензурасының иң кара вакытында да, Керенский заманасында да газеталарда эшләгән кеше, ләкин мин һич вакытта матбугат хөрриятенең бу кадәр тапталганын, матбугат һәм фикер хөрриятенә бу кадәр богау салынганын үз өстемдә хис иткәнем юк иде» *(ал.: Фатих Әмирхан. Традицияләр һәм заманчалык: Ф.Әмирханның тууына 120 ел тулуга багышланган республика фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2006. Б. 55).*

Менә шушы шартларда күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм галим Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов (1887-1938) инициативасы белән «Безнең юл» журналы оеша. Журналның беренче саны «Безнең юл» идарәсеннән әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият яратучыларга мөрәҗәгать» белән ачыла. Анда мондый юллар бар: «Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, «Безнең юл» журналын чыгара башладык. «Безнең юл»ның чыгуы татар җөмһүриятенең мәркәзендә – Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без үзәктә, Идел-Урал, Себернең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, гыйлем-әдәбият яратучыларның ярдәменә ышанып эшкә керештек» (*1922, № 1*). Шул рәвешле, яңа басма сибелеп яшәүче халкыбызны берләштерү максатын алга куя.

«Безнең юл»га мөхәррир итеп Гасыйм Гата улы Мансуров (1894-1955) – 1917 елдан РСДРП (б) әгъзасы, 1920 елны ТАССР эчке эшләр халык комиссары урынбасары, ТАССР НКВДсының җинаятьләрне эзләү идарәсе башлыгы булган, 1920 ел ахырында Урта Азия хокук саклау органнарына ярдәмгә җибәрелгән, 1921 ел ахырында Казанга, РКП (б) өлкә комитеты үгетләү-пропаганда бүлеге мөдире итеп күчерелеп, аннары «Коммунистический путь» (соңыннан «Татарстан коммунисты») журналының баш мөхәррире булган чекист билгеләнү республика өчен мөһим журналның сәяси нигезен «дөрес» итеп кору белән бәйле була, күрәсең.

Әмма Иж-Буби мәдрәсәсендә белем алган, соңрак 1925 елны Мәскәүдә басылып чыккан «Татар провокаторлары» китабы белән танылачак Г.Мансуров, революционер гына түгел, татар милләтенә һәм хакыйкатькә хезмәт итәргә омтылган шәхес булып күз алдына баса. Ул 1922 елда Идел болгарларының исламны кабул итүенең 1000 еллыгын киң билгеләү турындагы мәсьәләне күтәрә, мөфти Г.Баруди җәсәден Мәскәүдән Казанга кайтаруны оештыра. 1924 елның 6 маенда Мәскәүгә эшкә күчерелгәч, Г.Мансуров – РКП(б) Үзәк Комитетына Сталин исеменә М.Х. Солтангалиевне ябылудан азат итүне һәм аны порукага алырга рөхсәт итүне сорап, хатлар язучыларның берсе була. 1929 елның июлендә ВКП (б) Үзәк контроль комиссиясе аны нәкъ менә Солтангалиевчелектә гаепләп, партиядән чыгара, шул елның декабрендә кулга алынып, иң югары җәзага хөкем ителә. Аннары бу җәза 10 ел сөрген белән алмаштырыла.

1923 елның көзендә журналга мөхәррир булып килгән Микъдәт Юныс улы Борындыков та (1896-1965) 1917 елдан большевик, татар телендә чыга торган

«Коммунист» газетасының мөхәррире, 1920-1921 елларда Казанда Үзәк мөселман хәрби коллегиясен җитәкли, 1921-1922 елларны Мәскәүдә милләтләр эше буенча халык комиссары вазифасын башкара, аннан ТАССР мәгариф халык комиссары булып кайта. 1930 елны нахакка кулга алына, аның да язмышы аяныч булып чыга.

Шушы урында әлеге ике шәхеснең тормышы-язмышына бәйләп, тагын бер фикерне ассызыклап үтү мәгъкуль булыр: иҗтимагый-сәяси ситуация ничек кенә катлаулы булмасын, әдәби журнал чыгаручы татар зыялылары һәрвакыт үзләре күзаллаган дәрәҗәдә, татар халкы, үз милләте мәнфәгатьләрен алда тотарга тырышалар. Яңа идеология нинди зур басым астында урнаштырылуга карамастан, журналда бәхәсле, милләт язмышына, милли мәдәниятнең киләчәгенә турыдан-туры кагылган язмалар басыла тора. Шуларга бер мисал итеп, тел галиме, профессор Гыйбад Алпаровның «Безнең юл»ның 1926 елгы дүртенче санында дөнья күргән, үз чорының иң бәхәсле, иң каршылыклы – гарәп графикасыннан латинга күчү мәсьәләсенә багышланган «Латин түгел, гарәп» мәкаләсен күрсәтергә мөмкин.

1926 елда Бакуда уздырылган Беренче тюркология корылтаеннан соң әлеге мәсьәлә татар дөньясында зур җәнҗал куптара һәм җәмгыятьтә ике чиккә аерылу китереп чыгара. Т.Гыйззәтнең «Гарәпме, латинмы?», Ш.Камалның «100 процент» һәм «Гарәп хәрефләре төзеләчәкме?», Ф.Сәйфи-Казанлының «Реформамы, революцияме?» һәм «Тезисларга каршы – тезислар: латин хәрефләре» дигән мәкаләләре әлифба алыштыруны яклап әзерләнгәннәр. Корылтайда Татарстан делегациясе исеменнән чыгыш ясаган Г.Ибраһимов әлеге мәсьәләдә советларның рәсми позициясен якламаган мәкаләләр яза: «Революцияме, реформамы?», «Гарәп хәрефләре», «Яңа батырлар, муллалар, диннәр, техникалар», «Банкротлар».

Г.Алпаровның язмасы да укучы алдына бик күп сораулар куя. Бер яктан, автор һәм гарәп, һәм латин, һәм кирилл хәрефләренә күчү китереп чыгарырга мөмкин булган барлык уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне билгели. Ул теге яки бу позициягә баскан кешеләр белән бәхәскә керә һәм татар теленең киләчәге, һәм үткән мирасны саклау якларын үзәктә, күз уңында тотып, үз фикерләрен бик ачык формалаштыра. Төрки-татарлар тарихында әлифба алмашынулар тарихына да мөрәҗәгать итә, бу эш өчен кирәкле шартларны да бик дөрес санап чыга. Авторның фикере дөрес – әлифба алмаштыру бары тик матди мөмкинлекләр җитәрлек булганда, моңа керешкәнче элекке мирасны яңа хәрефләргә тулысынча күчереп бетерә алганда гына тотына торган эш! Кызганычка каршы, бу бәхәстә рәсми караш җиңә һәм 1927 елда Татарстан хөкүмәтенең латин алфавитына күчү турында махсус карары чыга. Бүген инде без әлеге мәкаләдә күрсәтелгән фикерләрнең никадәр дөрес булуын да, гарәптән латинга һәм кириллга күчүнең милли мәдәният өчен гаять аяныч нәтиҗәләрен дә бик ачык күрәбез!

Йә булмаса Г.Сәгъдинең «Безнең юл» журналының 1923 елгы 1 санында, Г.Гобәйдуллин һәм Г.Рәхимнәрнең «Татар әдәбияты тарихы» китабына рецензия итеп язылган «Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы» мәкаләсе – үз чорында гына түгел, бүген дә татар фольклористикасы тарихында хәлиткеч роль уйнаган хезмәт дип санала. Анда галим татар халык авыз иҗаты – милләтнең бәһаләп бетергесез хәзинәсе ул дип, фольклор үрнәкләрен җыю, өйрәнү, халыкта киң таралган сюжетларга яңа әсәрләр иҗат итү, мәгълүм дастаннарның җыелма вариантларын төзү бурычын куя. Ерак 1923 елда исә бу язма татар зыялыларын – үз мирасларын өйрәнүгә, туплауга, саклауга, фәнни әйләнешкә кертүгә чакыру булып яңгырый, кайтавазы игелекле хезмәтләр булып халык мәдәни тарихында да, журнал сәхифәләрендә дә үзен сиздерә.

Шул рәвешле, исеме Советлар идеологиясенә яраклаштырып, «Безнең юл» дип куелса да, журнал милли үзаң тәрбияләүне, татар мәдәниятен үстерүне, татар халкы тормышындагы катлаулы мәсьәләләрне куюны да – үз юлы, үз мәсләге, үз кыйбласы дип санаган басма булып эшләп китә.

Оешканда ук журнал эчтәлеге белән «кызыл» басма булып күзаллана: аның битләрендә революцион хәрәкәтләр тарихын яктыртуга, совет дәүләте төзелешен мактауга киң урын бирелә. Журналда яңа ныгып килгән Татарстан Җөмһүриятенең икътисади, иҗтимагый хәле, урыннардагы проблемалар хакындагы язмалар күпләп басылып тора. Аннары, 1926 елга кадәр татар телендә партия журналы булмаганга, агитация-пропаганда бурычлары да «Безнең юл»га йөкләнә. Әмма яңа әдәбият тудыру бурычы да читкә кагылмый. Бу яктан журналның юнәлешен Г.Ибраһимов билгели дияргә нигез бар.

1913 елның 16 сентябрендә Казанга килеп, Ә.Хәсәни чакыруы буенча «Аң» журналында җаваплы сәркатип булып эшкә керешкән, әмма 1914 елның 13 февралендә, кулга алынудан качып, Киевка китеп барган, шуңа да журналда үз алдына куйган планнарны үтәп өлгермәгән Г.Ибраһимов, бәлки, яңа басманы үзенең яшь вакыттагы өмет-хыялларын тормышка ашыру мөмкинлеге итеп караган, татар әдәбиятының ныгу мәйданы буларак үстерергә дә ниятләгәндер. Чөнки «Аң»да эшли башлауга, Ибраһимов журналга шактый үзгәрешләр керткән була: ул «Фәнни вә фәлсәфи мәсьәләләр», «Хатын-кыз галәменнән» дигән бүлекләр ача; анкеталар белән эшләүне нигезли, шул рәвешле журнал битләрендә көн кадагына суккан мәсьәләләр турында сөйләшүгә киң катлау укучылар тартыла. Тагын бер зур проекты – «Аң»ның әбунәчеләре өчен «Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасе)» исеме белән рәсем сәнгате әсәрләре тупланган альбомда Ибраһимовның әдәбият-сәнгать хакындагы уйланулары-эзләнүләре чагылыш таба, ул татар әдәбияты тарихын булдыруга юнәлтелгән хезмәт кебек тә кабул ителә!

Әмма заман алып килгән үзгәрешләр язучының әдәбият-сәнгатькә кагылышлы концептуаль карашларын да баштанаяк әйләндерә. «Безнең юл»ның иң беренче (май) саны ук Г.Ибраһимовның «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» дигән өр-яңа зур күләмле мәкаләсе белән ачыла. Анда ул рус әдәбиятын яңа нигездә – совет идеологиясенә тәңгәлләштереп тикшерүдәге беренче тәҗрибәләр хакында сөйли, татар әдәбияты тарихын марксизм ысулы белән тикшерү мөһимлеген көн тәртибенә куя, үзенең бу мәсьәләдә карашын тагын бер кат аңлатып уза. Аннары татар әдәбиятын дәверләргә бүлү аерып алынып, бу мәсьәләдә шул ук позицияне яклаган Г.Сәгъди карашлары анализлана. Әмма аның мәгърифәтчелекне бер дәвер дип каравы, борынгы чорны ваграк баскычларга аеруы белән килешмичә, Г.Ибраһимов үз бүленешен шәрехли: 1) Борынгы-кадим Шәрык (феодалчылык); 2) Яурупа тәэсире, рухы белән яңару, җәдитләнү (капитализм); 3) соңгы хәрәкәтләр тәэсире белән сыйнфый мөнәсәбәтләр нигезенә төшү (пролетариат революциясе заманасы). Шушы дәверләрнең чикләрен, чорлардагы вакыйгаларны, төп проблематиканы, иҗатчыларын күздән кичерә, татар әдәбиятында танылган каләм әһелләренең әдәби барышта урынын билгеләү омтылышы ясый. Шул рәвешле, татар әдәбияты тарихын күзәтүгә һәм аны марксизм методы белән тикшерүгә багышланган зур бер хезмәт килеп чыга.

Журналның икенче (июнь-июль) санында, шушы язманың дәвамы буларак, Ибраһимовның «Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен билгеләү мәсьәләсе» дигән мәкаләсе басылып, ул «татар әдәбияты тарихы» дигән төшенчә һәм аның вакыт-урын ягыннан чикләренә кагыла, ягъни татар әдәбияты тарихын чорларга бүлү турында сөйләшүне дәвам итә. Ибраһимов бирердә гомумтөрки әдәбиятны татар әдәбияты тарихыннан аерып карарга чакыра, татар әдәбияты тарихын исә Казан ханлыгы егылганнан соңгы дәвер белән башларга тәкъдим итә (шунда ук Казан ханлыгы, Алтын Урда заманындагы әдәбият үрнәкләре табылса, хәл үзгәрәчәк дип тә өсти). Шул рәвешле, Г.Ибраһимов «әдәбият тарихы» дигәндә ике: төрки-татар мәдәнияте барышын һәм татар әдәбияты барышын аерып алу карашын алга сөрә. Милли әдәби процессны рус мәдәнияте белән бер дулкында, «марксизм» дулкынында өйрәнү омтылышы була бу.

1925 елның башында Ибраһимов Республика Мәгариф комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәк рәисе итеп билгеләнә. Гыйльми үзәк Татарстанда фәнне үстерү, гыйльми кадрлар әзерләү өлкәләрендә бик зур эшләр башкара. Төрле фән юнәлешләрендә (тарих, тел, әдәбият, археология, фольклор, педагогика һ.б.) галимнәрне берләштергән җәмгыятьләр оеша, милли тел, әдәбият, тарих фәннәрен үстерү концепцияләре булдырыла, Ибраһимов аерым галимнәргә темалар бүлеп бирү, аларны Казанга кайтарту, китаплар яздыру мәсьәләләрен хәл итә. Әйтик, Г.Нигъмәти һәм Г.Сәгъдинең 1925 елны Казанга чакырылуы, Җ.Вәлиди, Г.Гали, Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим һ.б. әдәбият тарихы фәнен булдыру эшенә тартылуы – моңа мисал. Шунысын да билгеләп үтү зарур: концептуаль яктан Ибраһимов позициясенә тәңгәл килмәгән фундаменталь хезмәтләр дә – әйтик, Г.Рәхим һәм Г.Гобәйдуллиннарның «Татар әдәбияты тарихы» – аның фатихасы белән дөнья күрә. Үзе дә тел белеме, татарча терминология, тарих мәсьәләләре белән шөгыльләнә. «Безнең юл» журналының редколлегия әгъзасы буларак, Г.Ибраһимов аның сыйфатын күтәрү, эчтәлеген баету турында да уйлана. Ул шөгыльләнгән барлык мәсьәләләр дә журнал сәхифәләрендә чагылыш таба.

Г.Ибраһимов үзе дә журнал өчен махсус мәкаләләр яза. Әйтик, журналның 1926 елгы 5-6 нчы (май-июнь) саннарында аның «Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы (Татар халык әдәбияты турында)» дигән мәкаләсе дөнья күрә. Анда халык авыз иҗатын өйрәнүнең мөһимлеге, аның татар әдәби теле өчен чыганак булуы турында сүз алып барыла, татар фольклорын өйрәнү тарихына караган кайбер күзәтүләр ясала. Ибраһимов гыйльми-әдәби җәмәгатьчелек алдына 4 максат куя: «1) халык авызыннан җыю; 2) төрле вакытта җыелып та басылмый ятканнарны, басылып, таркау хәлдә торганнарны бергә туплау; 3) һәммәсен, гыйльми метод белән тикшереп, системага салу; 4) аннан соң тәртипләп бастырып чыгару...»

Шул рәвешле, Г.Ибраһимов журналны татар әдәбиятының киләчәктә үсеш юнәлешләрен билгеләү өчен файдалана. Басманы әзерләүчеләр дә бу хакыйкатьне аңлап эш итәләр. Әйтик, «Безнең юл»ның 1928 елгы 2 нче саны Г.Ибраһимовның 20 еллык әдәби һәм гыйльми эшчәнлегенә багышлап чыгарыла.

Әгәр «Безнең юл» тарихына кабат XXI гасыр югарылыгыннан күз ташласак, журнал 1917 ел алып килгән инкыйлаби үзгәрешләр йогынтысында юллар чатында калган, иҗат эшенең кыйбласын билгеләүгә мохтаҗ татар әдәбиятына әйдаман, юл күрсәтүче үзәк булып күзалланыр. Аның сәхифәләрендә алып барылган әдәбият язмышына, бигрәк тә үткән мираска, татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә һәм бәяләүгә кагылышлы язмалар, аеруча әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр Ф.Бурнаш, Х.Вәли, Г.Гали, Г.Нигъмәти, Г.Рәхим, Г.Сәгъди, Г.Толымбайский һ.б.ларның әдәби барышка, аерым язучыларның иҗатына, аерым әсәрләргә карата язылган рецензияләре, күзәтү мәкаләләре, аналитик мәкаләләре, ахыр чиктә, татар әдәбиятының киләчәктә үсеш юнәлешләрен билгеләүгә хезмәт итәләр. Шул ук вакытта 1920-1930 елларда татарларда әдәбият тарихы фәне тууны да турыдан-туры журнал белән бәйләнештә карарга була.

## «Безнең юл»да – әдәбият һәм татар әдәбиятының язмышы турында

Чор атмосферасы – чуар, идеологик җитәкчелек басымлы булуга карамастан, журналны чыгаручылар беренче саннан ук анда үз заманының әдәби барышын мөмкин кадәр тулы чагылдырырга омтылалар. Шунысын да әйтергә кирәк, классик әдәбият тудыруның – чиктән тыш акрынаюы, яңа әдәбият тудырабыз дип илһамланган яшьләрнең сыйфатлы иҗат үрнәкләре бирергә еш кына тәҗрибәсе дә, таланты да җитмәү сәбәпле, татар әдәбияты, бигрәк тә аның XX йөз башы дәвере белән чагыштырганда, яхшы әсәрләргә кытлык кичерә. Шуңа күрә дә әсәрләрне сайлап

алу өчен мөмкинлекләр зур түгел. Әмма журналда шул чор әдәби процессында урын тоткан һәр язучы һәм шагыйрьнең һәр яңа әсәрен биреп барырга тырышалар.

Журналның беренче саны чыгуга 5 ел тулу уңае белән, бу чактагы мөхәррир Г.Нигъмәти «Язучылар үзләре һәм безнең әдәбият турында» дигән яңа рубрика башлап җибәрә һәм аңа кереш сүздә басма тирәсенә тупланган каләм әһелләренең исемнәрен атый: «Безнең юл»ның 5 елы тулганда каләм гаскәренең матур әдәбият армиясенә бераз тукталып китсәк, урынсыз булмас. Матур әдәбият дигәч тә, мин бөтен матур әдәбиятыбызны алмыйм. Аның да һәммә солдатларын алмыйм. «Безнең юл»да язышып, шуның күкрәгендә тәрбияләнеп, шунда үсеп чыкканнарын алам. Мондыйлар үзләре берничә дистәләргә тулар. Шулар арасында хәзерге татар революция әдәбияты күгендә йолдыз урынына тота алырлыклары да инде дистәгә җитә яза. Әнә шулар арасыннан мин бишәүне алмакчы булам. Бу бишәү: Кави Нәҗми, Такташ, Туфан, Толымбай, Кутуй. Болар үзләренең әдәби үсешләренең имтиханнарын «Безнең юл» битләрендә бирделәр. Иң матур әдәби парчалары шушы журналда басылып чыкты». Күрәбез, чор әдәбиятында әйдәп баручы иҗатчыларның исемнәре атала. Шушы рубрика астында Ш.Госманов, Г.Кутуй, К.Нәҗми, Һ.Такташ, Г.Толымбай, Г.Хәйриләрнең мәкаләләре басыла.

Һ.Такташ язмасын «Үзем һәм башкалар турында» дип исемли (*1927, № 6, 7*). Монда ул үзенең әдәбиятка килү юлын күзәтеп уза. Татар әдәбиятында кемнәрнең әсәрләрен укып баруы турында, аларга бәя биреп, санап китә. «Безнең юл» журналында бергә үстек» дип, Кави Нәҗмине, Туфан һәм Кутуйны телгә ала. Язмасын болай дип тәмамлый: «Безнең юл» мине үстерде. «Безнең юл» минем үсү бишегем иде. «Безнең юл»ның бәйрәме – минем һәм күпләрнең яхшы бәйрәме».

Чыннан да, Һ.Такташның «Урман кызы» шигыре «Безнең юл»да 1922 елның 4 нче санында басыла. Шуннан соң бер-бер артлы «Нәләт» (*1922, № 5*), «Күктән сөрелгәннәр» (*1923, № 6-7*) пәйда була. Әйтик, 1923 елда гына да журналда Такташ шигырьләре берничә тапкыр дөнья күрә. Аерым алганда, «Нәни разбойник» (*1926, № 1-2*), «Әйдә, энем!» (*1926, № 3*), «Пи-би-би-бип» (*1926, № 7-8*), «Мәхәббәт тәүбәсе» (*1927, № 2*), «Мокамай», «Алсу» (*1929, № 2*), «Таныш түгел елмаючы» (*1929, № 6-7*), «Таң җиле» романының баштагы өлеше (*1929, №12*) һ.б. укучыга башлап «Безнең юл»да тәкъдим ителәләр.

Журнал яшь талантларны урынсыз тәнкыйтьләрдән араларга да омтыла. Әйтик, Г.Нигъмәти «Безнең юл»ның 1929 елгы 5 нче санында басылган «Имзасыз һәм җавапсыз мәкалә турында» дигән мәкаләсендә Һ.Такташның татар әдәбиятындагы урынын гаять югары бәяләп, «Берәү» имзасы белән язылган «Инде ачык әйтергә кирәк» дигән пасквильгә җавап бирә.

Гомумән алганда, «Безнең юл» әдипләрнең шигырьләрен яки проза әсәрләрен генә тәкъдим итеп калмый, ул аларны журнал тирәсенә туплап, үз иҗатлары, татар әдәбияты, аның бүгенгесе һәм киләчәге, әдәбият нинди юл белән үсәргә тиешлек турында ярым-публицистик язмалар бастыруны гадәткә кертә. Шулай журнал әдәби барыш турында сөйләшү оештырып, шул процесска йогынты ясаучы басма булырга омтыла.

## Заман һәм әдәби журнал

Коммунистлар партиясе 1920 еллар ахырына ил тормышының барлык өлкәләре, шул исәптән әдәбият-мәдәният белән дә турыдан-туры җитәкчелек итә. Башка әдәбиятлар кебек, татар әдәбияты да рәсми идеологиягә буйсындырыла. Илдә барган яңа тормыш төзелеше, сыйнфый көрәш, партиянең үзгәрешләрне җитәкләп баруы – әдәбиятта уңай яктан гына яктыртылырга тиешле төп темалар булып, шушы юнәлештәге «яңа әдәбият» тудыру бурычы язучыларның идея-эстетик эзләнүләрен чикли. Язучылар тормышны реаль сурәтләүдән, андагы тискәре якларны укучыга җиткерүдән читләштереләләр.

Әдәби журналлар, шушы берьяклылык һәм тенденциозлык сәбәпле, газеталар яки агитация китапчыклары бурычларын үти башлый.

1930-1932 елларда «Безнең юл» журналы икегә бүленә. Аның берсе «айлык әдәбият, сәясәт һәм тәнкыйть журналы» буларак «Яңалиф» исеме белән басыла. Татар язуының яңалифкә – латин хәрефләренә күчүе белән бәйле була ул исем.

Журналның мәсләген билгеләп, аның беренче санында болай диелә: ««Яңалиф»нең үз алдына куйган бурычлары: әдәбият белән сәнгатьне өйрәнү проблемаларын марксизмча тикшерү; матур әдәбият һәм сәнгать өлкәләрендә буржуазия һәм милливак буржуазия һәм башка шундый реакцион тенденцияләргә каршы рәхимсез көрәш алып бару; тәнкыйть һәм художество методы мәсьәләләрен тикшерү.

«Яңалиф» түбәндәге бүлекләрдән тора: сәясәт (сәяси обзорлар, мәкаләләр, очерклар), матур әдәбият (романнар, повестьлар, поэмалар, шигырьләр, очерклар һ.б.), әдәбият өйрәнү (методология, әдәбият тарихы, фольклор, телне өйрәнү мәсьәләләре, әдәби мемуарлар, истәлекләр, биографияләр), сәнгать (театр-кино, музыка, скульптура, живопись, репертуар, драматургия мәсьәләләре), культура, көнкүреш библиография, тәнкыйть һәм хроника» (*1930, № 1*).

Бу елларда «Яңалиф»нең мөхәррире булып эшләгән язучы, тәрҗемәче, Фатих Сәйфи-Казанлы да, аны алыштырган, совет чорының күренекле тәнкыйтьчесе һәм әдәбият галиме Галимҗан Нигъмәти дә татар әдәбиятының традицияләрен саклау һәм яңалыкны җиткерү ягыннан «Безнең юл»да табылган «алтын урталыкны» сакларга омтылалар.

Бу урында бер мисалга тукталып китү кызык булыр: ул – Һ.Такташның «Яңалиф»тә басылган (*1931, № 10*) «Партиясез» һәм партияле шигырьләр турында» язмасы. Шагыйрь аның жанрын үзе «Иҗат хатлары» дип билгели. Күләмле язма әдәбиятка куела торган таләпләрне билгеләп башлана: «Бүгенге пролетариат әдәбияты ул безнең уйларыбызның хәрәкәте, идеяләребезнең омтылышы булырга тиешле. Без шагыйрьләрдән менә шул идеяләребез өчен булган көрәштә аерым бер хезмәтне үти ала торган җанлы шигырьләр сорыйбыз. Без язучылардан яши һәм хәрәкәт итә торган һәм укучыларның уй юнәлешләрен хәрәкәт иттерә торган әсәрләр таләп итәбез!..»

Шактый пафос белән әйтелгән шушы сүзләрдән соң Такташ болай дип белдерә: «Без сәнгатьтә беренче урынга партиячелекне куябыз».

Шундый керештән соң автор татар әдәбиятына күчә һәм анда дүрт кимчелекне аерып чыгара: «1. Шигырьне рифма төзү итеп кенә аңлау»; «2. Хикәяләрне, драмаларны язган вакытта схема рәвешендә язу, типларны начар типлар, яхшы типлар итеп икегә генә бүлеп йөртү»; «3. Турыдан-туры формализм»; «4. Әсәрне конкрет бер идея нигезенә кормау яки фикер, идея ягы бик түбән булуы». Шагыйрь фикеренчә, «кызыл», «пафослы» булып та, яңа фикер бирә алмаган әсәр әдәбият була алмый. Ул мисалга Г.Теләшевның «Җиңү чорында» һ.б. шигырьләрен алып анализлый һәм мондый әсәрләрне «беспартийный» шигырьләр дип атый. Тематика-проблематика, идея ягыннан шигырьгә куела торган таләпләрне санап һәм шәрехләп уза. Моннан тыш, поэтика мәсьәләсенә кагылып, С.Рәфыйков, Б.Мокамай шигырьләре мисалында идеягә тиң форма табу турында сөйли. Шул рәвешле, Такташ, әйтерсең лә, үз иҗатына үзе куя торган таләпләр яктылыгында яшь татар шагыйрьләренә осталык дәресе бирә.

Әмма әдәбият тарихына караган яки әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә дә акцентлар үзгәрә. Әйтик, 1931 елгы «Яңалиф»нең 5-6 нчы саннарында Г.Ибраһимовның «Әдәбият тарихыбызның кадерле битләре болай таптатылмасын иде» дигән язмасы дөнья күрә. Ул Г.Гобәйдуллинның Г.Колахмәтов турындагы «Яңалиф» журналының 1930 елгы 6 нчы санында басылган «Революционер Гафур Колахмәтов турында истәлекләрем» мәкаләсенә тәнкыйть итеп язылган. Шактый тәкәллефсез, гаепләү рәвешендәге бу

язмада Г.Гобәйдуллин һәм Ф.Агиев адресына чор вазгыятенә бәйле куркыныч ишетелә торган гаепләүләр ташлана.

Икенче тармак булып аерылып чыккан «Атака» – Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе (ТАПП) органы булып ачыла. 1928 елның язында оештырылган ТАПП шул чордагы рәсми идеологияне әдәбият өлкәсендә аеруча актив үткәрүче һәм әдәби хәрәкәттә әйдәп баручы үзәк булып таныла. Аның төп органы «Атака» журналы да – ачыктан-ачык яңа әдәбият тудыру, мирастан баш тарту шигарен күтәрә. Журналның беренче санындагы (*1930, № 1*) кереш мәкалә-мөрәҗәгатьтә («Пролетариат язучылары ассоциацияләре янындагы бөтен татар секцияләренә һәм бөтен татар пролетариат язучыларына») аның мәсләген-кыйбласын билгеләп, җаваплы мөхәррире Г. Гали, редакцион коллегия һәм ТАПП идарәсе исеменнән, болай дип яза: ««Атака»ның төп бурычы партиянең матур әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә тоткан сәясәтен тормышка үткәрү өчен, пролетариат әдәбиятының гегемониясе өчен көрәшкә кайтып кала. Интернационал культура өчен көрәш юлында, буржуа милләтчелегенә, солтангалиевчелеккә, әдәбиятта уңлык һәм аның белән килешүчәнлек күренешләренә, шулай ук «сул» бөгелешләренә каршы аяусыз атака алып баруны бу журнал үзенең үзәк бурычлары рәтенә кертә. (...) Социализм төзелешенең бөтен фронтларында реконструкция чоры булган бүгенге чор – пролетариат әдәбияты хәрәкәтенең үзенә җавап бирерлек хәлдә булуын, аның сафларында да – кирәк темп, кирәк сыйфат һәм кадрлар мәсьәләсендә, шулай ук, иң беренчедән, пролетариат культурасының бөтен сыйнфый дошманнарына каршы кискен көрәш мәсьәләсендә булсын, – ныклы эш, каты көрәш сорый. Бу эштә һәм көрәштә татар пролетариат әдәбияты хәрәкәтенең турыдан-туры үз трибунасы булган «Атака» журналы зур урын тотарга тиеш булачак» һ.б.

Чыннан да, «бөтен татар пролетариатының интересын» яклауны шигарь-лозунг итеп алган «Атака» – үзе совет идеологиясенә туры килмәгән дип санаган һәр нәрсәгә каршы һөҗүм башлый һәм моны шактый тупас формада алып бара. Моны, хәтта, «Безнең юл» белән даими эшләп килгән Г.Ибраһимов язмалары мисалында да күрергә мөмкин. Әйтик, «Атака»ның 1931 елгы 1нче санында басылган «Г.Колахмәтов большевиклар белән эшләде» мәкаләсе татарларда революционерлар булуны ассызыклап язылган. «Атака» журналының 1931 елгы 3нче санында басылган «Әдәби программ турында» язмасында завод-фабрикалардагы башлангыч әдәби түгәрәкләр өчен программалар хакында сүз бара. Төп мәсьәләләрнең берсе төсендә әдәбиятта сыйнфыйлык теориясен аерып чыгарып, Г.Ибраһимов 1922 елда Җ.Вәлиди белән бәхәсне искә төшерә, әдәби әсәрләрне сәяси-сыйнфый хәрәкәтләргә баглап, сыйнфый яктан бәя бирү, шулай анализ ясау гына мөмкин дип белдерә. Ибраһимов ачыктан-ачык галимне түбәнсетү юлына баса, аның гыйльми позициясен буржуазиянең сыйнфый көрәш алып баруы дип атый. Бу мәкаләдә, Вәлидине гаепләү аша – яңа төзелә торган тормыш барлык милләтләр өчен уртак булган кебек, әдәбиятлар да бер, әдәбият белеме дә уртак, биредә фикер төрлелеге булырга мөмкин түгел дип, марксизм ысулына туры килә торган гомум бер поэтика тудыру эше алып бару белән чикләнергә, әдәбиятны шулай укытырга кирәклеге әдәби җәмәгатьчелеккә җиткерелә. Гомумән, «Атака»ның һәм сәяси, һәм әдәбият-сәнгатькә, аларның максаты һәм вазифалары, әсәрләрне бәяләү критерийлары мәсьәләләренә мөнәсәбәте сыйнфыйлык рухы белән сугарыла.

Мөхәррирләр Г.Гали, К.Нәҗми, З.Гали журналның яшь язучылар әсәрләрен бастыру, тикшерү, шул юл белән яңа совет әдәбиятының иҗат принципларын булдыру турында уйланалар. Эчтәлектә, күбрәк, яңа тормыш төзү, завод-фабрикалар, колхоз-совхозлар тормышын яктыртуга кагылган, шуларда хезмәт куйган аерым кешеләр турында сөйләгән очерклар зур урын алып тора. Шулай да, ТАППның һәм «Атака»ның татар әдәбиятына татарлар яши торган чит төбәкләрдән талантлы

каләмнәрне тарту, гомумән, татарларны милли мәдәни үзәк тирәсенә берләштерү эшен аерып билгеләп үтәргә кирәк. Мәскәүдә, Уралда, Уфада, Себердә, Самарада ТАППның татар бүлекләре оештырыла. Ассоциация илдәге социализм төзелеше белән якыннанрак танышу өчен язучыларны колхозлашу чоры авылларына, илдәге яңа төзелешләргә, завод-фабрикаларга дәвамлы командировкаларга җибәрүне гадәткә кертә. Мисалга, «Атака»ның 1930 елгы 2нче санында (август) Һ.Такташның «Тыңла, ТАПП!» дигән, 1930 елның 3-23 июнендә Донбасска иҗади командировкага барып кайткач язган очеркы шундыйлардан. Донбасс шахталарындагы хәлне, эшчеләрнең рухи ихтыяҗлары турында язып үткәннән соң, шагыйрь түбәндәге тәкъдимнәр белән чыга: «ТАПП членнарыннан бригадалар оештырып, шахтёрлар арасына җибәрергә, аларның шахтёрлар тормышын өйрәнү нәтиҗәсендә тудырган әсәрләрен альманах итеп чыгарып барырга»; «ТАППның танылган каләм көчләрен» шахтёрлар янына озак срокка җибәрергә; Шахтёрлар арасында туган язучыларны үстерүне «Атака» журналы ярдәмендә башкарырга; Эшчеләр яшәгән җирләрдә театр репертуарлары өчен әсәрләр язуны ТАПП планына кертергә».

Күрәбез, биредә көн кадагына суккан иҗтимагый характерлы мәсьәләләр үзәккә куелса да, аларның, ахыр чиктә, татар әдәби процессын баетуга китерәчәге шик уятмый. Әмма журналның эш стиле, агрессив һәм гаепләү тоны күп кенә иҗатчыларны аннан читләштерә. Соңрак бу хакта язып узучылар да була.

Мәсәлән, 1972 елны «Казан утлары» журналының 5нче саны басманың 50 еллыгына багышлап чыгарыла. Анда бик күп язучылар, тәнкыйтьчеләр – М.Әмир, Г.Әпсәләмов, З.Нури, Ф.Хөсни, А.Шамов, Ә.Еники һ.б. үзләренең журнал турында истәлекләре белән уртаклашалар.

Ә.Еники тагын 20 елдан соң «Чорлар аша» дигән язмасында болай дип яза: «Егерменче елларның ахырында инде «социализм өчен бөек көрәш» чоры башланды. Журналның исеме дә «Безнең юл»дан «Атака»га әйләнде. Ләкин мин бу вакытны «бөек кыйнау» чоры дип атар идем. Махсус һәм чамасыз көчәйтелгән «көрәш» Сталин тарафыннан халыкларны алдап һәм көчләп буйсындыру өчен чыгарылган бер сылтау гына иде. Бу кыйнау яки кыйналудан берәү дә читтә кала алмады. Гәзитә-журналларда бик әшәке яла ягулар, гаеп тагулар, фаш итүләр башланды. Әле кайчан гына бергә аралашып йөргән язучылар да теге яки бу каләмдәшен милләтчелектә, оппортунизмда, сыйнфый уяулыгын югалтуда гаепләп зур-зур мәкаләләр белән чыктылар, һәркем шик астында, күзәтү астында. Дәшми калу үзе дә куркыныч була башлаган иде. Менә мин дә, үсмер чагымнан ук, «Ленин бабай юлына» чын ихластан ышанырга тырышкан, мәгәр чыгышым белән «чит элементтан саналган яшь кенә бер «каләм тибрәтүче» идем. Чит булуның җәфасын миңа инде татырга да туры килгән иде (укуны ташларга мәҗбүр иттеләр). Ихтимал, шуңа күрәдер, ә дөресрәге, хәзер купкан «бөек көрәшнең» хаклыгына ышанмаудан, минем кумәкләшеп кыйнау кампаниясенә һич тә катнашасым килмәде. Киресенчә, бөтен күңелем белән мин кыйналучылар ягында идем. Адәм балаларына нинди зур фаҗига килгәнен күрмәмешкә салыну мөмкин түгел иде. Әмма ничек тә итеп бу фаҗигадән сакланып калырга. Хәзерге шартларда моның өчен бер генә юл – әдәбияттан китеп тору кирәк иде. Мин әле әдәбиятка сыңар аягым белән генә басарга өлгергән идем. Чын язучы булып танылганым да юк әле, шуңа күрә чигенү минем өчен бер дә читен булмады. Вакытлычамы, әллә бөтенләйгәме – мин язучы булудан туктадым. Әдәбияттан китеп торуым кимендә бер ун елга сузылгандыр. Бу утыз белән кырыгынчы еллар арасы, һәм бу еллар арасында кешеләрнең нинди коточкыч югалтуларга, рухи имгәнүләргә дучар ителгәнен сөйләп торасы да юк. Бары җиһан сугышы башланып, фронтка эләккәч кенә мин яңадан кулыма каләм алдым. Фронттан җибәргәләгән хикәяләрем «Совет әдәбияты»нда (журналның «Атака»дан соңгы исеме) ничектер ансат кына басылып та чыкты. Авыр сугыш әдәбиятка карата идеология тезгенен бераз бушатырга мәҗбүр иткән булса кирәк, шуңа күрәдер инде,

һәр язучының, элек кем булуына карамастан, патриотик рухтагы әйберләренә урынны кызганмыйча бирәләр иде. Моның бик ачык мисалы – мәрхүм Фатих Кәрим иҗаты. Төрмәдән фронтка озатылган шагыйрьнең һәр язганы матбугатта чыга торды» (*1992, № 5*).

Моннан да төгәл итеп бу дәвер вазгыятен әйтеп-бәяләп бирү мөмкин түгелдер!

Шул рәвешле, журналның ике мөстәкыйль басма буларак нәшер ителү тәҗрибәсе уңышсыз төгәлләнә. Бер яктан, ике басма үзләренең бер-берсеннән аерылып торырлык юнәлешен-кыйбласын таба алмыйлар. Моның урынына, гамәлдә татар язучыларын ике төркемгә аеру, аларны бер-берсенә каршы кую, шул рәвешле ике журналның репертуарын туплау килеп чыга. Шуңа күрә, озак та үтмәстән, кабат бер журналга берләшү – иҗат кешеләре, зыялылар тарафыннан хуплап каршы алына.

## «Совет әдәбияты» дәвере

Партия Үзәк Комитеты 1932 елның 23 апрелендә «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында» дигән махсус карар кабул итә, аны тормышка ашыру өчен СССР язучыларының беренче съездына әзерлек эшләре башлана. Әдәби журналыбызның «Совет әдәбияты» буларак, 1933 елның башыннан яңа дәвергә килеп керүе шуның белән бәйле була.

1934 елны үткәрелгән съездда совет әдәбиятының төп иҗат методы дип социалистик реализм игълан ителә, «әдәби хәрәкәт белән идарә итү» өчен СССР Язучылар союзы оештырыла. Шул ук елда Татарстан Язучылар берлеге төзелә. Бу оешмалар да, журнал да – турыдан-туры партия күзәтүендә эшли. Басманың төп авторлары булып инде каләм чарлаган М.Әмир, Ф.Бурнаш, Г.Гали, М.Гали, И.Гази, Ш.Камал, М.Крыймов, М.Максуд, Г.Нигъмәти, К.Нәҗми, Ф.Сәйфи-Казанлы, К.Тинчурин, Г.Толымбай, Х.Туфан, И.Туктаров, Ә.Фәйзи һ.б. санала. Татар әдәбияты эзләнүләр чорын, яңа әдәбият тудырабыз дип, юлсыз бәргәләнүләр этабын кичеп чыккан кебек тоела. «Совет әдәбияты» журналында татар әдәбиятының алтын фондына керәчәк әсәрләр дә, яшь язучы-шагыйрьләрнең беренче әсәрләре дә басыла тора. Г.Әпсәләмов, С.Баттал, М.Җәлил, Ф.Кәрим, С.Хәким һ.б. шушы журналның фатихасы белән зур әдипләр булып җитешә.

1933 елны «Совет әдәбияты» журналының 2-3нче санында Г.Ибраһимовның иң соңгы язмаларыннан берсе булган «Карт шагыйрьнең яхшы сайланмасы» басылып чыга. Ул М.Гафуриның Казанда нәшер ителгән «Сайланма әсәрләр»енә рецензия итеп язылган була.

1972 елны «Казан утлары» журналының 2нче санында, «Совет әдәбияты» журналының тарихын искә төшереп, 1936 елны журналга җаваплы секретарь булып килгән Г.Бәширов мондагы атмосфераны, редакция урнашкан, «карлыгач оясы» дип йөртелгән кечкенә бүлмәне, анда эшләүчеләрне шактый тулы, күз алдына килерлек итеп тасвирлый. «Әмма мине иң мавыктырганы – бу кечкенә бүлмәдәге кешеләрнең зур ваем белән яшәүләре булды. Алар һәр уңышлы әсәргә генә түгел, истә калырдай һәр яңа образга куанып, әдәбиятның якты киләчәге белән рухланып яшиләр, үзләрен тормышның вак-төягеннән өстә тоталар иде». Журналны әзерләүче коллективны күрсәтеп, язучы болай дип яза: «Ул елларда журналны һәм, гомумән, татар совет әдәбиятын әйдәп баручылар журналның җаваплы редакторы Гомәр Гали, редколлегия членнары Галимҗан Нигъмәти, Гумир Толымбай (кайберәүләр язганча, Гомәр түгел), Кәрим Тинчурин, Кави Нәҗми, Шәриф Камал булдылар».

Өлкән язучының кайбер бәяләре бүген аерым бер үкенеч хисе дә уятырлык. Әйтик, «Журнал редакторы Г.Гали белән профессор Г.Нигъмәти әдәби хәрәкәтнең башында торучы күренекле галимнәр буларак, партия карарларын тормышка ашыруда зур тырышлык һәм принципиальлек күрсәттеләр, әдәбиятның үсешенә

тоткарлык итә торган натурализм, формализм кебек зарарлы агымнарга каршы аяусыз көрәшеп килделәр» дип, язучы Г.Галинең 1936 елда язучылар җыелышында ясалган, «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 4нче санында басылган чыгышыннан бер өзек китерә: «Безнең социалистик матур әдәбиятыбыз иң югары идеяле, үзенең формасы белән иң бай, иң матур әдәбият булырга тиеш. Шуның белән бергә, бу байлык һәм матурлык хезмәт халкы йөрәге белән тоташкан булырга тиеш».

Шушы фикерне дәвам итеп, Г.Бәширов редакциягә Мәскәүдә яшәүче күренекле язучы М.Галәүнең килүен тасвирлый, сүзен болай дәвам итә: «Г.Гали яныннан чыкканда, кунагыбыз караңгы чырайлы иде. Ул вакытта мин аның сәбәбен төпченмәдем, болай гына чамаладым. М.Галәү заманында «Кармак» исемле юмористик журнал чыгарган, нәширлек белән дә шөгыльләнгән, халык арасында мәгърифәт тарату максаты белән, аз-маз китаплар да саткалаган, диләр иде. Г.Гали исә, сыйнфый мәсьәләләргә бик сизгер һәм җитди караучы ифрат туры коммунист булу сәбәпле, язучының кайчандыр чит сыйныф әһелләренә хас эш белән шөгыльләнүен гафу итә алмагандыр, күрәсең».

Г.Толымбайны хәтерләп, язучы шулай ук көтелмәгән бәягә килеп чыга: «Таланты һәм гаҗәеп эшчәнлеге белән заманында беренче биш язучы исәбендә йөргән, барлыюклы унбер-унике еллык иҗат гомере эчендә утыз биштән артык китап чыгарган бу галим һәм әдип әдәбиятта нигә сизелерлек эз калдырмады? Ничек ул шул кадәр тиз онытылып өлгерде? Аның әсәрләре вакыт сынавын үтә алмаслык сыек, зәгыйфь булдылармы? Әллә алар ясалма иделәрме? Бәлки, шулайдыр? Ихтимал, Толымбайның сулагай якка кизәнүен, Фатих Әмирханны тартып-сузып һәм көчәнеп буржуаз язучысы ясавын, чамадан тыш кызарып китеп, телне сыйныфларга бүлеп ташлавын тарих гафу итә алмагандыр? Ихтимал, шулайдыр».

Чыннан да, «Совет әдәбияты» журналы өлешенә ил тарихындагы куркыныч сынаулар чоры туры килә. 1937–1938 елларда халык та, каләм әһелләре дә шомлы бер атмосферага эләгә. Советлар идеологиясен хуплаган, чын күңелдән яңа хакимияткә хезмәт иткән байтак шәхесләр кулга алына, төрмәләргә-лагерьларга ташлана, юк ителә яки рухи сындырыла. М.Әмир, Ф.Бурнаш, Җ.Вәлиди, М.Галәү, Г.Гали, Ш.Усманов, Л.Гыйльми, Г.Ибраһимов, Ф.Кәрим, Ф.Кәрими, К.Нәҗми, Г.Нигъмәти, С.Рәфыйков, Г.Рәхим, И.Салахов, С.Сүнчәләй, Ф.Сәйфи-Казанлы, К.Тинчурин, Г.Толымбай, Х.Туфан ... – татар әдәби барышының алгы сафы бу!

Журналның эчтәлегенә зур зыян килә. Элеккеге мирасны – «буржуаз» әдипләрнең әсәрләрен дә, «шик төшкән» язучылар каләменнән төшкән текстларны да укучыга тәкъдим итәргә ярамый! Әсәрләр сайлау мәсьәләсендә редколлегиянең нинди хәлдә калганлыгын күзаллау өчен «Совет әдәбияты»ның 1937 елның 5нче санында басылган «Халык дошманнарының һәм аларның калдыкларының йөзен ахырынача ачарга!» дигән язмадан бер өзек китереп узарга мөмкин: «Союз җитәкчелеге күз буяу өчен Ф.Сәйфине союз членлыгыннан чыгара. Ләкин озак та үтми, аны яңадан союзга алалар һәм аның, шулай ук халык дошманнары Ш.Усмановларның, Г.Толымбайскиларның контрреволюцион әсәрләрен «Совет әдәбияты» журналында басып чыгаралар. Әлегә кадәр иҗаты һәм биографиясе караңгы булган Туфанның, Иптәш СТАЛИН биографиясеннән кабахәт рәвештә көлә торган «Ант» поэмасы да «Совет әдәбияты» журналында урнаштырыла. Халык дошманнары Г.Галиләр, К.Нәҗмиләр бу бозык әсәрне шедевр итеп мактарга тотыналар» (ал.: *Сүнмәс утлар балкышы: Мең санлы хәзинәдән. Казан: «Идел-Пресс» полиграфия-нәшр.комплексы, 2006. 215 б.*). Һәр санда диярлек «халык дошманнары» дип гаепләнгән әдипләрне фаш иткән коточкыч язмалар басылып тора. Әйтик, 1937 елның 6-7нче санында «Матур әдәбиятны дошман калдыкларыннан тазартырга!» дигән баш астында Татарстан Совет Язучылары Союзы идарәсенең Х.Туфан һәм Ф.Кәримне Язучылар берлегеннән чыгару һәм гаепләү карары урнаштырыла.

Журналда публицистик, сәяси-иҗтимагый характердагы язмалар, рус теленнән тәрҗемә әсәрләрнең саны тагын да арта. Ул яңа тормыш төзү барышын яктырткан хроникаль елъязмага, көндәлек вакыйгалар белән таныштыра торган газетага охшый башлый. «Совет әдәбияты»ның 1937 елгы 6-7нче саны тулысынча диярлек М.Горький иҗатына багышлана.

Әмма журналны торгынлыкта дип кенә карау хакыйкатькә хилафлык булыр иде. Басма татар әдәбиятының борынгы иң күренекле җәүһәрләре белән таныштыруны һич тә читкә куймый. 1940 елны «Совет әдәбияты» журналының 11нче һәм 12нче саннарында Н.Исәнбәтнең «Татар халкының эпосы «Идегәй» дастанының 500 еллыгы» дигән гыйльми язмасы белән бергә «Идегәй» тексты дөнья күрү зур бер вакыйга була. Дастан татар халкының шанлы тарихына, аның рухи хәзинәләре байлыгына, гүзәллегенә мәдхия булып яңгырый.

Күрәсең, совет идеологлары да моны аңлый: ВКП(б) Үзәк Комитетының татар галимнәрен милләтчелектә, Алтын Урда чорын идеаллаштыруда, «ханнар-феодаллар эпосы» «Идегәй»не популярлаштыруда һәм артык бизәп күрсәтүдә гаепләгән «О состоянии и мерах улучшения массово-политической и идеологической работы Татарской партийной организации» дигән 1944 ел 9 август карары сугыш елларында, патриотик дулкында күпмедер мөмкинлекләр ачылган тарихи тематиканы кабат ябып куя. Тарихи тематиканы гына түгел, бәлки төрки-татар тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү эшен дә тоткарлый, цензура кысаларына куып кертә. Әмма «Совет әдәбияты» инде «Идегәй»не татар укучысына илтеп ирештергән була!

Бөек Ватан сугышы башланып, татар әдипләренең кулына корал алырга мөмкин булганнары барысы да фронтка киткән, халыкта икмәк һәм исән калу кайгысы беренче урынга чыккан бер вакытта да журнал яшәүдән туктамый. Алай гына да түгел – ул, сугышчылар белән бергә, иң алгы сафта! Фронттагыларга да, тылда хезмәт куючыларга да, бердәнберләрен сугышка озаткан ата-аналарга, хатын-кызларга һәм балаларга да өмет утын сүндерми сакларлык, дошманга каршы көрәшергә көч бирерлек, сагынуларга, кайгыларга дәва булырлык дөрес сүзләр таба торган иң олы терәк, рухи азык, маяк булып күзаллана.

Бу хакта «Казан утлары» журналының 1972 елгы 5нче санында басылып чыккан, сугыш чорында басманың мөхәррире булган Гази Кашшаф истәлекләреннән дә үтемлерәк итеп әйтеп булмас. Ул кышын да ягылмаган бүлмәдә редакцион коллегияне тулысынча диярлек фронтка озаткан берничә кешенең журналны басмага әзерләве, 1943 елның җәенә нәшер итәргә акча табылмаган 7 санның типографиядә җыелуы, шундый шартларда да аның ябылмавы, яңа саннарны әзерләүнең өзелмәве, берәр генә данә булса да журнал бирегез дип, хәрби эшелоннардан – офицерларның, авыллардан – җитәкчеләрнең сорап килүләре турында сөйли. Сугыш чорында журналның төп авторларын – күбесе үзләре дә сугыштагы Г.Әпсәләмов, А.Әхмәт, И.Гази, Х.Госман, Ә.Ерикәй, Ә.Исхак, Р.Ишморат, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, Ш.Маннур, Ш.Мөдәррис, М.Садри, С.Хәким, Г.Хуҗи, А.Шамов һ.б. каләм әһелләренең эзлекле ярдәмен олы рәхмәт хисләре белән телгә ала. Язма мондый сүзләр белән тәгалләнә: «Совет әдәбияты»ның һәрбер саны, кимчелекләре булуга да карамастан, теткәләнеп беткәнче укыла, кулдан-кулга күчә. Тылдан бик кадерле бүләк төсендә фронтка юнәлә. Хәрби частьлардан махсус соратып алалар, кичектерми фәлән-фәлән саннарын җибәрегез дип таләп итәләр. Әгәр дә алар сораган саннар барып җитмәсә, шактый каты шелтәле сүзләр белән хат җибәрәләр. Мондый хатларны без тылдан да ала идек, очрашу вакытларында да шушы мәсьәлә күтәрелә иде. Шул рәвешчә, «Совет әдәбияты» журналы сугыш елларында халыкның юлдашы, сердәше, юанычы һәм куанычы булды».

Җиңү шатлыгы белән бергә, әдәби процесска шактый гына каләм әһелләре әйләнеп кайта. Сугышчы – татар кешесе, җиңүче – татар кешесе образы журнал

битләрендә билгеле бер рухи халәт, атмосфера тудыруга хезмәт итә. «Совет әдәбияты» журналының күләме арта, эчтәлеге төрләнә.

Шуның белән бергә, ВКП(б) Үзәк Комитетының 1946 елның 14 августында «Звезда» һәм «Ленинград» журналларын тәнкыйтьләп чыккан карары татар журналларына, Татарстан совет язучылары берлегенең эшенә дә кагыла. Язучыларның, җитәкчеләрнең хезмәтенә карата «зур кимчелекләр бар», «тиешенчә җитәкчелек итми», «буржуаз язучының чын йөзен ачмыйлар», «зур хаталар җибәрелә» кебек мөһерләр сугыла. Бу, әлбәттә, җиңү шатлыгы дулкынында илһамланып иҗат иткән, әле генә булып узган сугыш фаҗигаләрен дә, илне төзекләндерү, яңа төзелешләр, Татарстанда нефть промышленносте барлыкка килү һ.б. темаларга әсәрләр язарга алынган каләм әһелләренең иҗат җимешләренә дә тәэсир итә, аларны кабат совет идеологиясенең тар кысаларына куып кертү омтылышы ясала. Бу чорда әдәбиятның эстетик-форма ягы социалистик реализм чикләүләреннән зур зыян күрә. Татар язучылары шушы шартларда әдәбиятның сәнгатьлелеген, укучыга тәэсир итү һәм ышандыру көчен саклап калу хакында да уйланалар. Бу мәсьәләдә дә журнал аларга фикер әйтү мәйданы булып кала. Әйтик, «Совет әдәбияты» журналында басылган «Уйлану сәгате» мәкаләсендә (*1953, № 10*) Ш.Мөдәррис болай дип яза: «Лирикада кеше җанын бирү урынына, без күп очракларда тышкы эффект белән мавыктык. Кызны матур дидек, аның кыйгач кашын, алсу йөзен, бөдрә чәчен, эшчән кулларын җырладык. Егетне, әлбәттә, батыр дидек. Нишлисең? Традиция! Геройлардан без шәп сөйләтәбез, ләкин аның йөрәге читтә кала. Сүзен ишетәбез – хисен сизмибез. Кеше урынына – кибетләрдә витринага куелган көяз курчак килеп чыга».

Тагын бер мисал. 1956 елны «Совет әдәбияты» журналында Н.Фәттахның беренче зур әсәре – «Сезнеңчә ничек?» романы дөнья күрә. Социалистик реализм таләпләре белән тулысынча яраша алмаган әсәр авторны һәм аның иҗатын кысрыклауга сәбәп була. Бу урында сүзне язучының үзенә бирергә мөмкин. 2001 елны шушы әсәрне кабат бастырганда әзерләнгән керештә ул болай яза: ««Сезнеңчә ничек?» алтмышынчы елларда татар әдәбиятында зур яңалык буларак дан казанды. Китапны яшьләр дә, урта буын, өлкәннәр дә яратып укыдылар. Ул вакытта китап укучылардан күп кенә хатлар килде. Рәсми даирәләрдә роман шактый ыгы-зыгы тудырды. Әсәрне тикшерүгә багышланган җыелышларда, вакытлы матбугат битләрендә яшь язучыга карата тәнкыйть сүзләре дә әйтелә башлады. Төп тәнкыйть шуңа кайтып калды: Н. Фәттах, имеш, тормышны бозып сурәтләгән, романда, имеш, Коммунистлар партиясенең җитәкче роле күрсәтелмәгән *(Фәттах Н. Сезнеңчә ничек? // Фәттах Н. Сайланма әсәрләр. 5 томда: 1 том. -Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. Б. 11)*. Язучыларның еллык җыелышларында, әдәбиятка кагылышлы чараларда әлеге әсәрне тәнкыйтьләү гадәти бер күренешкә әверелә, аның авторы советчыл тормышны каралтып күрсәтүдә гаепләнә.

Әмма, ничек кенә булмасын, чорның иң күренекле әдәби әсәрләре «Совет әдәбияты» журналында басыла! М.Гайнуллинның «Н.Г. Чернышевскийның татар телендәге кульязмалары» (1954, № 6), И.Рәминең татарларның 1905 елдан соңгы рухи күтәрелеше хакындагы «Чәнечкеле еллар үтә килгәндә» (*1960, № 5*) кебек материаллар шушы журналда киң катлау укучыларга барып ирешә! Димәк, «Совет әдәбияты» да татар мәдәниятенә тугры хезмәт итүдән туктамый, нинди генә катлаулы хәлләрдә дә үз укучысы өчен әдәби-мәдәни мәгълүмат чыганагы гына түгел, бәлки фикердәш булып кала. Моның белән журнал, шиксез, редакция хезмәткәрләренә бурычлы!

Ә.Еникинең югарыда телгә алынган «Чорлар аша» мәкаләсендә (*1992, № 5*) бу хакта мондый хатирәләр бар: «Сугыш бетүгә бер-ике ел да үтмәгәндер. Сталинның күптән көйләнгән, тик сугыш вакытында гына бераз тыныбрак торган репрессия тегермәне яңадан ходка җибәрелде. (...) Сугыш вакытында әзрәк бушый төшкән тезгеннең яңадан каты тартылганын без – язучылар, бик тиз сиздек. Гәзитә-журнал һәм нәшрият редакторларына идея-политик таләпләр бик нык артты, электән үк

«уяулык» күрсәтергә яратучы Главлитның әдәби әсәрләргә бәйләнүе аеруча көчәйде. Бигрәк тә аерым язучыларга карата саклык күрсәтүне ачык сизәргә мөмкин иде. Мин моны үз җилкәмдә дә бик тиз татыдым. Кырык алтынчы елда чыгып яткан кечкенә китабымнан «Ялгыз каз» хикәясен үземә әйтмичә генә алып ташладылар. Әле кайчан гына журналда берсүзсез басылган хикәядән нинди куркыныч гаеп тапканнардыр – миңа аңлатып та тормадылар. Ярамый, вәссәлам! Һәм иң гаҗәбе, сугыш вакытында язганнарымны җиңел генә чыгарып барган «Совет әдәбияты»на үземчә шактый көчле язылган «Тауларга карап» хикәясен үткәрә алмадым. Бу хикәядән микроскоп аша карап та идеология таләбенә сыймаслык гаеп табу мөмкин түгел иде. Димәк, әсәрдән бигрәк минем үземне үткәрергә теләмиләр – башкача ничек аңларга? Главлитның идеология сагында торучы нинди усал вахтёр икәнлеген күптән белә идек. (...) Аның белән әсәрне басып чыгаручылар күбрәк җәфаланалар иде. Журнал редакциясендә утыручы егетләр әсәрне басарга әзерләгәндә еш кына «Әмирхан абый, менә бу җирен сызарга кирәк, Главлит барыбер үткәрмәячәк» дип әйтә торганнар иде. (...) Әмма,ниләр генә кичерергә туры килмәсен, минем «Казан утлары»на хөрмәтем һәм рәхмәтем бик зур. Барлык повестьларым, хикәяләремнең бик күбесе аның битләрендә басылып чыкты. Иҗат гомеремне мин аңардан аерым карый алмыйм, сөенечләрем дә, көенечләрем дә күбрәк аның белән бәйләнгән... Хәер, шушы ук сүзләрне безнең һәрбер әдип һәм шагыйребез әйтә алыр иде: һәркайсыбыз аның аша әдәбиятка кердек, үстек, танылдык. (...) һәм безнең журнал битләрендә идеология таләпләренә көчләп тә сыйдырып булмый торган кыю әсәрләр дә ара-тирә чыккалый иде. Мисал өчен Әхсән Баянның «Яшьлегемне эзлим», Нурихан Фәттахның «Артта калган юллар» һәм Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»ен искә төшерү дә җитсә кирәк. Билгеле инде, бу – журналны дөньяга чыгаручыларның да зур тәвәккәллеге иде. Аларның күбесе, үзләре дә турыдан-туры әдәбият белән шөгыльләнүчеләр буларак, әдәби иҗатның нәрсә икәнен яхшы аңлаганнар. Мин моны сугыштан соңгы елларда редакторлык вазифаларын үтәгән Гази Кашшаф, Газиз Мөхәммәтшин, Рафаэль Мостафин, шулай ук күп әсәрләрне кулларыннан үткәргән Фәрваз Миңнуллин, Яхъя Халитлар турында әйтә алам. Менә шулар, югарыдан каты шелтә алачакларын белеп торсалар да, безнең «гөнаһлы» әсәрләребезгә алдан шауламыйча гына мәйдан бирделәр. Ни өчен? Тыеп торучы түрәләр киләләр дә китәләр, ә матур әдәбият кала, ул бездән соң да яшәргә тиеш!»

Шулай итеп, 1950 еллар ахырына татар әдәбияты да үзенең яңа тормыш төзү пафосы белән сугарылган «кызыл» чорын, аннары алмашка килгән гражданлык романтикасын, сугыштан соңгы туган җир, туган ил төшенчәләре белән бәйле уянган сентименталь-лирик баскычны узып, торгынлык халәтенә килә. Бу әдәби-мәдәни торгынлык – рухи яңарыш, без карый торган өлкәдә исә – «Совет әдәбияты» журналының 1965 елның 6нчы саныннан башлап «Казан утлары» исемен алып, үзгәреп-балкып чыга башлавы белән төгәлләнә.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

*(Дәвамы 76 нчы биттә)*

Галимҗан
Ибраһимов

# ЯҢА ӘСӘРЛӘР*

Журналларыбыз: «Мәгариф», «Кызыл Шәрык яшьләре». – «Әдәби ярдәм мәҗмугасы». – Яңа иҗтимагый хезмәтләр: «Икътисад Әлифбасы», «Бөек Франция революциясе», «Татар иле», «Бөек Октябрь революциясе». – Риязият *(математика)* һәм әдәбият коллективларының хезмәтләре, дәреслекләре.

**«Мәгариф»[1]**

Казанда үткән яздан бирле тәгълим-тәрбия хакында бик яхшы журнал чыгып килә. Ләкин революциянең фаҗигале вакыйгалары эчендә бик күп гыйльми-әдәби хезмәтләр тиешле дәрәҗәсендә халыкка мәгълүм булмыйча калган кебек, Татар Социал Советлар Җөмһүрияте Мәгариф комиссариатының бу мөһим журналы үзенә лаек булган рәвештә урын алып җитә алмый. Бу «Мәгариф» журналы, теләсә үзенең мәсьәләләре, теләсә шул мәсьәләләрне тикшерү юлында тоткан ысуллары, теләсә материалының үз бабында байлыгы, төрлелеге белән, һич шөбһәсез, бездә революциягә чаклы чыккан тәрбия-тәгълим журналларыннан чагыштыру мөмкин булмас дәрәҗәдә югары тора.

Журналда һәрбер укытучыга һәр көн, һәр дәрестә кирәк булачак имля, тел, әдәбият, истыйлях *(атама, термин)*, тәгълим ысуллары кебек, күптән сөйләнеп килгән мәсьәләләр хакында җитди тикшерүләр булган шикелле, моңарчы безнең матбугатта бер дә кузгатылмаган риязият дәстүрләре *(кагыйдәләре)*, тәгълим-тәрбиядә хезмәт нигезләре, укытучыларның тарихлары, кәсептәшлек тәрбияләре, мәктәпләрдә уку сезоннары турында, шөбһәсез, гыйльми тәхкыйклар мөзакәрә ителәләр *(хезмәтләр тикшерeләләр)*.

Моңарчы журналның, ике номерын бергә куша-куша, барлыгы алты номеры чыкты. Якын арада җиденче, сигезенче, тугызынчы номерлары бергә чыгачак.

Соңгы номерда 6-7 мәсьәлә хакында мөзакәрә – дискуссия ачылган. Гәзитәләребезнең мондый гыйльми журналларны киң укучы дөньясына таныту хакында ара-тирә мәкаләләр язып, куелган мәсьәләләр хакында мөзакәрәләр ачып барулары лязим икәнен хәтергә төшерү белән бергә, журналның мәсъүл мөхәррире Вәли иптәш Шәфигуллинга[2] киңәш итеп әйтеп үтәсе шул бар: журналларның нык таралуы, үзенә тиешле урынны алуы өчен төп бер шарт бар: аларның үзенең мәгълүм вакытында чыгып торулары.

Типография ягыннан тоткарлык булмасын өчен, бу «Мәгариф»нең дә күләмен бераз кечерәйтеп, һәр айга кичекми бер мәртәбә чыгып торуын тәэмин лязим.

Яңа икътисади сәясәт буенча, журнал үзенең матди ягын уйларга мәҗбүр булганга, бу якка хәзер аеруча әһәмият бирергә туры киләчәк.

---

* Яңа әсәрләр («Казанда үткән яздан бирле...»). «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 17 гыйнвар (13 нче) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган. «Ахыры бар» дип куелган булса да, ахыры күренмәде.
Гарәп графикасында. Текст газетадан алынды.

## «Кызыл Шәрык яшьләре»[3]

Яшь татар коммунистлары тарафыннан Мөхәммәт Парсин[4] иптәшнең редакциясендә чыккан бу журналның беренче номеры көтелгәннән бай чыккан. Монда укып, күңел ачарлык кына түгел, бәлки яшьләр хәрәкәтенең үткәнен, хәзергесен тәхлил белән *(анализлап)*, киләчәккә шулар буенча юл сыза торган җитди мәкаләләр бар.

Журналда мәкаләләре чыккан иптәшләрдән Фатих Сәйфи, Гыйлемдар Баембәтов, Вәли Шәфигуллин, Сәлах Атнагулов, Галимҗан Ибраһимов кебекләр; болар кебек, инде киң укучылар дөньясына танылган язучылар хакында сөйләп тормыйм. Минем өчен мөһим булган нәрсә бигрәк тә коммунист яшьләрнең үз эченнән кайнап чыккан язучыларның әсәрләре булды.

Парсин, Нур Сәйфи[5] – болар ачыктан-ачык коммунизм байрагы астында язучы яшьләребезнең алгы сафында торучы язучылардан.

Әдәбият бүлегендә Мәхмүд Максудов[6] иптәшнең «Оҗмах сезгә, дөнья безгә» дигән мәкаләсе, чыннан да, иске дөньяны җимереп, җир-күккә хаким булырга хәзерләнә торган гаюр *(кыю, гайрәтле)* яшь буынның каһарманнарча омтылуларын күрсәтә торган парчалардандыр. Гомумән, Мәхмүд иптәштә һәркайчан үткен, матур, оригинальный парчалар ялтырап торалар.

Бу бездәге яшь әдәби көчләрнең, чыннан да, өмидлеләреннәндер. Буңа әһәмият бирү, бу яшь көчнең үсүенә мәйдан бирү лязим. Яңа яшь каләмнәрдән Зәйнәп Бәширова[7] һәм Ченәкәй[8] иптәшләрнең, бәлки, моңарчы язган нәрсәләренең иң матурлары журналга кертелгән.

Киң укучы дөньясына исеме яхшы танылган, әле басылмаган «Эшче», «Бабай» кебек поэмалары белән тормышның караңгы төпләрен тасвир итеп бирү көчен күрсәткән Кәрим Әмиринең[9] дә бу яшьләр журналына бик садә *(гади)* һәм матур парчалары кергән.

Журнал нык таралсын, киң дөньяда урын алсын. Буңа каләм белән дә, сүз белән дә ярдәм итү безнең бурычыбыздыр.

***

Яңа журнал! Бу хакта байтак сүз бара. Ләкин шуны утыртырга кирәк ки, һәркемгә кояш кебек ачык бер ихтыяж бар:

– Безгә гыйльми-әдәби һәм нәзари *(теоретик)* бер журнал лязим. Һәр көн безнең алдыбызга әллә ничаклы нәзари мәсьәләләр туа тора. Боларны марксизм ноктасыннан карап, халыкка тәхлил итеп бирү лязим.

Гәзитәләр буны сыйдыра алмый. Мәскәүдә русча «Красная новь»[10] исемендә калын бер журнал чыгаралар. Бер бүлеге әдәбият, икенче бүлеге – саф гыйльми мәсьәләләр, нәүбәттә торган мәсьәләләрне марксизм ноктасыннан тәхлилләр; дүртенчесе – революция тәҗрибәләренә бер нәтиҗә сала бару һәм революция хәрәкәтләренең тарихи материалларын кертә бару.

Менә безгә шул кирәк. Исеме теләсә нәрсә булсын. Һәм мондый журналны бу ел, һич булмаса, берничә номер чыгару лязим. Чөнки кыш буена җыелган материал хәзер байтак булды.

---

**Искәрмәләр һәм аңлатмалар**

1 «Мәгариф» – иҗтимагый-педагогик, фәнни-әдәби айлык журнал. «Мәктәп» журналының дәвамчысы. 1918 – 1936 елларда «Мәгариф» исеме белән басыла.

2 ...журналның мәсьүл мөхәррире Вәли иптәш Шәфигуллин... – В.Шәфигуллин (1894–1939), 1921–1922 елларда «Мәгариф» журналының мөхәррире.

3 «Кызыл Шәрык яшьләре» – 1922–1924 елларда Казанда чыккан айлык журнал. Алга таба журналның исеме «Октябрь яшьләре» (1924–1925), «Авыл яшьләре» (1925–1930), 1930 елдан «Колхоз яшьләре» дип үзгәртелә. 1933 елда «Атака» журналы белән берләштерелә. Журналның беренче санында М.Парсин, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Баембәтов, В.Шәфигуллин, Г.Ибраһимовларның һ.б.ның мәкаләләре басыла.

4 Мөхәммәт Парсин – журналист, публицист, әдәбият һәм театр тәнкыйтьчесе Мөхәммәт Зариф улы Парсин.

(1900–1963), «Кызыл Шәрык яшьләре» журналы мөхәррире. Репрессияләр чоры корбаны. Журналның беренче саны аның «Безнең юлбашчыбыз – III Интернационал юлы» мәкаләсе белән ачыла.

[5] Нур Сәйфи – язучы, журналист Нур Сәйфинең (1896–?) журналда «Эшчеләр әзерлик» мәкаләсе басыла.

[6] Мәхмүд Максудов – язучы, тәрҗемәче Мәхмүд Гыйсаметдин улы Максудов (1900–1962).

[7] Зәйнәп Бәширова – шагыйрә Зәйнәп Хуҗихан кызы Бәшированың (1903–1984) журналда «Шәрык яшьләре» шигыре басыла.

[8] Ченәкәй – Төхфәтулла Ченәкәйнең журналда «Теләнче җыры» шигыре басыла.

[9] Кәрим Әмири – К.Әмиринең журналга «Ачлык корбаннары» шигыре кертелгән.

[10] «Красная новь» – 1921 – 1941 еллардагы Мәскәүдә рус телендә чыккан беренче совет әдәби журналы. Беренче мөхәррире – А.Воронский.

*1922*

## *Безне котлыйлар*



**Серик САГЫНТАЙ,**
Казакъстан Республикасының «Касым» әдәби-иҗтимагый журналының баш мөхәррире

*Хөрмәтле һәм гыйззәтле «Казан утлары» журналы коллективы, коллегаларыбыз!*

*Сезне бер гасырлык юбилеегыз белән котлыйбыз! 100 ел – кешелек тарихында алай зур вакыт булмаса да, әдәбият дөньясы өчен, әдәби үсеш өчен шактый олы биеклек. Шушы йөз еллык юбилей көненә зур абруй белән, өлкән тарихи күренекле каләм ияләре белән килеп җиткән журнал коллективына зур уңышлар, иҗат дәрте телибез.*

*«Казан утлары»ның үткән гасырның 20-30 нчы елларында беренче дөнья күргән көннәреннән бирле казакъ язучылары һәм укучылары өчен бик якын, кадерле журнал булуын беләбез. Казакъ зыялылары, башында Магъҗан торган казакъ акыннары, «Казан утлары» журналы белән шул дәвердән бирле аралашып, аның төрки телле илләребезнең киләчәге өчен бик кирәкле басма булуын яхшы аңлаганнар. Беренче дәвердән үк казакъ-татар әдәби-рухани бәйләнешләренең башында булган журналны бүгенгә кадәр Евразия әдәби киңлегендә үз урыны, үз байрагы булган басма дип беләбез. Коллегаларыбызны, журнал редакциясен, бөтен Татарстан каләм әһелләрен шушы әдәбият бәйрәме белән, «Казан утлары» журналының йөз еллык юбилее белән котлыйбыз! Илебез өчен, туган телебез өчен, әдәбият өчен хезмәт итүдә Ходай куәт бирсен!*

# Һади Такташ

## Җырланачак җырлар турында

*...Арт урамда берәү авыр башын салган цементка,*
*Ул эчмәгән үзе, ләкин аны*
*Җырланмаган җырлар исерткән.*
Х. Туфан. «Җырланмаган җырлар турында»

Туфан!
Таш урамда башын салган егет
Синең тиргәвеңне ишетте.
Әйе,
Аны әле җырланмаган,
Җырланачак хисләр исертте!..
Бөек җиңү алып килгән хисләр
Сыеша алмый таша күңелдә;
Әйтче:
Кайсын шунда җырлап бетереп була
Безгә тигән кыска гомердә?
Һәрбер фронт безгә зур көрәштә
Тиңсез җиңү алып китерсә,
Һәрбер җиңү алып килгән хисләр
Үзе белән безне исертә.
Ә җырлаучы кайда шул хисләрне?
«Җырчы» урыны көтә иясен.
Бөек еллар җырда үз Ленинын
Тудыралмый калды, күрәсең...
Маңгай бөдрәләрен туздырып, мин
«Мазут» суы аккан урында
Уйлыйм, Туфан,
Әле җырланмаган,
Җырланачак хисләр турында.
Ташлап киттем
Тамбов урманнарын,
Нишлим? –
Шау-шуларга йөрәк чыныккан.
Давылларда туып канатланган
Бунтарь йөрәк качты тынлыктан.
Хәзер инде Тамбов урманнары
Төшкә генә минем керерләр.
Ләкин
Дус агайлар минем җырларымда
Мәңге шәүлә булып йөрерләр...
«Әухәди»не минем җырларымда
Әле,
Туфан, бик күп күрерсез,
Минем белән әле киң кырларда
Бик күп атлар көтеп йөрерсез...
Ләкин бүген менә «арт урамнан»
«Мазут» суы аккан урында
Уйлыйм
Җырланмаган, –
Киләчәктә
Бер җырланыр җырлар турында.

*«Безнең юл» . 1926 ел, 11–12нче сан*

# Хәсән Туфан

## Кырык бердән ашкан эсселектә...

Күрә алмам инде тормышны мин –
Их, ул тагы үсәр, үзгәрер.
Кайтмас юлга киткән мөһаҗирдәй,
Айга очып киткән юлчы кебек,
Саубуллашып карый күзләрем...

Оялары янган кошлар сыман,
Өметләрем качты бу баштан.
Бер уй гына калды баш очымда:
Кайда соң, сез, кордаш, кардәшләр?!

Авырайды тән, тимер тутырган күк,
Үзенә үлем тула, ахры!..
Бата барган кораб эчендәге
Юлчы сыман йөгерә акылым.

Тукта, акыл!.. Тукта... акыллым.
Йөгереп кая китә аласың?! –
Әйтелмәгән уйлар,
Язылмаган җырлар
Атомнарыма сеңеп каласыз.
Каласыз...

Каннар, әллә... тагын әйләнмәкче?!
Үлем, бәлки, кире юнәлер?..
Кырык бердән ашкан эсселектә
Кочегар күк эшли йөрәгем.

Ташлап киткән өмет кире кайтты,
Җанның эше тагы рәтләнә.
Йөрәккәме, камфорагамы соң –
Кемгә илтим бөек рәхмәтне?

Тормышка мин
Яңадан алып киләм
Коткарылган табыш-гомерне.
Беренче кат күргән кеше кебек,
Туймый карыйм туган илемне.

*«Яңалиф». 1930 ел, 2нче сан.*

## Нәкый Исәнбәт

### Әбүгалисина
**(биш пәрдәлек драма-поэмадан өзек)**

Аһ, юк, мин ни өчен гыйлем алдым,
Шул халкыма файда тимәгәч?
Кояш булып кемгә хаҗәт,
Башкаларга нурын бирмәгәч?
Юк, юк! Алар бәхте – минем бәхтем,
Телим: халкым күзе ачылсын,
Гыйлем белән алар көчле булсын,
Сөю, хаклык җирдә шаһ булсын.
Артык кеше кешегә кол булмас,
Бер халыкны берсе табындырмас,
Сәҗдә булмас, һичкем хур булмас.

*«Совет әдәбияты». 1959 ел, 7нче сан.*

## Әхмәт Фәйзи

### Көзге моңнар

*Левитанның «Алтын көз» дигән картинасын карагач*

Алтынланган куе әрәмәлек
Үзе моңлы, үзе сөйкемле.
Яфраклары төшә бөтерелеп,
Үлгән күбәләкләр шикелле.

Агачларның алтын яфракларын
Күлгә таба әйдәп җил исте.
Кургаш төсле авыр дулкыннарын
Әкрен генә чайкый күл өсте.

Шаулаштылар күлнең камышлары
Нәрсәдәндер боегып, зарыгып.
Ахры, ташлап киткән аккошлары
Белән үткән җәйне сагынып.

*«Совет әдәбияты». 1939 ел, 7нче сан.*

# Кави Нәҗми

## Туган йортыбыз

Совет иле – туган йортыбыз!
Шундый иркен синдә сулавы,
Тауларыңнан бәхет җырыдай
Шаулап ага чишмә сулары.
Матур синең җәйге таңнарың.
Рәхәт синең язгы җилләрең.
Һәр яфрагы изге урманнарның,
Һәр карышы изге җирләрнең.
Батырлыкта, эштә ярышып,
Тугры булып сиңа үстек без.
Давылларны, утлы елларны
Дуслар белән бергә кичтек без.
Һәр халыкны тигез яктыртып,
Байрагыңда балкый азатлык;
Синдә таптык әкият шикелле
Матур тормыш, бәхет һәм шатлык.
Совет иле – туган йортыбыз!
Кояш сиңа мәңге нур чәчәр.
Даһи Сталинның бөек эше
Шуның кебек – мәңге ул яшәр!

*«Совет әдәбияты». 1945 ел, 11нче сан.*

# Салих Баттал

## Өчтән бер

Мин – очучы. Парашютчы кыз ул,
Минем ярдәм белән очалды;
Минем җиңеп менгән биеклекне
Җиңеп түбән таба төшә алды.
Зур дан алган көнне, ул көнне дә
Минем белән бергә очты ул;
Беренче кат – өч мең,
Икенче кат – биш мең метрдан,
Өченче кат – рекорд куйды ул.
Аерылыштык, куллар бирешеп без,
Аерылучы дуслар шикелле.
Бер ел үтте. Почта шушы кыздан
Бер үк көнне өч хат китерде.
Ләкин мине кечерәйтә бару
Сизелгәндәй булды хатлардан:
Бер хаты – «Иптәш командир»,
Икенчесе – «Иптәш Баттал...»,
Өченчесе – «Салих...» диеп кенә
Башланган...
Дулкынландым. Ышанасым килми
«Салих» кына булып калуыма!
Беренче һәм икенчесен куеп,
Шушы хатны алдым кулыма.
Юк, бусының башка мәгънәсе бар,
Һич көтмәгән идем монысын:
Беренче хат – кыска,
Иенчесе – озынрак;
Өченчесе – озын, бик озын...
Анда әйткән, гаепләмә, дигән,
Сиңа ачам йөрәк серемне;
Әле синең белән танышканчук,
Кечкенәдән ике егетне
Мин күзәтеп үскән булган идем,
Тик зуррак эшкә тотынгач,
Берсе – онытылды.
Икенчесе – онытылып килә,
Өченчесе, ахры, онытылмас...

*«Совет әдәбияты». 1936 ел, 1нче сан.*

Шәриф
Камал

# КУРАЙ ТАВЫШЫ

хикәя

Мин ата-анамны белмим.

Аларны бик шәп киенгән сурәттә фараз кыла идем.

Гүя алар бик шәфкатьле, бик матурлар... Тик икесе дә хәлсезләр... Әллә нинди, караңгылы-яктылы бүлмәдә бик әкрен, бик көчкә генә сөйләшәләр, сүзләре аңгарылмый... Морҗада җил сызгырып тора, һәм куркынычлы, һәм моңлы курай уйнаган тавыш ишетелә... Яисә алар әллә кайда кырда, бер-берләреннән ерак яталар. Тагын ук хәлсезләр... Өсләренә нечкә чаршаулар ябылган, күтәрелеп, үрелеп торалар... Чаршауларны җил селкетә, җил сызгыра... Караңгы... Курай тавышы ишетелә, кем уйнаганы күренми...

Үлем миңа шулай тоела иде.

Артыгын уйлый алмый, курка гына идем.

Дәдәм мине яратмый иде. Аның берничә мәртәбә: «Син, малай, яхшы булмассың!» – дигән сүзләре хәтеремдә.

Мин моңа бик борчыла идем. Аулакка китеп елыйдыр идем. Башкаларның яхшы булып та, үземнең начар булачагыма күңелем әрни иде.

Минем яхшы буласым килә иде. Яхшы булыр өчен нишләргә кирәк икәнлеген төрлечә уйлый вә аңларга тырыша идем.

Хезмәтче Фәйзулла агайны дәдәм бер дә орышмый иде.

Мин аны «яхшыдыр, ахрысы...» дип уйлыйм, ләкин нәрсәсе яхшы икәнлеген белә алмый аптырыйдыр идем. Куллары яргаланган, бер бармагы кәкре, бер күзе аклы, үзе һәрвакыт атларның аналарын сүгә... Аңа сүгү гөнаһ ич.

Шулай да мин аның турысында начар дип хөкем йөртә алмый идем: начар булса, әлбәттә, дәдәм орышыр иде.

Без чәчү вакытында аның белән кырга – чәчәргә йөридер идек.

Җиңгәем мине бик иртә уята торган иде. Ул, миңа ачуланмыйча гына:

– Тор, балакаем... тор, – ди иде.

Мин аны сөядер идем; күзләремне көчкә булса да ачып, тизрәк торырга тырыша идем.

Күп вакытта без кырга чыккач кына, урман артыннан кояш күренә башлый иде. Бу вакытта инде йокым ачыла, рәхәтләнеп китәм...

Кайчагында Фәйзулла агай миңа, аклы күзен генә әйләндереп, калын тавышы белән:

– Нихәл, чәүкә? Йокы ачыламы? – ди.

– Ачыла, – дим.

– Анаң булса, мондый иртә уятмас иде шул. Әнә ничек үзенең кызлары рәхәтләнеп йоклап калдылар! – ди.

– Алар бит кызлар, – дим.

Ул, басып кына:

– Кызлар шул! – ди дә көн буе минем белән бер сүз дә сөйләми...

Ул сукалый, мин аның артыннан тырмалыйм... Аның киң вә керле аркасы белән кара җилкәсе көне буена минем күз алдымда йөрсә дә, минем аңар эчем пошмый иде. Бәлки, көчле вә зур бер кешенең мине бер дә борчымый гына алдымнан йөрүе мине тынычландыра иде. Бу вакыт мин курыкмый идем. Атлар йомшак туфрак өстеннән һаман атлыйлар, һаман баралар. Берсенең камыты бик нечкә ыңгырашкан төсле тавыш бирә, шыгырдый...

Төрле якта кешеләр безнең кебек үк җир каера, мыжгып, хәрәкәтләнеп торалар, аннан-моннан тавышлар ишетелгәли, кеше кычкыра, ат кешни... Мондагы тавышлар берсе дә эч пошу тавышлары түгел; уйнау, күңел ачу тавышлары да түгел, уй вә өметләр арасыннан чыккан эш тавышлары.

Җиребез башыннан узган кайсы кеше, сүз кушмый үтмәс өчен, Фәйзулла агайга:

– Малайны арытма! – дип кычкыра.

Ул миңа әйләнеп карый да:

– Малай егет ул, – ди. Янә тегеңәр карамый, атларны әйди...

Мин азрак шатланам. Фәйзулла агайның керле аркасы, кара җилкәсе миңа тагын сөйкемлерәк күренә.

Байтак эшләгәч инде, ул миңа:

– Чәүкә! Ашыйсы киләме? – ди.

Мин ни дип әйтсәм дә, ул аңар әһәмият бирми – тынарга туктыйбыз.

Ашаганда, мин аның кәкре бармагына карамыйм: үзе күрердән оялам. Ашап туйгач, икебез дә дога кылабыз, Фәйзулла агай: «Аллаһым бәрәкәт», – дип, бит сыпыра, мин дә аның артыннан шулай әйтәм.

Бәгъзе вакыт ул, дога кылгачтын, миннән:

– Нихәл, армадыңмы? – дип сорый.

Мин арганлыгымны аңар әйтмим, һәрвакыт:

– Юк, армадым, – дим.

Шуннан соң ул артык сөйләнми.

– Атлар солыларын бетергәч, мине уятырсың... – ди вә озын гына киерелеп сузыла да тиз арада ук хырылдап йокыга китә...

Мин ялгыз утырып калам. Бу вакыт миңа бик күңелсез була.

Тирә-яктагы чәчүчеләр дә һәммәсе эштән тукталган. Аяк өстендә кем дә күренми. Анда-монда атлар гына икәү-өчәү бергә киңәшеп, серләшеп торган кебек күренәләр. Табигать терелеп бетмәгән. Кошлардан чыпчык яисә сыерчыклар гына чырылдашкалап үтәләр, яисә ала карга ачы тавышы белән каркылдап уза. Аның сөйкемсез ачы тавышына атлар ашаган җирләреннән туктап караналар, мин искәртмәстән, ни булды дип аптырап, Фәйзулла агайга карыйм... Ул хырылдап ята, йоклый, ахрысы. Ләкин керфек араларыннан күзләре күренә, икесе дә аклы кебек хәрәкәтләнәләр. Мин тагын куркам... Бервакыт мин шулай аңар таба карап тора идем, ул кинәт

авызын ершайтып, чырае көлгән рәвештә булды. Аһ, бу сөйкемсез көлеш! Мине бөтенләй изде, чәчләрем үрә торды, түбәмнән бозлы су коелган кебек булды. Курыкканымнан, торып, бер читкә китеп утырдым.

Моннан соң ул йоклаганда, мин аңар карамый, бер читтәрәк, авыл якка карап утырадыр идем. Авыл янындагы тау өстендә ике җил тегермәне бик ерактан күренә иделәр. Алар минем зиһенемне адаштыралар... Миңа алар җанлы кебек тоела иделәр. Кайчагында мөгезләрен сузып, нидер тыңлаган төсле тик кенә торалар. Бу вакытта әллә нинди кодрәт кәҗәләре төсле җанварларга охшыйлар. Яисә бер урында җиңнәрен селкетеп, кулларын бутап-бутап шаярган балалар төсле котырып чыгалар... Аһ, бу шаярган «дию балалары» ерактан нихәтле минем эчемне пошыра иделәр. Бу вакытта атларның бер көйгә кыштырдашып ашаган тавышлары, Фәйзулла агайның хырылдавы, коры җилнең ыжгыруы арасыннан курай уйнаган тавыш ишетелә иде, анам-атам да шунда булган кебек тоела иде. Тик күрми генә идем...

Фәйзулла агай, йоклап торгач:

– Әйдә, бетерик тә кайтырбыз... – ди торган иде.

Ул мине күңелләндерер өчен моны әйтә иде.

Тагын кичкә хәтле бер дә сөйләшмичә эшлидер идек.

Тик бу вакытта борын үтәли генә көй чыгаргалап йөри иде ул. Бу чакта миңа күңелле буладыр иде.

Без авылга кайтканда, кояш түбәнләнеп кызарган була иде.

Тегермәннәр янынннан үткәндә, мин инде тынычсызланмый идем; Фәйзулла агай әкренләп җырлый, мин тыңлап кайтам. Аның җырларына мин әллә нинди мәгънәле, серле сүзләр, хакыйкатьләр кебек карыйдыр идем.

Ул бер җырында:

Төннәр уртасында үкереп елый
Буйга гына җиткән кыз бала, –

ди.

Мин шул турыда юл буенча уйлый киләм: «Ни сәбәптән болай төн уртасында үкереп елый икән? Алар һәммәсе дә шулай төн уртасында елыйлармы?.. Әнкәләре сизәме, юатамы икән? Ачуланмый гына юатасы иде. Алар бит гаепле түгел; Фәйзулла агай да аларны сүкми, кызганып кына җырлый...»

Безгә дәдәм үзе капка ача, җиңгәм дә, Гөлниса белән Фатыйма да шунда булалар.

Җиңгәм ачык йөз белән минем турыда Фәйзулла агайга:

– Хәсәнемне син арыткансыңдыр инде, юләр нәрсә! – ди. Миңа: – Әйдә, юын инде тизрәк, ашыйсың да килә торгандыр, бәбкәм... – кебек сүзләр әйтеп, ягымлы гына каршылый иде.

Дәдәм:

– Аздырма, аздырма үзен, Фәйзулла! Ничек, ялкауланмыймы, карышмыймы? Юкса мин үзен!.. – ди.

Җиңгәм аңа ачулана:

– Йә, булыр, саташкан! Баланың күңелен бозып сөйләнәсең шунда... – ди.

Минем күзләремә яшьләр килә, көчкә генә еламый түзәм.

Фәйзулла агай:

– Малай – егет, өйләнәсе генә бар... – ди.

Җиңгәй минем аркамнан кагып көлә, мин оялып, өйгә кереп китәм.

Минем юынган җиремә килеп, Гөлниса белән Фатыйма, бер-берсен бүлеп-бүлеп, миңа хәбәрләр сөйлиләр: кайда әнкәйләре белән кунакка барганнар, бәбкәләрне ничек карга ала башлаган, әткәләре ярминкәдән нинди уенчыклар китерергә әйткән – тиз генә сөйләп өлгерергә тырышалар.

Кич тиз уза, иртән тагын җиңгәм уята, тагын тиз генә торырга тырышам...

Чәчү беткән иде инде, беркөн Фәйзулла агай, хасталанып, өенә китте. Шуннан соң аның хатынын бер-ике мәртәбә күрдем. Дәдәмнән акча сорарга килгән иде. Аның хатыны үзеннән биек, үзеннән матур иде, тик киемнәре начар. Менә җиңгәмнең күлмәкләре шәпләр!

Без бервакыт җомга көнендә җиңгәм, Гөлниса, Фатыйма урманга җиләккә бардык. Җиңгәм миңа яңа күлмәк-ыштан, күк кәләпүш кидерде. Гөлниса белән Фатыйма да бик киенгәннәр иде. Көн бик һәйбәт, аяз, урман тәбәнәк, яфрак вә чәчәккә күмелгән, күз камашырлык якты, эссе. Агач, чәчәк исләре мигә үк тула, рәхәтләндерәләр; төрле сандугачлар, Гөлниса белән Фатыйманың мин кырдан кайткач, ашыгып-ашыгып, хәбәр сөйләгәннәре кебек, әллә ничәсе бердән сайрый, иң нечкә кылдан алып төрле көй, төрле тавыштан гаҗәепле бер матур гөрелте чыга: әллә кайларда чылтырап аккан елга тавышлары, әллә нинди хатын-кызның бик нечкә, бик матур каһкаһәләре, бишек тирбәткән көйләр, әллә кайлардан ишетелгән көтүче кычкырыклары, күктә уйналган әллә нинди шатлык көйләре, курай тавышлары, чиксез-кырыйсыз матурлык, сафлык, югарылык көйләре... Бу вакытта атам-анам да гүя әллә кайда, бик еракларда шатланалар...

– Хәсән, Гөлниса, сез миннән ерак йөрмәгез, адашырсыз... – ди җиңгәм. Ул үзенең ал күлмәге, матур чырае белән бик зур гөл чәчәгенә охшый, ифрат та сөйкемле...

Кайбер җирләрдә агач ботаклары аңар тимәсен өчен, ул үткәнче тотып торам, аңар күрсәткән шул кечкенә хезмәтемә җаным белән рәхәтләнәм... Аның аяк астына чәчәкләр түшисем килә...

Без өйгә кайтканда, көтүләр килә иде.

Дәдәм капка алдында күңелсез генә тора, безнең җиләкләргә дә бер дә исе китмәде. Гөлниса белән Фатыйманы да бер дә мактамады, сөймәде. Җиңгәм белән сөйли калдылар, без өйгә кердек. Ишек ачык иде. Соңыннан җиңгәмнең:

– Үлгән икән мескен!.. – дип кайгырып кергәнлеген ишеттем.

Ул, өйгә кергәч:

– Фәйзулла агагыз үлгән икән... – диде.

Гөлниса белән Фатыйма икесе бердән:

– Әни, чынмы үлгән? Әни, ник үлгән, ә? – диештеләр.

Мин дә, җиңгәм ни әйтер икән дип, аларның болай сорауларыннан разый булдым.

Җиңгәм:

– Чын булмый ни... Юкларны сорашмыйлар... – диде.

Артык алар да сорашмады, җиңги дә ул турыда безгә бер сүз дә сөйләмәде. Шулай да минем урман рәхәтләрем тузанга тузды, күңелемә Фәйзулла агай килеп утырды...

Моннан соң байтак вакытларга кадәр әлеге караңгылы-яктылы бүлмәдә ике кеше түгел, өч хәлсез кеше ята башлады; өчесе дә аңлашылмаган тел белән бик әкрен, көчкә сөйләшәләр, морҗадан җил сызгыра, тәрәзә төбендә һәм куркынычлы, һәм моңлы курай уйнаган тавыш ишетелеп тора... Яисә, мәгълүм булмаган әллә кайлардагы кырда, бер-берләреннән ерак яткан хәлсез кешеләр дә икәү генә түгел – өчәү. Өсләренә нечкә чаршаулар ябылган, күтәрелеп үрелеп торалар... Җил селкетә, җил сызгыра. Караңгы... Курай тавышы ишетелә – кем уйнаганы күренми...

## *Безне котлыйлар*



**Маркабай ААМАТОВ,**
Кыргыз Республикасы Язучылар союзының «Ала-Тоо» журналы баш мөхәррире, Кыргыз Республикасының халык шагыйре

*Хөрмәтле баш мөхәррирне һәм «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләрен басманың 100 еллык юбилее белән чын күңелдән котлыйм!*

*Бер гасырлык данлы тарихы булган журнал битләре аша кыргыз укучыларына киң билгеле булган татар әдәбияты классиклары Габдулла Тукай, Муса Җәлил иҗаты кыргыз әдипләре өчен чын иҗат мәктәбе булып торуын яхшы беләбез. Олуг бәйрәмегез уңаеннан исемнәре журнал тарихы белән бәйле булган бүгенге заман татар әдипләреннән Равил Фәйзуллин, Илфак Ибраһимов, Рафис Корбанов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин, Ленар Шәех кебек каләмдәш дусларның әсәрләре белән безнең «Ала-Тоо», «Яңа Ала-Тоо» журналлары аша кыргыз укучыларының да танышу мөмкинлеге туды.*

*Хөрмәтле каләмдәш дуслар!*

*Безнең араларны бары тик бер-беребезнең әдәбиятлары гына якынайта ала. Советлар Союзы вакытында «Әдәбиятлар дуслыгы – илләр дуслыгы» дигән канатлы гыйбарәне киң куллана идек. Хәзер дә бу сүзләрнең мәгънәсе югалганы юк. Киресенчә, аның мәгънәсе артып кына бара. Журналларыбыз арасындагы бәйләнешләр тугандаш ике ил арасына әдәби күпер салып, араларыбызны тагын да якынайтуын телибез.*

*Бар булыйк, бергә булыйк!*




### «Безнең юл» идарәсеннән әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә

## МӨРӘҖӘГАТЬ

*Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, «Безнең юл» журналын чыгара башладык.*

*«Безнең юл»ның чыгуы татар җөмһүриятенең мәркәзендә – Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без эчке, Волга-Урал, Сибириянең төрле почмакларында яшәүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең ярдәменә ышанып, эшкә керештек.*

*Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына; икенче яктан, гыйльми-сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән журналга булышсыннар иде. Кульъязмалар өчен акча түләнә, даими абунә җыючылар, язучылар белән аерым мөгаһәдәләр ясала. Эшче-крестьян гаммәвесенең азатлыгы юлында эшләүче иптәшләр бу журналны үзләренең уртак хезмәтләре итеп карасыннар һәм шулай булышсыннар иде.*

*«Безнең юл»ның программасы:*

*1) гыйльми-сәяси мәсьәләләр;*

*2) революция һәм партия тарихыннан материаллар;*

*3) партия һәм совет төзелеше;*

*4) пропаганда;*

*5) Шәрыкны өйрәнү;*

*6) әдәбият һәм сәнәигы нәфисә;*

*7) татар җөмһүриятендә иҗтимагый вә икътисади хәлләр;*


*8) нәүбәттәге мәсьәләләр;*

*9) рәсми бүлек (партия һәм советның мөһим карарлары, тәгълиматлар).*



*«Безнең юл» журналын оештыруга зур өлеш керткән Галимҗан Ибраһимов Казанның гыйльми үзәк җитәкчесе дә була. Фотода Г.Ибраһимов (уртада), аның уң ягында Фатих Сәйфи-Казанлы, сул ягында Шаһид Әхмәдиев һәм үзәк әгъзалары.*

*Татар Совет әдәбиятының классик әдипләре Мәҗит Гафури, Һади Такташ, Галиәсгар Камал. 1920 еллар ахыры.*





*Газиз Гобәйдуллин белән Гали Рәхим «Татар әдәбияты тарихы»ның 3 нче томлыгы чыккач. 1924 ел.*



*Каләм ияләре киңәшә. Сулдан уңга: Шәриф Камал (утырган), Гомәр Гали, Хәмит Ярми, Гомәр Толымбай, Кави Нәҗми, Кәрим Тинчурин. 1932 ел.*



*Хәсән Туфан, Мәхмүд Максуд. 1934 ел.*



*Габдрахман Минский, Һади Такташ, Мирсәй Әмир. 1920 нче еллар ахыры.*



*Татар язучылары Казан Кремле янында. 1930 нчы еллар.*



*Совет язучыларының I Бөтенсоюз съездына Казаннан барган делегатлар. Сулдан икенче – Кәрим Тинчурин. 1934 ел.*



*Муса Җәлил каләмдәшләре Төхфәт Ченәкәй, Әмирхан Еники (басканнар) белән. 1930 ел.*

## Муса Җәлил

### Катыйльгә*

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.

Меңен түгел, бары йөзен генә
Юк итәлдем синең сыңарның.
Һәм халкымнан кайткач шуның өчен
Мин тезләнеп гафу сорармын.

*«Совет әдәбияты». 1953 ел, 7нче сан.*

## Фатих Кәрим

### Күңел кошым

Күңел кошым миңа хат язганда,
Күзен йомып уйга таладыр:
Алсу йөзләреннән йөгереп төшкән
Сагыш яше хатка тамадыр.

Кайчан гына шаулы яз җитәр дә,
Кыр казлары кайтыр күлләргә:
Кайчан гына кайтып сөйгәнемнең
Кайнар яшьле күзен үбәргә!

*«Совет әдәбияты». 1945 ел, 6нчы сан.*

## Абдулла Алиш

### Өченче көз

Саргаешып каен яфраклары
Өченче кат җиргә коела.
Өч кенә ел үтте микәнни соң?
Ун ел үткән кебек тоела.
Ил бәйрәмен инде өченче кат
Тоткынлыкта, читтә үткәрәм.
Бер файдасыз, дуслар, үтә гомер,
Бушка үтә, үтә, әй, әрәм!

Бүген тагын инде өченче кат
Килеп җитте менә бу бәйрәм,
Хыялымда бергә бәйрәм итәм,
Дуслар белән бокал күтәрәм.
Дүртенчесен инде насыйп булсын
Каршыларга мул бер табында.
Балаларым, иркәм белән бергә,
Чөкердәшеп өстәл янында.

*«Совет әдәбияты». 1956 ел, 6нчы сан.*

* Катыйль – үтерүче

# Нәби Дәүли

## Ана

Тәрәзәдән карый февраль таңы,
Иртәнге җил кага ишекне,
Яңгырады җирдә шатлык чаңы,
Бөек җырны дөнья ишетте.
Кремльнең корыч курантлары
Туган илне тәбрик иттеләр.
Ерак-ерак бозлы котыпларга
Таң яктысын алып киттеләр.
Урамнарны бизи ал байраклар,
Байракларга җиңү язылган.
Ак чәчәкләр аткан бар агачлар,
Әйтерсең лә инде яз булган.
Иртәнге кар ята юл өстендә,
Кешеләр бара ап-ак урамнан.
Ил каршылый бүген бәйрәм таңын,
Ак ефәккә җирләр уралган.
Яз гөлләре белән бизәкләнгән
Сайлау йорты ачты ишеген.
Кеше монда җиңү китабына
Язып китәр үзенең исемен.
Иң беренче булып килде ана
Һәм офыкта янып таң торды.
Комсомолка сәлам бирде аңа,
Ал байраклар түргә чакырды.
Ул бюллетень алды кулларына,
Бер карады аңа куанып:
– Кызларыма, – диде, – улларыма,
Көннәр килсен данга уралып,
Үзем өчен, туган илем өчен,
Сталинга булсын тавышым,
Гомер телим аңа иртә, кичен,
Мин бәхетле, аяз тормышым.
Ул калдырды язып бюллетеньгә
Йөрәгенең кайнар сафлыгын.
Баласына алып кайтты ана
Киләчәкнең бөек шатлыгын.

*«Совет әдәбияты». 1947 ел, 2-3нче сан.*

# Шәрәф Мөдәррис

## Оч син, җаным!

Ялкын аткан янгын каршысында
Сау-сәламәт чәчәк булырмы?
Кермә, кошым, монда – канлы кырга,
Яндырырсың мамык туныңны!

Гөрли сугыш, көйри бөтен нәрсә,
Без дә монда җиргә сыендык...
Ялкын, сөрем, янгын, төтеннәргә
Кермә, җаным, кермә сыерчык!

Оч син, оч син, җилпеп, купшыланып,
Тыныч кырга, тыныч сахрага, –
Туган җирем табып, кунчы барып,
Кунчы барып минем капкага.

Йортыбызга төш тә, симез, тәмле,
Татлы җим ал, мамык җыеп чык.
Сорар булса әнкәм минем хәлне,
«Ул сау» диген, җаным, сыерчык!

Вакыт җитәр, сугыш корымнарын
Искән җил дә өстән кагышыр...
Туган кырым, туган болыннарым
Минем белән тагын кавышыр.

Төшсә дә тик монда, сугышларда,
Чәчкә кырау, биткә җыерчык, –
Көчем бөтен минем, сулыш барда,
«Ул шат» диген, җаным, сыерчык!

*«Совет әдәбияты». 1944 ел, 5нче сан.*

## Хәйретдин Мөҗәй

### Минем шатлыгым

Бөдрә чәчле иркәм, шатлыгым син,
Синең өчен яши бу йөрәк,
Син булмасаң, әйе, син булмасаң,
Бу йөрәгем үзе ник кирәк?

Гөл кебек ал, матур галстуклы
Пионер, син минем шатлыгым,
Син булмасаң, әйе, син булмасаң,
Яшәвемнең ниткән шатлыгы?

Яңакларың кипкән, әби җаным,
Шатлыгым син күңел түремдә,
Син булмасаң, әйе, син булмасаң,
Нидер җитмәс иде күңелгә.

Көмеш чәчле бабай, шатлыгым син,
Синең өчен ага бу каным,
Син булмасаң, әйе, син булмасаң,
Боегыр иде төсле шул җаным.

Урманга бай, суга, гөлләргә бай,
Шатлыгым син, матур туган ил,
Син булмасаң, әйе, син булмасаң,
Кемгә кирәк, нигә кирәк мин?

Бөтен шатлык, кайнар мәхәббәтем,
Үз халкымда, туган илемдә.
Шулар өчен биреп бөтен дәртне,
Көлә беләм сугыш җирендә.

Көлә беләм, шаулап җырлый беләм,
Көрәшләрдә күңел ямь таба,
Күз алдымда каты үлем күрәм,
Җиңә беләм, Җиңү – мәртәбә.

*«Совет әдәбияты». 1942 ел, 7нче сан.*

## Нур Баян

***

Минем өстән пуля яуса да,
Җәрәхәттән каннар тамса да:
Халкым өчен постта торырмын,
Халкым өчен туры булырмын.

Авырлыклар миңа килсә дә,
Барыр юлым дошман киссә дә:
Тереләй бирелмәмен дошманга,
Хыянәт итмәм Татарстанга!

Кая гына аяк бассам да,
Тик бер генә пуля атсам да:
Сөйгән халкым өчен барысы да,
Туры улың, халкым, мин сиңа.

*«Совет әдәбияты». 1947 ел, 4нче сан.*

Гадел
Кутуй

# ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР

ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК

Искәндәр!

Тормышыма зур үзгәреш керткән бер вакыйга булу аркасында, бу хат нәкъ 20 көн өзелеп торды. Шунлыктан Мәфтуха апай турында да язалмый калдым. Мин сиңа байтак нәрсә турында язарга уйлаган идем. Ләкин көтмәгән бер вакыйга килеп чыгып, хатымны чуалтты. Шуның аркасында башта язылган өч хатымны да җибәрми калдым.

Беркөн амбулаториядә авыруларны карап бетереп китәргә җыенганда гына, ял йорты докторы кереп:

– Ирең безгә ял итәргә килде. Синең турыда сөйләгәч, бик шатланды. Бүген янына килә, – диде.

Кулымда градусник иде – төшеп ватылды. Бер-ике минутка телсез калдым. Нинди ирем? Кем? Искәндәрме? Вәлиме? Нәрсә уйларга да, кемне күрергә дә белмәдем. Ял йорты докторы – гаҗәп культуралы кеше. Ул канлы ярага тоз салырга яратмый – минем нинди хәлдә калуымны аңлады, күрәсең:

– Шатлыгыңнан шаккаттың бит, Галия. Ярый, мин киттем. Иреңне каршы алырга комачауламыйм. Аннары ашыгыч эшләрем дә бар. Икәүләп безнең янга мороженое ашарга барыгыз, – дип чыгып китте.

Ял йорты докторы чыгып киткәч, ярты сәгать чамасы кабинетымда бикләнеп утырдым. «Искәндәр булмас, аның белән бөтен нәрсә өзелгән, беткән. Ул булса, күрешермен, сөйләшермен дә – бетәр. Вәли булса нишләрмен? Романтикага бирелеп тудырылган хыялый ирем юкка чыккач, халыкка, балаларга нәрсә әйтермен?» – дип уйландым. Авыр уйлардан башым авырта башлады. Өйгә кайтырга җыенып, амбулатория ишеген ачтым. Ишек төбендә Вәли Сафиуллин иде.

– Мөмкинме? – диде.

– Рәхим итегез...

Без кабинетка кердек. Ул бик нык үзгәргән. Йокымсыравы беткән. Олылык төсе кергән. Тик аның күзләрендә генә элекке Сафиуллин билгеләре калган. Йөзендә – шатлык.

– Әдрәстә очрашырбыз дип кем уйлаган?!

– Әйе.

– Йә, ничек торасыз? Сез мине оныткансыздыр да инде. Хәер, белмим. Ә мин рабфакны, рабфак белән бергә сезне дә бик еш искә төшерәм, – дип сөйләп китеп, мине уңайсызлыктан чыгарырга тырышты.

Бер ярты сәгать сөйләшкәннән соң:

– Буш булсагыз, мине чәй белән сыйлар идегез. Ял йортында чәйне көнгә бер генә тапкыр бирәләр, ә мин яратып чәй эчәргә өйрәнгән кеше. Семьягыз белән дә таныштырырсыз, – диде дә урыныннан кузгалды.

Башта мин аны өемә чакырырга да, чакырмаска да белмәдем, чөнки балаларым, әткәй, дип, Вәлинең муенына асылынулары мөмкин. Рәсемнәрне күреп, мине дә, үзен дә уңайсыз хәлдә калдырыр. Мин шулай уйладым. Ләкин шулхәтле озак күрешми торганнан соң, «вакытым юк» дип, Вәлине дә кайтарып җибәрергә теләмәдем. Тик амбулаториядән чыккач кына, башыма килгән фикерне әйтә алдым:

– Әнә теге ак йортны күрәсезме? Мин шунда торам инде. Приёмнан соң өс-башны алмаштырасы бар. Ун-унбиш минуттан соң шунда килергә булсагыз, мин сезне вареньелап чәй белән сыйлармын, – дидем.

Ул риза булды.

Мин, өйгә кайтып, балаларны урманга җиләккә җибәрдем. Самовар куеп, өстемне алмаштырдым һәм түземсезлек белән Вәлине көтә башладым. Стеналарга эленеп куелган рәсемнәрне кузгатмаска булдым. Сер, ачылгачтын, ахырына кадәр ачылсын, дидем.

Самовар өстәлгә менү белән, Вәли килеп керде.

Сезнең квартирагыз шәһәр квартираларыннан бер дә ким түгел, – дип, керүенә бүлмәләремне мактый-мактый, күзен стеналарга, рәсемнәргә төшерде.

Рәсемнәрдә үзен күрүгә гаҗәпсенде. Ләкин эндәшмәде. Тик чәй алдында гына, бер-беребезгә ияләшә төшкәч кенә, түбәндәгечә сөйләшүләр китте:

– Карагыз әле, Галия, – диде ул. – Мин ял йортына килеп төшкәннең икенче көнендә үк миңа: «Сезнең хатыныгыз биредә доктор булып эшли», – диделәр. Юлда йөргәндә, ял йортларында ятканда, кеше белән нинди кызык нәрсәләр булмый! Тиз танышасың. Шунда моңарчы берәүгә дә сөйләмәгән серләреңне сөйлисең. Моннан соң мәңге очрамаслык кешеләр белән дуслашасың. Бу юлы да: «Мине берәр кеше белән бутыйлар, күрәсең, әйдә кызык булсын», дип уйладым да, «хатының монда» дип әйтүчеләргә: «Әйе шул, минем хатыным монда эшли», – дия башладым. Ләкин ял йорты докторы да шул ук сүзне әйткәч, «сезнең хатыныгыз Галия Сафиуллина» дигәнне дә ишеткәч, борчылырга тотындым һәм сезне күрәсем килде: «Фамилияләр бер булганга шулай әйтә торганнардыр», – дип уйласам да, «юк» дип җавап бирергә телем бармады. Чөнки рабфакта чакта мин хыял итеп йөргән Галиямнең хәзер кешеләр тарафыннан «синең хатының Галия» дип йөртелүе минем өчен рәхәт иде. Инде үзегезне күрдем. Менә монда, сезнең өегездә утырам. Стенада үземнең рәсемнәремне күрәм. Ләкин бит мин сезнең белән бервакытта да рәсемгә төшкәнем юк. Миңа охшаган кеше кем ул? Ялгышмасам, сез артист Искәндәргә чыккан идегез. Аерылдыгызмы әллә? Искәндәрдән соң әнә шушы рәсемдәге кешегә чыктыгызмы? Нинди кәмит бу? Зинһар, аңлата күрегез.

– Искәндәр белән мин күптән аерылдым. Шуннан соң берәүгә дә чыкмадым, дияр идем, хата булыр. Чөнки рәсемдәге кеше «ирем» булып хисаплана. Балаларым аңа «әткәй» диләр.

– Кем соң ул?

– Ул – сез. Мин ул рәсемне рабфактан калган дәфтәрләрем арасыннан таптым.

– Димәк, сезне минем хатыным дип йөрүләре дөрес?

– Әйе, дөрес.

– Ләкин мин бернәрсә дә аңлый алмыйм. Бу эшкә сәбәп нәрсә?

– Әгәр дә бу эш сезне борчыса, мин хәзер үк рәсемнәрне алып яшерә алам һәм, телисез икән, ял йортына барып, «Бу Сафиуллин минем ирем түгел» дия алам. Ләкин сез монда күп булса тагын бер ай торырсыз. Авырсынмасагыз, мин сездән бу «кәмит»нең – «фаҗигале кәмит»нең, дәвам итүен сорар идем.

– Ягъни?

– Ягъни семьягыз турында сүз чыкканда...

– Мин өйләнмәгән, минем семьям юк...

– Минем турыда сүз чыкканда, дим мин...

– Әйе...

– Галия – минем хатыным, иптәшем, – дип әйтегез.

– Ни өчен? Нигә? Һич аңламыйм.

– Вәли, сез миңа бик авыр сораулар бирәсез. Курыкмагыз, мин сезгә ике баламны тагарга, сезгә кияүгә чыгарга уйламыйм. Бу бары сезне һәм үземне кешеләр алдында да кыен хәлдән чыгару өчен генә. Юкса йә сез, йә мин, икебезнең берсе хәзер үк моннан китәргә тиеш.

– Беребез дә китми. Мин риза. Тик, үзем белмичә, мин ничек итеп сезнең ирегез булганмын? Шуны беләсе килә.

– Анысын хәзергә сорамагыз. Мин аны сезгә... Димәк, риза?

– Риза.

– Рәхмәт, – дидем дә кулымны суздым һәм аны балаларның яшьләре, исемнәре белән таныштырдым. Үз өенә килгән кебек миңа кереп йөрүен сорадым. Балалар белән әткәйләре шикелле сөйләшүен үтендем.

Шуннан соң ул көн саен безгә килеп йөри башлады. Балалар аңа бик тиз ияләштеләр. «Әткәй», «әткәем» дип, артыннан калмыйча йөриләр. Бергә урманга, чиягә йөрдек. Шул вакытларны райздрав:

– Ирең дә кайткан, ашлык җыю вакыты да җитә. Син бер унбиш көнгә отпускыга чыгар идең. Аннары кызу эш булыр, – дип, үземә отпуск бирде.

Без көн саен очраша торган булдык. Бергә төрле китаплар укылды. Студент чаклар искә төшерелде. Ләкин Вәли һичбер вакыт Галиуллин шикелле начар кыланмады. Мин үземнән курыктым. Чөнки Вәлине чын-чынлап ярата башлаганымны сиздем. Аның белән ничек саубуллашырмын, бергә кушылмас борын ничек аерылырмын дип, йөрәгем сызлады.

# Сибгат Хәким

## Әнкәмә

Кая барсам, кайда йөрсәм дә мин,
Күңелемә шулай тоела:
Пар кулыңа пар чиләгең асып,
Син чыгасың, әнкәй, коега.
Су алганчы юлга бер карыйсың,
Чиләкләрең тулгач, – тагын бер.
«Бала күңеле – далада» дип, бәлки
Үпкәләп тә йөргән чагыңдыр.
Изге теләк теләп үстердең син,
Бассыннар дип тизрәк аякка.
Шул сүзләрең синең искә төшә,
Юнәлсәм дә менә кай якка.
Кое янында син ишетерсең
Миннән сиңа хәбәр килгәнен.
Син һәркемгә очрыйсыңдыр, әнкәй,
Мөлдерәмә килеш чиләгең.

*«Совет әдәбияты». 1955 ел, 1нче сан.*

# Нәҗәр Нәҗми

## Шагыйрь итмәскә

Язам, язам... Нигә язам икән?
Түгелме ул юкка-тиктәскә?
Мин тумыштан, бәлки,
шагыйрьмендер…
Тырыштылар шагыйрь итмәскә.

Бала чагым. Әти үлгән. Ачлык.
(Ачлык елы килгән өч яшьтә).
Шул ук елда үтерергә иткән
Язмыш мине – шагыйрь итмәскә.

Яшьлек, яшьлек…
Тәүге иҗат юлым
Шигъри буын әле неп-нечкә.
Сугыш чыкты: минем кебекләрне
Үтерергә – шагыйрь итмәскә.

Тере калдык. Тормыш дигәннәре
Булмаса да тик син дигәнчә,
Гомеремне шигырьләргә бирдем
Кулымнан һәм каннан килгәнчә.

Язганымны «Вак!» диделәр ваклар,
Йөрәксезләр әйтте: «Акыл юк!
Зур заманда мәхәббәтне җырлап
Вакланырга, имеш, хакым юк».

Вакланмадым түгел, вакландым мин –
Күңел юлым киңнән тар итеп,
Ялганлыкка ихлас ышанудан
Җырладым мин юкны бар итеп.

(Вакландым мин – бик тә үкенечле, –
Мин күз йомдым, йоммас урында.
Һәр талантсыз әдәбият кортын
Үз күрдем мин – күрмәс урында.)

Әхлакый бу җинаятьтән, шөкер,
Котылдым мин, соңлап булса да,
Заман чире күңел юлларыма
Үз тозагын корып торса да.

Торылмады айт дигәнгә, тайт дип,
Вөҗданымны алдым иптәшкә.
Койрык болгау минем канымда юк –
Тырыштылар шагыйрь итмәскә.

Булды заман: иҗатчының данын
Күрделәр тик алтын бизәктә.
Бизәксезләр, имеш, ярты-йорты –
Тырыштылар шагыйрь итмәскә.

Әй син, вөҗдан! Әй син, тәңре уты!
Биреләдер алар сүнмәскә.
Халкы өчен җанын бирүчене
Мөмкин түгел шагыйрь итмәскә.

*«Казан утлары». 1992 ел, 5нче сан.*

# Нури Арсланов

## Чегән кызы

Чегән кызы килде, баштанаяк
Чуар сәләмәгә төренгән,
Гүя моннан биш йөз еллар элек
Торган халык кабат терелгән.

«Сөйләп бирәм, – ди ул, – язмышыңны –
Ни күргәнсең, ниләр көткәнен...»
Белми, мескен, нигә үз язмышы
Фәкыйрьлектә болай йөрткәнен.

Алдан күрә белсәң, түбәнләнеп,
Тиңнәреңнән булмас идең ким,
Ялган ирек тозагыннан арынып,
Яңа юлга чыгар идең син.

Миңа калса, минем үткәннәрем
Бөек Октябрьдан башлана,
Киләчәгем исә ачык, якты,
Беләм аны синнән башка да.

Багучы кыз тәмам өмет өзде,
Сиздә бугай табыш булмасын,
Очлайтты да иренен, китә-китә:
– Игез тапсын, – диде, – юлдашың.

– Тукта, менә бусы мин дигәнчә,
Рәхмәт төшсен яхшы сүзеңә,
Сиңа булсын, мә, ал, сөенчене
Алдан биреп куям үзеңә.

*«Совет әдәбияты». 1953 ел,10нчы сан.*

# Мостай Кәрим

## Аерылу юк

Аерылу юк сөйгән йөрәкләргә,
Без кавыша алмас ара юк,
Сагыну бар, ләкин күңелләрдә
Әрнеп торган утлы яра юк.

Вокзаллар бар. Вагон янында бар
Минутның иң кыска чаклары,
Бөтен юллар буйлап килә торган
Бар шатлыклы сәлам хатлары.

Һәр урында тормыш кочак җәя,
Кул сузалар миңа чын дуслар,
Чөнки җирдә, сөю белән бергә,
Илгә багышланган хезмәт бар.

Арабызда кояш балкып тора,
Җилләр исә, яман җил түгел,
Илебез киң, ләкин кешеләрне
Адаштыра торган җир түгел.

Сагыну бар, алда көрешү бар,
Күңелләрдә утлы яра юк.
Бер Ватанның балалары өчен
«Аерды бит», дияр ара юк.

*«Совет әдәбияты». 1949 ел, 12нче сан.*

# Зәки Нури

## Тәрәзә янында

Чәчәк ата кебек үзе күңел,
Таң шикелле хис саф, уй якты;
Мине бүген, бомба шартлап түгел,
Сандугачлар сайрап уятты!

Тәрәзәмне тулы ачтым, күрәм:
Таныш урман, камыш, күл әнә;
Ничек рәхәт, җәйнең җиле керә
Блиндажга түгел, бүлмәмә.

Күгәрченнәр гөрләп оча җимгә,
Тыңлыйм – гүя, аңлыйм серләрен:
Алар сөйли бу иртәне җиргә
Китерде дип җиңү көннәре.

Кинәт томан сирәгәеп китте,
Күз алдымда – уяу, зур шәһәр.
Әнә юллар, беләм, шулар илтте
Мине моннан Эльбага кадәр.

...Мәйдан итеп уйларым кошына
Шул юлларын үткән арамның –
Мин сокланып, тыныч тормышыма
Ачык тәрәзәдән карадым.

*«Совет әдәбияты». 1946 ел, 7-8нче сан.*

# Шәйхи Маннур

***

Язмыш мине кая чөерсә дә,
Нинди генә михнәт күрсәм дә,
Мин үкенмим, дуслар, өелсә дә
Сугыш йөге солдат җилкәмдә.

Шау-шу да мин, дан да эзләмәдем,
Тик вөҗданым кушкан бу эшне
Үтәдем мин – җаным жәлләмәдем,
Үтәдем мин – ничек тиешле.

Халкым өчен чиксез авыр көндә
Аның белән бергә булдым мин.
Бер сохари кимереп суык төндә,
Солдат кунган җирдә кундым мин.

Бүлештем мин аның кайгыларын,
Җырлап, моңсу күңелен юаттым.
Уртаклаштым ялгыз сагынуларын,
Шатлыкларын түзем солдатның.

Батырларын мактап яздым аның,
Юашларын үттем үгетләп.
«Абый, тагын кил!» дип, канатланып
Кала иде бик күп егетләр.

Йөрәгемдә нинди ялкын булса,
Бар җылысын аңа бирдем мин.
Туры килеп шулай ашсыз кунсам,
«Рәхмәт, дустым, мин тук!» дидем мин.

Кая чөерсә дә язмыш мине,
Киселсә дә соңгы сулышым –
Халкым белән бергә үттем инде
Юлымның иң газап тулысын.

*«Совет әдәбияты». 1946 ел, 1нче сан.*

# Әнвәр Давыдов

***

Кулларыма туган кырларымнан
Туфрак алып үпсәм, көлмәгез,
Моны күңелем йомшак булуыннан,
Җаным җебеклектән күрмәгез.

Ят юлларның әче тузаннарын
Көнбатышка карап йотканда,
Чит җирләрдә алга үрли-үрли
Әрем сабакларын тотканда,

Курыкмадым, дуслар, үлемнән мин,
Әмма һаман шуны уйладым, –
Җылы бөркеп яткан буразнаның
Очы күренмәгән буйларын,

Туган җирләремнең
Күгәрчен түшедәй
Күпереп торган симез балчыгын
Сагындым һәм дошманыма каршы
Сүрелмәс үч белән ярсыдым.

*«Совет әдәбияты». 1948 ел, 5нче сан.*

## Зыя Мансур

### Хатын-кыз кардәшем

Дөньяның йөзләгән, меңләгән
Мәшәкать йөкләрен сөйрәгән.
Назласаң, назланып туймаган,
Булмаса, ялвара белмәгән.

Хатын-кыз кардәшем, чәчәк син,
Кул тисә, черт итеп өзелгән.
Ник ләкин ут яумый, кирәктә,
Чыдам син җеннәрнең үзеннән!

Гөлләрем борлыга син юкта,
Әйләнә бар дөньям котыпка.
Нур белән, ямь белән тула Җир
Син кайтып елмайган минутта!

Карыйм да уйланып сиңа мин,
Эчемнән тын гына сүз катам:
«И Хода, (ә үзем алласыз),
Аера күрмә, дим, бу заттан!..»

*«Казан утлары». 1965 ел. 9нчы сан.*

## Сәйфи Кудаш

### Кайгыртам

Кайгыртмаска киңәш бирәсең син
Бер шелтәләп, йә бер үпкәләп.
Телләреңнең төбен аңлыймын мим.
Тик шулай да китте күпкәрәк.

Безнең көннәр ансат узмадылар,
Билләр биртәйделәр кайгыдан,
Шул кайгылар килер буын өчен
Әзрәк калсын диеп кайгыртам!..

*«Казан утлары». 1967 ел, 5нче сан.*

## Рәшит Гәрәй

### Яз шатлыгы

Кояш сипкән якты нурлар белән
Челтәрләнә карлар катлавы,
Йөрәкләрдә яңа дәрт тудыра
Җир исләрен тоеп атлавы.

Күкселләнә барган чокырларның
Буйларында томан тирбәлә.
– Без хәзер, – дип, – язгы кыр эшенә
Колхоз карты көлеп җибәрә.

Түзеп булмый шат яз хөрмәтенә
Җырламыйча гүзәл җырларны,
Безнең җырның көчле ташкыннары
Күмеп китә иркен кырларны.

Ә аннан соң бәхет, шатлык булып
Кояшкача менә сирпелеп;
– Юлбашчыга биргән вәгъдәләрне
Без үтәрбез төгәл иттереп!!!

*«Совет әдәбияты». 1951 ел, 5нче сан.*

Әмирхан
Еники

# КЕМ ҖЫРЛАДЫ?

хикәя

Ватан сугышының дәһшәтле көннәреннән берсе иде.

Көзге караңгы төндә кечкенә генә җимерек станциядә ике эшелон очрашып, янәшә туктадылар. Боларның берсе тылдан фронтка яңа хәрби часть алып баручы эшелон, икенчесе фронттан тылга яралылар төяп кайтучы санитар поезды иде. Эшелоннар икесе дә, бик озын булып, гел кызыл вагоннардан торалар. Тик санитар поездының гына паровозга якын очында бер-ике классный вагоны бар, ә калганнары исә кечкенә чуен мичләр куеп җылытылган теплушкалар иде.

Станция дигән нәрсәнең үзе дә, бер генә каралтысы да юк – бар да җимерелеп беткән. Тик юллар буенда берничә кат юан бүрәнәләр түшәп һәм балчык өеп эшләнгән зур гына землянка ялгызы калкып тора... Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты җемелдәсен – әйләнә-юнь морҗа эчедәй кап-кара. Ләкин еракка күз ташласаң, сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә. Янамы анда берәр зур авыл, туплар атышы шулай чагыламы – моннан карап белеп булырлык түгел.

Бөтен әйләнәдә фронтка якын җирләрдә генә була торган үле тынлык хөкем сөрә. Хәтта эшелоннар башындагы ике кап-кара паровоз да тып-тын тора, әйтерсең, казаннарын сүндереп, аларны ташлап киткәннәр... Эшелоннарны томалап куйганнар диярсең, берсеннән-бер көлгән, сөйләшкән тавыш та ишетелми, төшеп-менеп йөрүче дә күренми. Тик араларыннан узганда, туктала биреп колак салсаң, бер яктагы кызыл вагоннардан ара-тирә каты хырылдау, икенче яктагы теплушкалардан авыр ыңгырашу ишетелеп кала. Берәүләр соңгы тапкыр йокы туйдыралар, икенчеләр бер күз йомарга гаҗиз булып яталар, күрәсең.

...Теплушкаларның берсендә түбәнге сәкедә каты яралы яшь лейтенант – татар егете ята. Егетнең хәле авыр, уң аягы аның тездән югары киселгән, ә санитар поезды юлга чыккач, аңарда гангрена башланды. Менә бер тәүлек инде ул, ни йоклый, ни уяна алмыйча, ярым һушын югалткан хәлдә ята. Вакыт-вакыт ул аңына килә, шул чакта авыр газаптан талган күзләрен ача, янында басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрә, аның салкын кулын маңгаенда тоя. Бер мәлгә егет үзен җиңеләеп киткәндәй хис итә, хәтта

уң аягы бар, ул кычыта кебек тоела аңа... Ләкин бу хәл озакка бармый, тагын бөтен тәне буйлап ут тарала, күзләрендә бизгәк чаткысы кабына. Бераздан егет күз кабакларын акрын гына йома һәм, һушын югалтып, яңадан эссе томан эчендә йөзә башлый. Яткан урынын да, туташның кагылуын да, хәтта шприцның очлы энәсен дә ул инде тоймый...

Шулай үлем тырнагыннан ычкына алмыйча газапланып ята егет. Врачларның өметләре аз, гангренаның никадәр хәтәр нәрсә икәнен алар яхшы беләләр. Бигрәк тә юл шартларында авыруның хәлен җиңеләйтү бик читен эш иде.

Бу кечкенә станциягә килеп туктагач, күпмедер вакыттан соң, егет тагын бер мәлгә һушына килде. Талган, инде бу дөньядан китә башлаган күзләрен ачты, вагон эченә сибелгән зәгыйфь сары яктылыкны, шул тонык яктылыкта басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрде. Тышта вагон стенасына ышкылып кына яуган көзге вак яңгырның әкрен генә кыштырдавын ишетеп алды. Кара янып кипкән иреннәрен хәлсез ялап куйды – эчәсе, бик эчәсе килә иде аның...

Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

...Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йа Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы, куркынып, тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды.

Ә бу җыр чынлыкта бар иде, ул янәшәдәге эшелонның бер вагоныннан килә иде. Әгәр теплушка белән кызыл вагонның ишекләре бер-берсенә капма-каршы туры килгән булсалар, ишек яңагына сөялеп, кулларын шинель җиңнәренә тыгып җырлап торучы кыз, ихтимал, үзе дә күренгән булыр иде. Ләкин теплушканың аз гына ачык ишегеннән ут яктысы кыздан читкәрәк, кызыл стенага тар гына сары юл булып төшкән иде.

Күзгә күренмичә, берничә адымда гына җырлап торган кыз ялгызы гына булса кирәк, чөнки бүтән беркемнең дә тавышы-мазар ишетелми иде. Ихтимал, ул төнге дежурда торадыр, шунлыктан, ахрысы, иптәшләренең татлы йокысын бозарга теләмәгәндәй, ничектер тыелып, әкренрәк җырларга тырыша кебек... Әмма аның иркен, матур, аз гына калынрак күкрәк тавышы төнге тирән тынлыкта бик ачык булып ишетелә иде.

Кыз, үзенең ниндидер яраткан көен эзлиме, бер җырны башлый да, бетермичә икенчесенә күчә, бераз җырлагач, туктап тынып тора, аннан тагын акрын гына башлап китә. Үзенә күбрәк ошаган кайбер көйләрне озаграк та җырлап куя, әмма ул кем дә булса мине ишетәдер дигән уйны күңеленә дә китерми иде, әлбәттә.

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән

соң егетнең рухи хәлендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына – Таһирәнең кул сузымы гына җирдә җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да, барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, туган ил җыры... Аһ, моңнардан да кадерлерәк һәм ләззәтлерәк нәрсә булырга мөмкинме соң?!

...Һәм вагон стенасына ышкылып кына яуган вак яңгыр аша әкрен-ачык ишетелгән җыр, күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй, егетне ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып менеп китте. Аның хәтта тәне, һавада йөзгәндәй, җиңеләеп калды, акылы ничектер бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште. Җырны инде ул хәзер моң итеп кенә ишетмичә, гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе итеп тә күрә иде.

...Менә кыз әкрен генә башлап, аннан тавышын күтәрә төшеп, сузып кына җырлый:

Сарман буйлары, ай, киң ялан,
Печәннәре җитәр бер заман шул,
Печәннәре җитәр бер заман...

Һәм егетнең күз алдына үтә ачык булып, әллә кайларга кадәр җәелеп яткан чуп-чуар чәчәкле болын килә. Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп, йомшак кына җил исә, имеш. Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек, йомшак җил кибеп яткан покосларның хуш исен китерә кебек, тик егет печән чабучылар ягына нигәдер борылып карый алмый, имеш. Ул да булмый, аның күз алдына бормаланып киткән тар гына болын юлы килә. Хәтта бер мәлгә егет үзе дә ике рәт үлән арасындагы тәгәрмәч эзеннән, җылы туфракка яланаяк баса-баса, китеп бара кебек, ә каршысына киез эшләпә кигән, таяк таянган ак сакаллы бер бабай килә кебек.

Күпмедер вакыт узгач, кызның тагын моңлы җыры ишетелә:

Кояш бата, айлар калка,
Бик ямансу шул чакта...

Һәм егетнең күз алдына үзләренең шәһәрдәге кечкенә өйләре килеп баса. Эңгер-меңгер вакыты, имеш. Өйдә әнисе ялгызы гына икән. Менә ул, ак яулык бәйләгән кечкенә карчык, ут кабызып, бисмилласын әйтә-әйтә, тәрәзә пәрдәләрен төшереп йөри, тәрәзә төбендәге гөлләрнең кипкән яфракларын чүпләп-чүпләп ала, имеш. Өстәлдә яңа гына кайнап чыккан самавыр тора икән. Әнисе аның институттан кайтканын шулай чәй әзерләп көтә, имеш.

– Әнием, әнием! – ди егет, эченнән үксеп, һәм аның йомык күзләреннән сыгылып терекөмештәй кайнар яшь бөртекләре кипкән иреннәренә акрын гына тәгәрәп төшәләр. Шәфкать туташы кулын аның маңгаена куеп, иелеп, нидер сорый шикелле, ләкин егеткә гүя Таһирәсе дәшкән кебек тоела.

Шул чакта кыз тирән бер сагыш белән:

Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда... –

ди.

Һәм егет ике куллап, Таһирәсенең башын күкрәгенә кыса, имеш, йөзен аның күперенке чәчләренә куя, имеш, иреннәрен аның җылы, йомшак муенына тидерә, имеш:

«Бәгырем, бәгырем, күз нурым! Нигә алай дисең, нигә елыйсың? Без мәңге, мәңге бергә ич!»

Һәм кыз, башын аның күкрәгеннән алмыйча, назланып, зарын әйтә кебек:

Сагынам үзем, юлда күзем,
Саргайды нурлы йөзем...

Юк, юк, бүтән аерылу юк. Инде без бергә, дустым, мәңге бергә!.. Менә алар җитәкләшеп, ашыга-ашыга, Идел тавына менәләр, имеш. Тау бик биек икән, туктап-туктап тын алалар, кулларын җибәрмичә, сүзсез генә бер-берсенең күзләренә карап, бәхетле елмаялар, тагын кузгалып китәләр... Ниһаять, менеп җитәләр, йа Хода, нинди киңлек, нинди киңлек, нинди чиксез нур һәм ямь дөньясы бу туган җир! Шундый җиңел, шундый рәхәт аларга! Менә алар, тотынышкан хәлдә кулларын киң җәеп, таудан күтәреләләр һәм пар аккоштай елгалар, кырлар, урманнар өстеннән шул чиксез нур дөньясына очалар, очалар...

Кыз җырлавыннан кайчан туктады, каршыдагы эшелон кайчан тавыштынсыз гына кузгалып китте – егет моны сизмәде. Ул инде яңадан аңына килә алмады. Ә икенче көнне санитар поезды тагын бер җимерек разъездга җитеп туктады. Кызыл теплушкадан егетнең үле гәүдәсен носилкага салып чыгардылар да юлдан ерак түгел бер калкулык өстендәге ялгыз нарат төбенә илтеп күмделәр. Күмеп беткәч, туфрак өеменең башына кечкенә фанер кадакланган казык утыртып куйдылар. Фанерга кара буяу белән егетнең исеме, фамилиясе, туган һәм үлгән еллары язылган иде. Күмүчеләр, башларыннан салып, кабер әйләнәсендә бераз тынып тордылар да аннан барысы берьюлы вагоннарына таралдылар.

Поезд китте, ялгыз кабер торып калды.

Кинәт җил исте, биек нарат, эре яңгыр тамчыларын җиргә коеп, салмак кына башын чайкады. Күктәге салынкы соры болытлар, кемгәдер юл ачкандай, икегә аерылдылар. Шунда ук зәңгәр ачыклыктан, бәхилләшергә соңга калгандай ашыгып, кояш карады. Нарат төбендәге кабер өсте, әйтерсең, егетнең җирдә калган, үлмәгән һәм мәңге үлмәячәк якты хыяллары белән кинәт нурланып балкыды.

Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә чыннан да бу егетнең сөйгәне Таһирә иде.

*1956*

# ХАТЛАРДА – ӨЛКӘННӘР СҮЗЕ

*«Илләр күргәч»*

*Рәдифнең яңа шигырьләре*

*Шагыйрь зуррак дөньяга чыкса, шигырьгә барыбер яңа хис килеп керә, тематик яңалыктан тыш, яңа фикер, яңа деталь... Шагыйрьгә зур дөнья кирәк, өзлексез, туктаусыз, төрле халәттә, шатлык, фаҗига, каршылык көрәше һ.б. Париж шигырьләрендә шул публицистик колач, ритмик иркенлек, хисләрнең тыгызлыгы. «Казан утлары»нда Кара диңгез буе шигырьләре генә түгел, Париж шигырьләре дә басылып чыксын әле.*

**Сибгат ХӘКИМ.**
**16.03.77**

*«Казан утлары»на*

*Мөдәррис Әгъләмовның журнал өчен әзерләгән яңа шигырьләр циклын укыдым. Бүгенге поэзия миңа таныш нәрсә, көндәлек. Китап булып чыкканнары да, журналда басылып барганнары да һәм кулъязма хәлендәгеләре дә көндәлек таныш. Тәҗрибәм дә җитәрлек, көндәлекләрдән тупланган тәҗрибә. Шигырьнең төрлесен күрдем, төрле дәрәҗәдәгесен. Профессиональлеккә ирешкәннәрнең җайга салынган, шома, тигез, бер бураздан бер адым да читкә чыкмый аккан шигырьләрен дә күп укыдым. Карт, гомер иткән, язасын язып бетергән шагыйрьләр өчен мондый профессиональлекне мин гафу итәм. Әмма талантлы яшь шагыйрь профессиональлеккә күнексә, ул хәтәр. Димәк, ул шигырь техникасына төшенгән, серенә төшенгән. Күптәнге темасына гадәт буенча тәсбих төймәсен тарткан кебек тезеп кенә бара. Күпләр хәзер шулай. Мөдәррис Әгъләмов күнегелгән юлдан бармый. Гражданлык – төп юлы. Профессиональлыгы гражданлыгында. 1976 елда Зөлфәтнең шигырьләр циклын укып, бер рухи канәгатьләнү хисе кичергән идем, быел, 1977 елда, Мөдәррис шигырьләре Зөлфәткә җавап шикелле яңгырады. Шагыйрьдән мин шушындый борчулы, тынгысыз, раслый, бәхәсләшә торган хис, фикер, публицистик яну бергә кушылган шигырьләрне көтәм. «Лит. газета»да барган «Поэзиягә ни җитми?» дигән мәкаләләрнең сорауларына мәнә шушындый шигырьләр җитми дип җавап бирер идем. Мөдәррискә үзе кебек тәрҗемәче җитми. Менә нинди шигырьләр белән чыгарга кирәк зур мәйданга. «Казан утлары»на шушындый шигырьләр җитми.*

**Сибгат ХӘКИМ**
**27.09.77**

*«Казан утлары»на*

*Измайлова шигырьләрен Гамил Афзалга, Галимҗан Латыйпка берәр экземпляр бастырып, укып карар өчен җибәрсәгез иде, бәлки әзрәк уңайсызлану хисе туар иде аларда. Кайвакыт шулай янәшә куеп, чагыштырып карау файдалы. Илаһилык бетсә җанда, шигырь бетә, сүз тезмәсе генә кала.*

*Хатын-кызлар көнендә ичмасам әйбәт шигырьләр укыдым.*

**Сибгат ХӘКИМ.**
**8.03.78**

*Нури Арсланның «Яшә, илем», «Дөнья яшьләренә», «Янудан», «Аның күз яше», «Көзге төндә», «Күгәрченнәр», «Күзләренә карап», «Исән калды», «Беренче кар», «Бичара маэмай», «Ят була», «Яңа көй» шигырьләре.*

*Ачыла бара картлач. Ярый шушындый шагыйрьләр бар әле. Поэзия ничек булырга тиеш дигән сорауга Мөдәррис белән икесе җавап бирергә уйлаганнар. Фәкать шулай. Кушылам.*

**Сибгат ХӘКИМ**
**27.12.78**

*Рәдиф!*

*Салисә бик матур шигырьләр җибәргән, лирик кичерешләр, укып кара әле. Алдагы саннарга бәлки кереп китәр.*

*Син теге Черкез Алине онытма. Яхшы түгел, әзерлә, мин Мәскәүдән пленумнан кайтышлый Зәки белән сөйләштем аның турында. Ул яхшы белә аны. Зөлфәт, Мөдәррис, Р.Вәлиев, Ә.Гадел берәр-икешәр шигырь тәрҗемә итсә, шул җитәр.*

**Сәлам белән, Сибгат ХӘКИМ.**
**1.01.79**

*Бар да Равилчә. Уй күп, сагыш күп, моң күп, поэзия!*

**Сибгат ХӘКИМ.**
**17.04.79**

*Әхсән Баянның Яңа ел алды шигырьләре турында*

*Әхсәндә тыелган мәхәббәт, яшьлек, сагыш, төсләр-хисләр ташыган! Күптән болай ташыганы юк иде. Көтеп йөри идем, еракка китте дип. Күптән тоташ бер шундый цикл укыган юк иде. Күңел булды. Ярым-йорты түгел, тоташ, тулы, ахырынача. Шагыйрьнең шулай ачылуын, әйтеп бетергәнен яратам. Менә сиңа прозаик! Мин шагыйрьләрдә аз ялгыштым. Тагын бүтән яклары белән сөендерер әле поэзия. Талантлар яшәсен!*

**Сибгат ХӘКИМ.**
**25.12.79**

*Рәдиф!*

*Укыдым, сайлап карадым үземчә. Гәрәй күбрәк ошады. Рөстәм дә әйбәт. Равилнең дә традицоннары матур. «Будда» бик коры. «Чаян»га бәлки барадыр. Карагыз, басасыз икән, каршы түгел. Гамилнең лирик шигырьләре миңа якынрак.*

**Сибгат ХӘКИМ.**
**30.12.80**

*«Гасыр фаҗигасе» Илдар Юзеевның яңа әсәре*

*Тукай турында драма, музыкаль әсәр. Шигырь белән язылган. И.Юзеевның Тукай турында мондый күләмле драматик әсәре юк иде әле. Ләкин мин көттем, бу егет барыбер бер алыныр әле дип көтеп йөрдем. Нигә дисәң, И.Юзеевның шагыйрьлек рухын яхшы беләм мин. Тукайны да беләм. И.Юзеевта Тукайлык бар. Табигатендә, рухында. Поэмалар, драматик поэмалар, җырлар авторы. Бу рух Тукай белән кайчан да булса бер кушылырга тиеш иде. Менә ул хәзер кушылган. Тукай туган, халык эченнән аның «Туган теле» булып, мәңгелек җыр булып, улы, шагыйре булып туган. Халык эченнән... Әсәр шулай башлана, татар халкы тудыра, тарих тудыра. Әсәр башыннан ахырынача Тукай һәм халык белән бергә итеп күрсәтелә. Шул Тукай яшәгән заманның бөтен катлаулары, бөтен каршылыклары... Тукайның өмете «Уралчылар» белән, бу да әйбәт табылган! Тукай фаҗигасе – гасыр-халык фаҗигасе. Менә шушылай зур*

*планда бара драма. Сәнгать әсәре, плакат түгел, шигъри, музыкаль әсәр. Кайчан да булса сәхнәгә менәчәк. Йә опера, йә балет, яки башка бер формада барыбер бер сәхнә күрәчәк әсәр язылган. Музыканы үзе сорап тора. Хәзер эш композиторларда! Ышанам, туар.*

**Сибгат ХӘКИМ.**
**14.01.81**

*Дүрт кыз. «Яшьлек мәйданы»*

*Флёра Гыйззәтуллинаның мин белгән зур әсәре, поэмасы. Ватан сугышы еллары истәлеге. Яшьлек. Дүрт яшь кыз язмышы. Чыннан да Флёраның мин мондый әсәрен беренче тапкыр укыйм. Ни өчен ошады? Кыскалыгы, тыгызлыгы белән. Образлар шигъри. Хисләр шигъри. Ялыктырмый, теле әйбәт. Авторның шулай үз-үзенә зур таләбе ошады миңа. Нык утырганы сизелеп тора. Авторга бер киңәшем бар. Исемен «Дүрт кыз» дип куяр идем. «Яшьлек мәйданы» бик абстракт, бик гомуми. Әсәр бит конкрет – дүрт кыз турында.*

**Сибгат ХӘКИМ.**
**8.09.82**

*«Казан утлары»на*

*Шигырьләрне һәм поэманы укыдым. Нурия Измайловадан соң үземнең дә шундый шигырьләр язасым килде. Чын талант, халыкчан, гади, табигый, хисле, фикерле. Искиткеч җиңел ирешә кебек. Сүнмәсен генә!*

*Әхсән Баян – усал шагыйрь, талантлы. Прозаик буларак та, шагыйрь буларак та үзенчә, усал. Үз юлы. Үз карашы.*

*Гәрәйдән күбрәк көткән идем.*

*Рашат поэмасына «мин» җитми.*

**Сибгат ХӘКИМ.**
**19.09.83**

*«Казан утлары»на*

*Өч шагыйрь: Гамил Афзал, Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов... Иң тыйнагы, аз сүзле, образлысы – Рәшит Әхмәтҗанов. Шигырьләренең кадерен белеп яза, профессиональ таләп сизелә. Үзегез теләгәнен сайлап алыгыз дип тутырмаган. Өлгерү галәмәте. Шамил дә саран. Гамил бу юлы күп сүзле. Яхшысын да, уртачасын да бергә өя. Үземчә сайлап карадым. Матур әйберләр бар.*

**Сибгат ХӘКИМ.**
**26.11.83**

*И.Юзеев «Очты дөнья читлегеннән...»*

*Формасы белән бик үзенчәлекле, эчтәлеге фәлсәфи әсәр. Шигырь техникасына катнашырга хакым юк дип санап, мин әсәрнең драматургия өлешенә генә кагылам. Хәер, кагылып та тормыйм, чөнки ул бик зур осталык белән эшләнгән. Берничә сәнгатьнең бергә кушылуына карамастан, Музалар талашмыйлар, бертуган сеңелләр булып, тату яшиләр. Тукаебыз турында күп әсәрләр яздылар. Бу – чираттагысы. Тукайны олылап, тирән уйланып язылган поэма. Кызганыч, бүгенге безнең татарларыбыз мондый әсәрне сәнгати куярга әзер түгелләр. Шуңа күрә аны «Казан утлары»нда бастырып куярга кирәк. (Әдәби әсәр буларак, анда басылырга тулы хакы бар). Киләчәк режиссёрлары, композиторлар һәм башкалары поэманы укып сәхнәләштерү юлын да табарлар бәлки.*

**Туфан МИҢНУЛЛИН**
**4.03.81**

*И.Юзеевның «Олы юлның тузаны» поэмасы хакында*

*Миндә «сюжетлы» һәм «сюжетсыз» поэмаларның синтезы сыман тәэсир калдырды.*

*Бик тә йөрәктән үткәреп, реаль итеп сурәтләнгән көчле кеше образы – Фәнүс. Фаҗига бар – ләкин төчелек, мелодрама дәрәҗәсенә төшерелмәгән. (Илдар абыйның беренче поэмаларын искә төшерик).*

*Лирик пульс – таман. Артык та, ким дә түгел.*

*Поэманың үзәгендә – тулы канлы, көчле рухлы, реаль герой.*

*Бик кирәкле поэма. Мөгаен, поэзиядә бик әйбәт, яңа вакыйга булачак.*

**Зөлфәт**
**10 май, 1983 ел**

*«Казан утлары» редакциясенә*

*Н.Дәүлинең «Йөрәк турында сөйләшү» дигән поэмасын укып чыктым. Поэмага «Доктор Христиан Бернард белән әңгәмә» дигән аңлатма бирелгән. Х.Бернард – дөньяда беренче йөрәк күчерү операциясе ясаган хирург.*

*Автор поэмада кеше йөрәген күчерүгә, бер кеше әгъзасын икенче кешегә ялгауга каршы чыга. Ул мондый эшнең куркыныч нәтиҗәләргә китерүе ихтималлыгы турында әйтә.*

*Йөрәк күчерүгә бәйләп, автор тирән фәлсәфи, политик проблемалар күтәрмәкче була. Ләкин... булдыра алмый. Империалистларның әлеге фәнни казаныштан үз максатларында файдаланулары ихтималлыгын кисәтсә дә, Н.Дәүли бүгенге көннең медиклары ирешкән уңышны политика белән бутап, дөрес эшләми. Политикларның кеше йөрәген (күңелен) үзләренә буйсындырырга омтылулары өчен доктор Бернард гаепле сыман булып аңлашыла. Үз фикерен тәэсирле итү өчен автор Бернардны кеше үтерүчегә әйләндерә. Нииндидер бай, карт кешенең тормышын саклап калу өчен әлеге хирург аягы-кулы йөрми торган кыз баланы үтереп, аның йөрәген ала, имеш.*

*Автор Х.Бернард батырлыгының асылын аңламый. Бернард кеше үтерүче түгел, киресенчә, үлемгә дучар булган кешегә яңа йөрәк куеп, аның гомерен озайтучы. Аның методы нигезендә төрле илләрдә күп кенә кешегә йөрәк күчереп утыртылды, шулай ук башка әгъзаларны да күчереп утырту тәҗрибәсенең туктаганы юк. Йөрәге (әгъзасы) алынган кешеләрнең дә исемнәре билгеле дөньяга. Бу хакта бик күп галимнәр дә белә. Татар шагыйре Н.Дәүлинең бөтен дөньяны таң калдырган шушы бөек тәҗрибәгә каршы күсәк күтәрүе көлке дә, күңелсез дә.*

*Шуңа күрә поэманы журналда басарга тәкъдим итеп булмый.*

**Н.Фәттах**
**22.01.86**

*Рәдиф, сәлам!*

*Хатыңны алдым. Язганнарың мәгълүм булды. Сибгат абый белән бәхәсләшеп булмый инде, гәрчә мин ул шигырьләргә өметләр баглаган булсам да.*

*«Хатыннар хөррияте» дигән озын шигырь турында бер сүз дә әйтмисең син, неужели ул да ошамады?*

*Сезгә восторг кирәк икән, ай-яй, брат, кемнәрдән табарбыз икән аны? Менә, бер бәйләм шигырьләр җибәрә торам. Җәй көне Казанга килермен әле, шунда гәпләшербез.*

***P.S.** Китабың чыкканын ишеттем, котлы булсын!*

**Гамил АФЗАЛ**
**1.04.78**

*Хатлар* **Рәдиф ГАТАШ** *архивыннан алынды*

## Илдар Юзеев

### Өч авылдан чыккан өч гали җан

Өчиледән чыгып киткән Тукай,
Шигъриятнең серле йомгагын,
Очын табып ерак гасырлардан,
Миллион күңелләргә чорнадың.

Сыркыдыдан чыгып киткән Такташ,
Шигъриятнең серле йомгагын
Сүтә-сүтә, киләчәккә илттең
Заманыңның шашкын моңнарын.

Мостафадан чыгып киткән Җәлил,
Шигъриятнең серле йомгагын
Сүтә-сүтә, дөнья буйлап киттең,
Үлемсезлек җырын җырладың.

Өч авылдан чыккан өч гали җан
Биеклектән карап көтәрләр:
Серле йомгак очын, югалтмыйча,
Кемнәр кая алып китәрләр...

*«Казан утлары». 1976 ел, 5нче сан.*

## Гамил Афзал

### Онытыма хат

Томан булып күтәреләм иртән,
Һәм чык булып төшәм кичләрен.
Тел шартлатып карап йөрим читтән
Онықларның кырган эшләрен...

Бөтен тирә мәрмәр, пыяла, чәчәк,
Хуш бакчалар белән бизәнгән
Матур заманнарда яшәячәк
Онытыма сәлам җибәрәм.

Исән-таза гына ятасызмы,
Сәламәтме бала-чагагыз?
Без әбиең белән дөнья артыннан
Чабабыз да һаман чабабыз.

Мин күп белмим, лектор сөйләмәсә,
Син яшәгән заман хакында.
Үзең белән илне бизәп яшә,
Үзең белән җирне матурла!

Фараз кылам: сездә космонавтлар,
Ракеталар белән күк тулыр,
Җанга куәт биргән ак канатлар –
Шигырьләр һәм җырлар күп булыр.

Сез шагыйрьләр булып туарсыз да,
Шигырь белән буа буарсыз.
Карап карыйк. Безнең китапларны
Кайсы шүрлекләргә куярсыз?

Бабайлардан танавыңны борма
Шигырь мәйданында ярышта.
Айга менеп, Тукай җырын җырла,
Такташ шигырен укы Марста!

Мин йөземне борып сезнең якка,
Тәмле-татлы уйга талырмын.
Каберемә басып киткән чакта
Табаныңны үбеп калырмын.

*«Казан утлары». 1965ел,11нче сан.*

# Шәүкәт Галиев

***

Минем гомер, нәсел җебе буйлап
Бик еракка барып тоташа –
Килгән күпме үлемнәрне җиңеп,
Килгән күпме хәвеф, ут аша.

Гасырларны кичеп агып килгән
Миңа бабайларның каннары.
Сеңгән аңа күз яшенең тозы,
Алсулыгы сеңгән таңнарның;

Кубыз, сорнай, гөслә моңнарыннан
Нечкәргәннәр күңел кыллары,
Ә күзләргә рәсем булып төшкән
Болгар сылуының сыннары.

Бөтен тарих үткән йөрәк аша,
Берсеннән дә читтә калмаган –
Гүзәллекләр аны иркәләгән,
Хаксызлыклар аны талаган.

Гомер арты гомер алмашынган,
Офык арты офык ачылган.
Тел очына килгән җыруларны
Әйтәлмәүдән бабай ачынган.

Күңелләрдә калган бик күп хисләр
Бөреләнгән икән җыр булып –
Каләм төрткәч, гасыр төпләреннән
Басым белән чыга ыргылып.

Алар әйтеп өлгермәгәнне дә
Мин әйтергә бүген тиешле.
Шигырь ритмын бирә буыннардан
Күчеп килгән йөрәк тибеше.

Ничек миңа шуның кайнарлыгын
Һәм исерткеч дәртен тоймаска –
Минем каным мең ел куәт җыйган
Шәраб кебек кайнап кояшта!

*«Казан утлары». 1966 ел, 10нчы сан.*

# Әхсән Баян

***

Була сүзләр – тыныч, йомшак сүзләр,
Яфрак сулышына охшаган.
Кычкырмыйлар тамак карлыкканчы,
Мин ишетәм ләкин, ышанам.

Була сүзләр – ничек сөйләсәң дә
Оят түгел – изге, гөнаһсыз.
Заман, мәйдан, эшләр, гөрелтеләр
Капламый һич – барысы зыянсыз.

Була сүзләр – чәнечкеле еллар
Аша карый безгә миллион күз:
Җәлил кебек ирләр... Мин ышанам.
Кычкыралар алар тавышсыз...

Була сүзләр – кычкырсаң да, ләкин
Мин ышанмыйм яман сүзләргә.
Сөйлә, дустым, мин ишетәм сине,
Мин ышанам сөйгән күзләргә.

*«Казан утлары». 1969 ел, 6нчы сан.*

# Әнгам Атнабаев

## Кешегә нәрсә җитми

Бу кешегә һәрчак нәрсә җитми:
Кара икмәк булса, ак җитми,
Шуышып йөргән чакта аяк җитми,
Җәяү йөргән чакта ат җитми.
Аты булса, машинасы җитми,
Очар өчен ракетасы җитми...
Планетасы житми... Күк җитми...
Бу кешегә ифрат күп җитми!

Шул кешегә ләкин кайчагында:
Башларына кайгы төшепме,
Бинахакка гаеп күтәрепме,
Гамьсезләнгән җаны өшепме,
Ап-акны да кап-карага буяп,
Матурны да ямьсез күргәндә,
Якты дөнья белән бәхилләшеп,
Һәлакәтен эзләп йөргәндә, –
Шул юлыннан тартып алыр өчен
Кешегә бит ифрат аз җитә –
Бер җылы сүз –
Күңел эретерлек наз җитә!

*«Казан утлары». 1967 ел, 4 нче сан.*

# Роберт Әхмәтҗанов

***

Кырларда җил. Җитен кырларында,
Җитен диңгезендә – бүген җил.
Җитен җилли. Зәңгәр дулкыннарда
Кыр тургае йөзә... Туган җир!
Җитен җилли офыкларга тулып,
Ишелеп-ишелеп кайта юлларга...
Бала тургай. Таныйм! Ул тумыштан
Пропискада безнең кырларда...
Тугрылыклы. Нәни метеор сыман
Кыр өстендә риза янарга.
Яшел кыяклардан – камылгача
Басуда ул, төшә камылга...

Яшь тургайлар менә,– яңа буын,
Туган ягым күгенә, алмашка.
Күгем тулы тургай! Яздан көзгә...
Мөмкин түгел җырда янмаска!

Карт игенче, соң кат «хуш!» дигәнче,
Һаваларга карар иң элек:
Зыңлап калыр гомер иткән дөнья,
Күк юлына биек чөелеп.

*«Казан утлары». 1969ел, 6нчы сан.*

# Сажидә Сөләйманова

***

Әй, солдатлар, тигез, кыю басып,
Үтмәгезче безнең урамнан.
Кирза итек, иңбашларда мылтык,–
Артыгыздан калмый оланнар.
Яңартмагыз утлы еллар җырын,–
Улым үсеп килә, улым...

Әй, солдатлар, сез атлаган чакта,
Тынып торсын шаулы урамнар.
Адым тигез, балкый кызыл йолдыз,–
Сезгә тигезләнә оланнар,
Һай күп әле җирдә җәбер-золым...
Улым үсеп җитте, улым.

*«Казан утлары». 1969 ел, 5нче сан.*

# Гөлшат Зәйнашева

***

Тәрәз төбемдә гөлем бар.
Күчереп утыртсам сула.
Йөрәгем – шул гөл яфрагы,
Ерак калса ил туфрагы –
Өзелеп төшәрдәй була.

*«Казан утлары». 1967 ел, 3нче сан.*

# Клара Булатова

## Язлар алда

Чук тәлгәшле каеннары белән,
Камышлары белән ярдагы,
Кайнар яшьле кайгылары белән,
Сагышлары белән җандагы,
Әле генә кар юрганын салган

Яшел уҗым белән кырдагы,
Яңа гына үргә менеп барган
Дәртле җыры белән юлдагы, –
Бар байлыгы белән ничек инде
Җирне шулай ташлап китәсең?

Әй, җиңел дә күңел, галәм гизә.
Хыял җиле, кая илтәсең?
Әнә, язлар җитә: җиргә кара!
Уйсу төшләр һаман кар әле,
Язлар алда, синең ул язларда
Яңгырыйсы җырың бар әле.

*«Казан утлары». 1966 ел, 6нчы сан.*

# Марс Шабаев

## И татар гынам...

*А татарчёнку хочется напиться.*
Дм. Кедрин.

Шагыйрь теленә кергәнсең икән,
И татар гынам, татар баласы!
Хәмерләр эзләп йөрергә кая –
Бер сынык эзләп читкә баргансың.
Чәчелгәнсез дә дөнья буйлатып,
Милләтнең эшчән ир-егетләре.
Чәчрәгән сезгә авыр тормышның
Шәрабы түгел, гел күбекләре.
Шундый булган ул синең сәрхушлек,
Дөнья ачысы сине исерткән.
Куган чактамы берәр ишектән,
Аһ-зарларыңны шагыйрь ишеткән.
Бәлки, син аңа, телең сындырып:
«Куалар... вот как...» – дигәнсеңдер дә.
Ул «водка» диеп аңлап калгандыр...
Юк, үпкәләмим аңа мин бер дә.
Төрле тел түгел, бер үк телдә дә
Кеше бер-берсен аңламаганда,
Рәсәй илендә, кая барсаң да,
Кан-яшь эчкәнсең син ул заманда.
Шулай йөргәнсең кагылып-сугылып,
Тик бетмәгәнсең сынып-сыгылып...
Синең мескенлек, синең сәрхушлек
Чит-ят җирләрдә калсын егылып.
И татар гынам, татар баласы,
Чәчелгәнсең лә син туган җирдән...
Тел очындагын әйтмәгән шагыйрь:
Хөрлек хәмерен эчәсең килгән.

*«Казан утлары». 1992 ел, 5нче сан.*

# Марат Кәримов

## Кемгә – ничек

Берәүләргә хаклык түшәм кебек,
Түшәм ныклы икән – бул тыныч.
Җил-яңгыр да сиңа тими үтәр,
Бураннар да булмас куркыныч.

Ә берәүгә хаклык идән кебек,
Шунда басып йөри һавалы.
Шак-шок итә пычрак итекләре,
Ул итекләр корыч дагалы.

*«Казан утлары». 2002 ел, 2нче сан.*

# КАЛЫН ЖУРНАЛ

## «Казан утлары» балкышы

1953 елдан илдә тарихка «Хрущёв җепшеклеге» буларак кереп калган дәвер башлана. Шәхес культының фаш ителүеннән юл алган үзгәрешләргә – Бөек Ватан сугышында җиңү шатлыгының көче сүрелмәү, сугыштан кайтучыларның күңел күтәренкелеге һәм тормышның үзгә юл белән үсәчәгенә ихлас ышанычы, илне төзекләндерүнең зур тизлек белән баруы, икътисади-иҗтимагый өлкәләрдә алгарыш килеп кушыла. Болар әдәби-мәдәни барышка да гаять көчле тәэсир ясыйлар.

Татар әдәби-мәдәни процессында 1950-1960 еллар чигендә башланган яңарыш тамырлары белән илдәге хәлләргә барып тоташа. Ләкин татар әдәбиятында бу хәрәкәтнең үсеш юнәлешләрен җепшеклекне иртәрәк тойган рус әдәбияты түгел, бәлки татар зыялыларының милли әдәбият язмышы хакындагы күзаллаулары билгели. М.Җәлил, Х.Туфан кебек шагыйрьләрнең исеме аклана һәм иҗатлары әдәби барышка кабат килеп кушыла, моңа кадәр тыелып торган Ш.Бабич, Ф.Борнаш, Дәрдемәнд, Н.Думави, С.Сүнчәләй кебек әдипләр мирасы татар укучысына әйләнеп кайта. Боларны әдәби журналыбыз һәм язучылар башлап йөри. 1950 еллар ахырыннан татар язучы-шагыйрьләренең тормышны сурәтләүдә үзгә бер дулкынга көйләнә башлавы тоемлана. Журнал битләрендә дөнья күргән шигъри әсәрләрдә, хикәя-повестьларда туган җиргә – татар җиренә мәдхия, аның табигате, бәйрәм-йолалары, әниләр, алар биргән әхлак дәресләре, юлбарыстай сугышкан татар батырлары образлары пәйда була.

Бу яңарыш татар язучыларының дөньяга карашларындагы яңа сыйфатлар, аларның нинди кыйммәтләргә йөз тотуы һәм иҗатка мөнәсәбәтләре белән бәйле була. Мәсәлән, шул елларны искә төшереп язылган «Четерекле булды безнең заман» дигән истәлекләрендә (2013, № 8) язучы Нурихан Фәттах болай ди: «Безнең дә үз халкыбызны данлы итәсебез килде. Безне иң элек, барыннан да элек, әдәбият, культура кызыксындырды. Кешене кеше иткән, халыкны халык иткән нәрсә – әдәбият. Югары дәрәҗәдәге әдәбият. Барлык халыклар кызыгып, көнләшеп укырдай әдәбият. Еш кына миңа шулай тоелды. Еллар буе мин үземне шундый югары әдәби әсәр иҗат итү өчен әзерләдем».

Мондый омтылыш, татар әдәбиятын үстерү һәм аны, XX гасыр башындагы кебек, милләткә хезмәт иттерү теләге татар язучы-шагыйрьләрен берләштерүче, аларны иҗатка илһамландыручы фактор була. Нәкъ менә шул дулкында журнал яңарыш чорына килеп керә, аның битләрендә хөр фикер, өр-яңа тематика, авангард әдәбият үрнәкләре күренә башлый.

Татар әдәбиятындагы яңалыклар, иң беренче нәүбәттә, көчле кеше тәгълиматын шәрехләп, аны соцреализмдагы массалар көченә каршы куюда күренә. Аерым әсәрләрдә, хис-кичерешләрдән бигрәк, акылга тәэсир итү, ягъни фикер кыюлыгын алга сөрү, яшерен, катлаулы, ассоциатив эчтәлек тудыру, образларның күпмәгънәлелеге белән уйнау күзәтелеп, алар укучыда да аерым әсәрләрдән тыелган, яшерен эчтәлек эзләү омтылышы китереп чыгара. Нәкъ менә 1960 елларда журнал «советча ук булмаган» әдәби әсәрләр бастыруы белән укучыны үзенә җәлеп итә.

1960 елларда «Казан утлары» журналы совет чорында формалаштырылган, 1917 елга кадәр татар тормышы караңгы, мескен, надан булган дигән карашны юк итүгә күп көч куя. Әдәби яктан, бу юлда беренче карлыгачлардан булган әсәр – Г.Бәшировның

*Дәвамы. Башы 18 нче биттә.*

«Туган ягым – яшел бишек» повесте 1967 елгы 5-11нче саннарда тулы килеш диярлек басылып чыга, укучысына татар халкының ярдәмләшеп яшәү рәвешен, кешеләрнең аң-белемгә омтылышын, уңганлыгын, йола-гадәтләрнең күркәмлеген күрсәтеп сокландыра. Ф.Хөснинең, И.Газинең детальләрдә – матурлык тергезгән халыкчан-сыгылмалы хикәяләве, М.Мәһдиевнең татар авылын, аның яшәү рәвешен илаһилаштыруы, А.Гыйләҗевнең татар дөньясының җимерелү сәбәпләрен барлавы, Ш.Хөсәеновның, Г.Афзалның җәмгыятьтәге «яшерен чирләрне» әдәбият мәйданына менгерүе, С.Хәкимнең, И.Юзеевнең, Х.Туфанның, яшьрәк буын шагыйрьләр М.Әгъләм, Роб. Әхмәтҗанов, Р.Вәлиев, Р.Гаташ, Зөлфәт, Р.Миңнуллин, Р.Харис һ.б. талант ияләренең милли яшәешкә хас кыйммәтләрне эзләве – гомумән алганда, татар сүз сәнгатенең тасвирлау объектын тамырдан үзгәртә, матур әдәбият үз укучысы белән милләтенең-халкының тормышы-яшәеше хакында ачыктан-ачык сөйләшүгә чыга. Шигърияттә, фәнни-публицистик язмаларда татар рухын үзенә лаек биеклектә яктырту, аның тарихи хәтерен яңарту, проблемалары хакында сөйләшү кызыл җеп булып сузыла. Яңарыш хәрәкәте татар әдәбиятының милли традицияләренә әйләнеп кайтуын тәэмин итә.

1960-1980 елларда да мәдәни-әдәби мәйданда көчле бер күзәтү-басым яшәп килә. Бу хәл журналның материалларны «җиз иләк» аша уздырып тәкъдим итүендә дә күренә. Үзенең «Кырык дүртнең май аенда» (1965) әсәренең журналдагы язмышы хакында Н.Фәттах болай дип искә төшерә: «Бөтен илдә барган җанлану, баш калкыту җилләре белән рухланып, сугыш елларындагы авыл тормышы турында озын гына бер хикәя яздым. Хикәя башта «Кырык дүртнең май аенда» дип аталды. Хикәядә үзем күргән, үзем татыган тормышны мөмкин кадәр, батырлыгым җиткән кадәр дөрес итеп, кискен итеп күрсәтергә тырыштым. Ләкин ул шундый усал һәм дөрес булып чыкты ки, миңа иң теләктәш кешеләр дә каушап калгандай булдылар. Хикәянең баштагы вариантында туган авылына торф эшеннән качып кайткан яшь хатын, дөньяда яшәү өчен берninди мөмкинлек юклыгын күреп, имчәк баласын юл буенда ташлап калдыра, үзе акылдан яза. Укыган абзыйлар хикәянең азагын яхшылык, яктылык белән тәмамларга киңәш иттеләр. Исеме дә үзгәрде. Заманга, стройга протест булып аңлашылмасын өчен, хикәя «Артта калган юллар» дип аталды. Шул исемдә ул 1965 елда «Казан утлары»нда басылып чыкты. Икенче вариантта яшь ана баласын ташлый ташлавын, шулай да аңа юлда бер атлы кеше очрый. Ул кеше сугыштан яраланып кайткан райком секретаре икән. Хәмдиягә ул туры юл күрсәтә. Шулай итеп, «юлдан язган» ананы да, баланы да партия коткарып кала. Хәзер инде хикәянең идеясе тәртәгә керде. Менә дигән социалистик реализм» (2013, № 8).

Ләкин әсәр бу вариантта да тәнкыйтьләү объектына әйләнә, авторның үзен дә, редакцияне дә сәяси гаепләүләргә сәбәп була. Аның тулы варианты, повесть рәвешендә, үзгәртеп корулардан соң гына дөнья күрә.

Гомумән алганда, чор әдәби һәм публицистик иҗатында советчыл җәмгыятьнең ялгыш асылына караган күзәтүләрне, кимчелекләрне ачыктан-ачык, «күзгә бәреп» сөйләмәгәндә дә, ниндидер киеренкелек, тынгысызлык тудырыла. Бу хакта фикерләрне без Ә.Еникинең Х.Сарьян иҗатына бәясендә очратабыз: «Сарьяндагы җан тынычсызлыгы һәм канәгатьсезлек кайдан ул, нәрсә аркасында, ничек туган?.. Дөресен генә әйткәндә бит, тынычсызлык белән канәгатьсезлек безнең күбебездә бар иде, чөнки без кичергән заманның ялганнарын, кимчелек һәм гаделсезлекләрен күзе ачык кешегә күрмичә тору мөмкин түгел иде. Тик менә күрә торып та шулар белән килешә алмый, борчылу, ризасызлык белдерү кадәрлесе бер түгел – бусы инде төрле кешедә төрлечә. Сарьянның да бөтен тормышы һәм рухи халәте әнә шул без күреп уздырган ясалма-ялган заман белән турыдан-туры бәйләнгән иде. Һәм икеләнмичә әйтәсем килә, аның күңел сизгерлеге һәм эчтән уйланулары күпләрнекеннән тирәнрәк тә, газаплырак та булып чыкты» (Еники Ә. Сарьян // Сарьян Х. Бер ананың биш улы: Повесть,

хикәяләр. Казан: Татар.кит. нәшр., 2000. Б. 6). Күп кенә татар язучылары бу чорда үз әсәрләрендә менә шул үз борчуларын, советчыл тәртипләрдән канәгатьсезлекне, аның милли әхлакны һәм күзаллауларны җимерүен «күзгә бәреп» түгел, бәлки тоемларлык итеп җиткерә белделәр. Журнал исә мондый әсәрләргә мәйдан бирүдән баш тартмый: шуның белән үз укучысын һәм әдәбиятка җылы мөнәсәбәтне саклап кала.

Дөрес, журнал эчтәлегендә советчыл очеркларны да, партиягә дан җырлаган шигырьләрне дә күпләп табарга була. Әйтик, редакция Г.Гобәйнең дингә каршы язылган пасквилен – «Коръән серләре»н бастырырга (1966, № 1-6) мәҗбүр була. Г.Бәшировның «Кыйбла билгеләгәндә» истәлегендә (1992, № 5) бу дәвердә әсәрләрне «өстән кушып яздыру» күренеше дә телгә алына.

Шушы чорда журналда үткән мирасны барлау, күренекле шәхесләрнең якты исемен халыкка кайтару, татар мәдәниятенең инкыйлабка кадәрге асыл сәхифәләрен җиткерү активлаша. 1965 елның август саныннан баш мөхәррир булып Рафаэль Әхмәт улы Мостафин (1931-2011) килгәннән соң, бу эш тагын да җәһәтрәк төс ала. Бигрәк тә Муса Җәлилнең шанлы исемен, каһарманлыгын, әсәрләрен халыкка җиткерү ягыннан зур эш башкарыла. Әйтик, журналның 1965 елгы 6-12нче саннарында бу хакта күп язмалар дөнья күрә, 1966 елгы 2 сан шагыйрьнең 60 еллыгына багышлана. Аерым язучыларның юбилейларына махсус номерлар әзерләп бастыру традициясе ныгый. Ф.Әмирханның тууына 80 ел (1966, № 1), Тукайның тууына 80 ел (1966, № 4), А.Алишның тууына 60 ел (1968, № 9) һ.б. тулуга багышланган саннар шундыйлардан. Бу татар милләтенең тарихына караган күп яңа материалларны укучыга җиткерергә мөмкинлек бирә. Әйтик, Ф.Әмирханга багышланган сандагы Ш.Байчура истәлеге – мәдрәсәләр тарихы, татар театрының тууы («Шимбә» түгәрәге) турында сөйли. Бигрәк тә XX гасыр мәдәнияте тарихына кагылышлы бик күп яңалыклар журнал битләрендә яктыртылалар.

Г.Ибраһимовның тууына 80 ел тулуга журналның 1966 елгы 10-12нче, 1967 елгы 1-2нче саннарында махсус сәхифә бирелеп, 3 сан тулысынча шуңа багышлана. Әлеге материаллар белән танышканда, редакциянең совет идеологиясе куйган идеаллаштырылган схемалардан баш тартып, шәхесләрнең холкы-фигыле, гаиләсе, башкалар белән мөнәсәбәтләре хакында ачыктан-ачык сөйләшүне өстен күрүе күзгә ташлана.

Шулай ук мисалга 1966 елгы саннарны алганда да, 9нчы санда – Х.Фәезхановның тууына 145 ел тулу уңаеннан, 11нче санда – Солтан Рахманколый турында күләмле язмаларны аерып күрсәтергә мөмкин. Ф.Вәлиевнең татар сәнгате, Ә.Кәримуллинның – басма китап тарихы буенча мәкаләләр цикллары да татар мәдәниятенең байлыгын, тирәнлеген төрле яклап бәяләү максатына хезмәт итә. Әдәбият тарихына караган материаллар биреп бару журнал өчен гадәткә әйләнә, әдәби тәнкыйтьтә катлаулы сораулар күтәрү күзәтелә («»Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе» / Р.Фәйзуллинның әдәбият галиме И.Нуруллин белән әңгәмәсе (1978, № 3)). Мондый текстлар язучының да, укучының да әдәбиятка карашын-мөнәсәбәтен җитди бер дулкынга көйлиләр.

Шулай да 1960-1980 елларда «Казан утлары» журналына хас төп сыйфат итеп аның татар дөньясына – милли-мәдәни тарихын кайтару чарасына әйләнүен күрсәтергә кирәк. Бу аңлашыла да: әлеге чорда татар телендә фәнни-популяр мәгълүматларны киң катлау укучыга җиткерә торган башка мондый мәйдан юк!

Иң беренче чиратта ул, дәвер биргән иҗтимагый-сәяси мөмкинлекләрдән файдаланып, зыялы татар укучысына үз халкы тарихының моңа кадәр яшереп яки кысрыкланып килгән, өйрәнергә рөхсәт ителмәгән яки эчке цензура тарафыннан хупланмаган сәхифәләрен – аерым чорлар, вакыйгалар, шәхесләр турында мәгълүматларны – үз телендә җиткерү, алар хакында фикерләшү мөмкинлеге бирүе белән үзенчәлекле һәм, әйтергә кирәк, бердәнбер басма булып җитешә. Бу юнәлештә берничә галимнең хезмәтен аерып күрсәтергә кирәк: Миркасыйм Госманов тырышлыгы белән этрафлы, үтемле итеп, нәкъ менә үз милләте язмышында уйнаган

роленә басым ясап, татар дөньясына Ш.Мәрҗани (1968, № 1), Мөхәммәдъяр (1968, № 2), Х.Фәезханов (1971, № 3; 1978, № 9), Кол Гали (1983, № 9) һ.б. бөек шәхесләрнең исеме, хезмәтләре, әсәрләре, мохите турында мәгълүмат җиткерелә. Галим популяр тел белән гасырлар чоңгылына, чишмә башы белән хуннар дәверенә үк китә торган мәдәният тарихыбыз турында сөйли («Язма мирасыбызның күтәреләсе катламнары»: 1984, № 5), татарларның мәгълүм баш күтәрүләрдәге урынын барлый (С.Алишев белән бергә, «Бөек крестьяннар сугышына 200 ел»: 1973, № 9), татар кулъязмаларын барлау, өйрәнүгә кагыла («Саклап каласы иде»: 1978, № 10), «»Хан кызы» җыры: эзләр дастанга илтә»: 1981, № 8) һ.б.

Аның белән иңгә-иң торып, бер дулкында Яхья Абдуллинның татар акыл ияләре, мәгърифәтчеләре һәм философлары хакында бер туплам язмалары тәкъдим ителә (1974, № 2; 1974, № 10; 1975, № 2; 1975, № 11; 1976, № 10; 1977, № 1; 1978, № 7; 1978, № 9; 1980, № 6; 1983, № 6; 1985, № 1 һ.б.), алар милли иҗтимагый фикер тарихына һәм мәгърифәтчелек хәрәкәтенә генә түгел, җәдитчелеккә, руханилар эшчәнлегенә, ислам диненә, мәктәп-мәдрәсәләргә карашны тамырдан үзгәртүгә хезмәт итәләр. Журнал битләрендә озак еллар дәвамында максатчан «оныттырылган» Һ.Атласи (Госманов М.Г., Абдуллин Я.Г., Таһиров И.Р., тууына 100 ел тулу уңае белән «Тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Атласи»: 1986, № 11), С.Вахиди (Госманов М. «Сәет Вахидиның игелекле мирасы»: 1987, № 5) һ.б. күп кенә фидакарь шәхесләребез хакында мәгълүмат беренче булып фәнни әйләнешкә кертелә.

Бу чорда журнал татар әдәби-мәдәни мирасын (халык авыз иҗаты, кулъязмалар һәм басма китаплар, аерым әсәр текстлары) барлау белән дә максатчан, эзлекле шөгыльләнә. Әйтик, Марсель Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре һәм аларның төрләре» (1978, № 3), «Ләйлә белән Мәҗнүн» кыйссасының татарча варианты» (М.Гайнетдинов белән берлектә, 1979, № 6), «Риза Фәхретдинов шәҗәрәсе» (1984, № 1), «Г.Кандалыйның яңа табылган әсәрләре» (1984, № 9), «Ф.Әмирхан архивыннан» (1986, № 1), «Г.Ибраһимовның автографлы китабы» (1987, № 3), «»Таһир белән Зөһрә» дастаны» (1987, № 4) һ.б. язмалары шундыйлардан.


Заманның – совет заманы икәнен тагын бер кат ассызыклап, журнал хезмәткәрләренең гражданлык батырлыгына да аерым игътибар итәргә кирәк. Язучыга һәм редакциягә дә күп авырлыклар китергән М.Мәһдиевнең «Буби мәдрәсәсе» (1969, № 12), А.Фәтхинең татар-башкорт мөнәсәбәтләренә багышланган, бүген дә актуальлеген җуймаган «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр» (1968, № 2) кебек язмалар – шушы фикеребезгә ачык мисаллар.

Безнең карашыбызча, бу дәвердә журнал фәнни яктан, галимнәрнең төпле язмалары хисабына үзгәреш кичерә, укучылар туплый, үзе дә яңа буын татар кешеләрен тәрбияләүгә, яшьләрнең милли үзаңын үстерүгә гаять зур өлеш кертә. «Казан утлары» исемен алган журналның популярлыгы гаять нык үсә, ул, чыннан да, татар дөньясына нур сибүче яктылык чыганагы булып хезмәт итә. Татарстанда гына түгел, татарлар яшәгән һәр төбәктә аның һәр номерын көтеп алалар, укучы һәр яңа санны гына түгел, андагы яңалыкны зарыгып көтә, журнал редакциясе исә бу өметләрне акларга тырыша.

1972 елны редакция хезмәткәрләре журналның тиражы хакында мәгълүмат бирәләр. 1941 елда 5 меңнән артса, 1944 елга 10 мең чиген үтә. Үсешнең иң зур өлеше 1960 елларга туры килә: 1965 елда – 20 мең, 1967 елда – 57 мең, 1968 елда – 65 мең, 1969 елда – 84 меңгә, 1970 елда – 88 меңгә җитә. Алдагы елларда иң югары күрсәткеч 1978 елга туры килә – 94,5 мең. Аннары инде кимү күзәтелә (Сүнмәс утлар балкышы: Мең санлы хәзинәдән. Казан: «Идел-Пресс» полиграфия-нәшр.комплексы, 2006. 297 б.).

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*





ТАССР
„СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ“
ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ
Татарстан Совет Язучылары Союзы Органы
Казан, Бауман урамы, 19
Матбугат йорты
Телефон № 83-45

ТАССР
РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛА
„СОВЕТ ЭДЕБИЯТЫ“
(Советская литература)
Орган Союза Советских Писателей Татарии
Казань, ул. Баумана 19, Дом печати.
Телефон № 83-45.

№______ „___“__________194 г.

*Сибгат Хәким фронтта һәм аның «Совет әдәбияты» журналына язган «Фазыл чишмәсе» шигыренең кулъязмасы.*



*Афзал Шамов – «Алга, дошман өстенә» газетасының (Калинин фронты) хәбәрчесе. 1943 ел, 5 май.*




*Габдрахман Әпсәләмов (икенче рәттә сулдан беренче) – «В бой за Родину», «Сталинский воин» фронт газеталарының корреспонденты сугышта катнашучы дуслары белән. 1943 ел, 5 май.*



*Әбрар Кәримуллин. 1946 ел*




*Муса Җәлил*



Дорогой Кашшаф! 27.V.42

*Муса Җәлилнең фронттан Гази Кашшафка язган хатының беренче бите. Хат рус телендә язылган. 1943 ел.*



Nr 2968

Berlin – Charlottenburg – – , den 26. August 1944.

Der Schriftsteller Abdull A l i s c h e w,

mohammedanisch,

wohnhaft in ~~Berlin~~ Kasan, Straße Jerjinski 18/19,

ist am 25. August 1944 – – um 12 Uhr 12 Minuten

in Berlin – Charlottenburg, Königsdamm 7 – – – – – verstorben.

Der Verstorbene war geboren am 15. September 1908

in Kajuki/Rußland

(Standesamt Nr. )

Vater: Abduil Bari Alischew, letzter wohnort unbekannt

Mutter: Gasisa Alischew, Mädchenname unbekannt, wohnhaft Kasan

Der Verstorbene war – ~~nicht~~ – verheiratet mit Rakia Alischew, geborenen Tulbanoa.

Eingetragen auf mündliche ~~– schriftliche~~ – Anzeige des Hilfsaufseher Paul Dürrhauer, Berlin, Manteuffelstraße 10.

Der Anzeigende ist bekannt und erklärte, er sei vom Tode aus eigener Wissenschaft unterrichtet.

Vorgelesen, genehmigt und unterschrieben

Paul Dürrhauer

Die Übereinstimmung mit dem Erstbuch wird beglaubigt.

Berlin-Charlottenburg, den 26. August 1944


Der Standesbeamte

In Vertretung

Der Standesbeamte

Gluck.

*А. Алишның үлеме турындагы таныклык. 1944 ел, 25 август, 12 сәгать, 12 минут*



*Абдулла Алиш*



*Фатих Кәрим*




*Гадел Кутуйның соңгы фотосы. Польша, 1945 елның язы.*





Гариф Ахунов

*Ибраһим Салахов*



УДОСТОВЕРЕНИЕ

Выдано тов. ДАВЛЕТШИНУ
Набиулла Хасановичу

в том, что постановлением президиума Советского комитета ветеранов войны он(она) награждается „Почетным Знаком СКВВ“

Председатель
Советского комитета ветеранов войны
генерал армии
П. БАТОВ

Ответственный секретарь
Комитета
А. МАРЕСЬЕВ

„30“ апреля 1977 г.

*1977 елда Нәби Дәүлигә «Бухенвальд-Дора үлем лагеренда фашистларга каршы хәрәкәттә катнашучы» медале бирелү турында Указ чыга. Язучы үзе бу турыда белми кала. Медаль 1990 елда гына – язучының вафатыннан соң ярты ел узгач – аның туганнарына килеп ирешә.*



*Бөек Ватан сугышында катнашкан язучыларыбыздан бер төркем. Беренче рәт: сулдан-уңга — Әдип Маликов, Мөнир Мазунов, Сибгат Хәким, Зәйни Шаһиморатов, Мәхмүт Хөсәен, Шәрәф Мөдәррис; икенче рәт — Халикъ Садри, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Афзал Шамов, Риза Ишморат, Госман Бакир; өченче рәт — Габдрахман Әпсәләмов, Гамир Насрый, Әсгать Айдар, Абдулла Әхмәт, Вадим Земной, Хатыйп Госман; дүртенче рәт – Әмирхан Еники, Әхмәт Исхак, Әхмәт Фәйзи, Хәсән Шабанов. 23 апрель, 1947 ел.*

ЛИТЕРАТУРНАЯ ГАЗЕТА

Автономная некоммерческая организация «Редакция «Литературной газеты»
121069, г. Москва, ул. Большая Никитская дом 50А/5 стр 1, www.lgz.ru, e-mail: litgazeta@lgz.ru, т. 8 (499) 788-00-56

Старейшее российское культурологическое издание – «Литературная газета» сердечно поздравляет коллектив журнала «Казан утлары», старейший литературный журнал России, со 100-летним юбилеем.

Это знаменательное событие заставляет задуматься о том, как много у нас общего. В первую очередь — понимание важности художественного перевода. Как журнал «Казан утлары» со дня своего основания помимо произведений татарских писателей предоставлял свои страницы для переводов произведений народов Евразии на татарский язык, так и «Литературная газета» на постоянной основе уделяет внимание национальным литературам, в рамках проекта «Многоязыкая лира России». Историю татарской литературы, публицистики и литературной критики без журнала «Казан утлары» так же трудно представить, как историю русской литературы и журналистики без «Литературной газеты», которой в 2020 году исполнилось 190-лет со дня основания. Наконец, нас объединяет универсальность подхода: не ограничиваясь прозой и поэзией, мы много внимания уделяем вопросам театрального, изобразительного и музыкального искусства, проблемам истории и современности.

Желаю дружному коллективу журнала «Казан утлары» не останавливаться на достигнутом, добиваться дальнейших творческих успехов, расширять круг новых интересных тем и талантливых авторов, совместных проектов с «Литературной газетой» и другими общероссийскими литературными изданиями.

С уважением,
**Главный редактор,**
**член Совета при Президенте РФ**
**по развитию гражданского общества**
**и правам человека** **М.А. Замшев**



**Мөнир КУНАФИН,**
Башкортстан Республикасы «Агыйдел» әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журналының баш мөхәррире

*Хөрмәтле «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре, кадерле коллегалар!*

*Бер-беребезгә эшләгән яхшылыкларыбызны, изге гамәлләребезне уеп язарлык татар халкының хәтер ташы – «Казан утлары», башкорт халкының хәтер ташы – «Агыйдел» журналларыбыз бар. «Ташка уеп язылган югалмый», ди башкорт мәкале. Үткән йөз еллык дәверебездәге кебек килер заманнарда да изгелекнең, игелекнең бөек кануннарына тугры калсак, тарих ташларыбыз да, журналларыбыз да, әдәбиятыбыз да, милләтләребез дә яшәр! Иншаллаһ!*

*Гасырлык юбилееӊ котлы булсын, «Казан утлары!»*

*Казан утлары әллә кайдан яктырып, Идел, ягъни Олы Идел төбәген балкытып, үзенә тартып утырган кебек, шул ук исемне йөрткән журнал да ялкынлы нуры белән барча татар халкының рухи гөмбәзен ай саен бер карышка киңәйтә-биегәйтә барган тылсымлы бер кодрәт ул!*

*Әдәбиятсыз кавем – кабилә генә; әдипләре, чәчәннәре булганы – халык булып оешканы! Нур утларыңа татар дөньясы таянып әйләнер күчәрдәй көч булып яшә дә яшә әле, «Казан утлары»!*

*Балкысын «Казан утлары»!*
*«Агыйдел» аксын шаулап!*
*Милләт өчен, ил, тел өчен*
*Яшик үрләр яулап.*



**Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ,**
Башкортстан Республикасы «Шоңкар» яшьләр журналының баш мөхәррире, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Ш.Бабич исемендәге Дәүләт яшьләр премиясе лауреаты

*Хөрмәтле дуслар, кадерле коллегалар!*

*Сезне «Казан утлары» журналының 100 еллык юбилее белән ихлас котлыйбыз.*

*«Казан утлары» журналы – татар халкының рухи кыйбласы, үз милләтенең рухият елъязмасы. Ул балкыткан яңа исемнәр әдәбиятта үз урынын табып, милли интеллигенция сафын тулыландырды.*

*Үткән гасырның катлаулы чорында барлыкка килгән басма үзенең тирән эчтәлекле булуы, ихласлыгы, җылылыгы белән күңелләрне яктырта. Мавыктыргыч әсәрләр, бәхәс тудырган чыгышлар, ихлас әңгәмәләр журнал битләрен укылышлы итә, халык күңелендә илсөярлек тойгысы уята, телне сөяргә чакыра. Журналның таләпләре һәрчак югары! Анда басылган әсәрләр яхшылыкка, матурлыкка, изгелеккә өндәп, әдәбиятның төп максатына тугры кала. Нәкъ шуңа да «Казан утлары» татар халкының гына түгел, башкортларның да яраткан журналына әверелде. Күп кенә башкорт язучылары нәкъ шушы басма аша татар дөньясына танылды. Бүгенге заманда ике кардәш халыкның киләчәккә бәйле уй-ниятләре дә, борчылулары да, теләк-омтылышлары да уртак. Әдәбиятыбыз яшәгәндә, туган телдә газета-журналларыбыз чыгып торганда туар көнебез ышанычлы.*

*«Казан утлары» коллективы шушы изге максатларны яхшы аңлап, армый-талмый халык мәнфәгатенә хезмәт итә. Шуңа да журналның төрки дөньяда абруе югары. Бүген «Казан утлары»ның Россиядә иң зур тиражлы әдәби басма булуы да күп нәрсә хакында сөйли.*

*Тугандаш татар халкының шатлыклы вакыйгасын уртаклашып, иң изге теләкләребезне юллыйбыз!*

*Бәйрәмегез мөбарәк булсын! Мәңге балкысын «Казан утлары»!*

# Фәнис Яруллин

## Күмелеп калмасын

Улым да юк минем, кызым да юк,
Җимешсез шул нәсел агачым.
Белеп торам, нәсел агачымның
Озакламый җиргә авасын.

Тик мин җирдән мәңге киткән чакта,
Теләп эчтән соңгы теләкне,
Дусларымның хәтер учагына
Күмеп калдырырмын йөрәкне.

Кирәк кеше аннан ут алыр да
Үз учагын куяр тергезеп.
Йөрермен мин җаннан җанга күчеп,
Йөрермен гел шулай җир гизеп.

Шушы булыр минем улым-кызым,
Шушы булыр минем дәвамым.
Дусларымның хәтерен көл басмаса,
Гел янармын, күмелеп калмамын.

*«Казан утлары». 1987 ел, 5нче сан.*

# Равил Фәйзуллин

***

Космополит түгел. Шөкер. Минем
халкым да бар, ил дә, Ватан да.
Мин тынычмын: «татарныкы» диеп
төртеп күрсәтмимен ал таңга.

Минеке дип белмим күкне, айны,
мөһер сукмыйм ел фасылына.
Милләт исемен такмыйм урман-суга,
агач ташның иң асылына.

Һәммә гашыйк, һәммә халык өчен
бар Табигать – уртак Матурлык.
Барыбызга да газиз Матурлыкны
бирәүнең дә үзенеке ясар хакы юк!

Кояшка һәм Күккә бар да тигез.
Без табигать балалары ла!
Без һәммәбез тигез. Кая? Кемнәр
ак сөякле, зәңгәр канлылар?

Соң безнекеләр Ил туфрак өчен
яуларда баш салмадылармы?
Уртак Ватан өчен Парижларны,
Берлиннарны алмадылармы?

Шуңа күрә горур, тынычмын мин.
Халкым да бар, ил дә, Ватан да!
Уртак могҗиза дип карыйм мин кояшка,
барыбызныкы дип карыйм ал таңга!

Миңа җитә – халкым, Ватаным бар.
Матурга да бик нечкә күңел.
Кем кылана, димәк – җитми. Ә без?
Без болай да бәләкәй түгел!

*«Казан утлары». 1971 ел, 1нче сан.*

## Ренат Харис

### Өянке

Өскә үсмәсен әле дип,
Баш ботагымны киссәң –
Мин бит як-якка үсәм.

Киңлеккә китмәсен диеп,
Ян-якларымны киссәң –
Мин куелыкка үсәм.

Куелыкка үсмәсен дип,
Ябалдашымны киссәң –
Мин тамыр якка үсәм.

Бәгыренә чабыймчы дип,
Казып тамырыма төшсәң –
Кабереӊ өстендә үсәм!

*«Казан утлары». 1971 ел, 1нче сан.*

## Рәдиф Гаташ

### Җилкән

Җилкәннәрне ефәк җил күтәрде,
Тын ярларны инде калдырам...
Авыр миңа, гүя гомерлеккә
Ай, кояштан бүген аерылам.
Тиргәмәгез мине, сөйгән дуслар.
Тиргәмәгез – ерак киткәнгә.
Сезгә, бәлки, утрау күбрәк ошый,
Диңгез кирәк ләкин – җилкәнгә.

Җилкәннәрне тагын җил күтәрде.
Җилгә – җиңел... ә соң күңелгә?!
Бик еракта инде тын яр булып,
Малай чагым минем күмелә.
Диңгезләргә илтә тагын юлым,
Мин күрмәгән ерак җирләргә.
Ярдан һаман ерагайган саен
Җиңелрәк икән җилкәнгә!

*«Казан утлары». 1961 ел, 1нче сан.*

## Рәшит Әхмәтҗан

### Бәйрәм

Без мәңгегә, без мәңгегә монда!
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
Кыңгыраулар таккан атлары.
Чәчте-урды халкым, горур булды,
Үз язмышын ятка бирмәде.
Кешеләрнең бүген туган җирдән
Үлемсезлек алган көннәре.

Алар күргән авыр кайгыларны
Онытырмын димә тиз генә.
...Килгән дошман халкым сөягеннән
Һәйкәл куяр өчен үзенә.
Мин туганмын җиргә шул елларда,
Озак яшәремне ил белгән.
Мин туганмын, илем дошманнары
Нәкъ мин туган җиргә күмелгән.

Гомер биргәнсең син,
Йөрәк янган: сүнми, югалмый.
Туган җирдә дошман каберләре...
Каберләрдән ирләр үч алмый.
Шундыйларны, шундый кешеләрне
Дошман яуда җиңәламыни!

Шундый кешеләрнең нәфрәтләре –
Аны ерак җибәрәмени!
Без мәңгегә, без мәңгегә монда!
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
Кыңгыраулар таккан атлары.

*«Казан утлары». 1968 ел, 10нчы сан.*

# Гәрәй Рәхим

***

Күзләреңне кара димәдем,
Битләреңне алма димәдем,
Иреннәрең чия димәдем –
Мин, ахрысы, бер дә кешегә
Охшаш итеп сөя белмәдем.
Мин башкача сөйдем, ахрысы,
Үзем генә сөя белгәнчә.
Җирдә әле башка беркем дә

Сөя белмәгәнчә – бүтәнчә.
Мин үкенмим ләкин хәзер дә,
Сөю кануннарын эзләмим.
Мин сөям ич сине үземчә –
Күзләреңне кара димичә,
Битләреңне алма димичә,
Иреннәрең чия димичә
Сөям сине нәкъ син көенчә.

*«Казан утлары». 1970 ел, 1нче сан.*

# Салисә Гәрәева

***

Син еракта. Белмим кайдалыгың,
Эзләреңә басып йөрелмәс.
Күңелләрдә сагыну яшәсә дә,
Чәчләребез чәчкә үрелмәс.

Үкенү дә түгел, кайгыру да...
Син яшьлектә калган язларым,
Мин хәтерлим сине. Син дә шулай
Уйлыйсыңдыр җирдә мин барын.

*«Казан утлары». 1967 ел, 3нче сан.*

# Рөстәм Мингалим

## Әрсезләр

Никтер әле җирдә әрсезләргә
җиңелрәк ачыла ишекләр.

Әрсезләрне күзләр күбрәк күрә,
колаклар да тизрәк ишетә.

Җыелышларда күккә әрсезләрнең
исемнәре ешрак чөелә.
Начальниклар – яңа эшкә кергән
әрсез замын күреп сөенә.
Егетләрне әле кай җирдә дә
әрсез кызлар тизрәк карата.
Яшь кызлар да, никтер, тол хатын да
әрсез егетләрне ярата.

Хәтта аталар да, аналар да
кызларына егет димлиләр.
Имеш: «Әрсез егет дөнья көтәр,
үзе ярты бәхет ул!» – диләр.
Яратыгыз, кешеләр, димләгез дә –
каршы килү түгел теләгем.
Әмма була микән әрсез бәхет!
Әрсез кайгы барын беләмен.

*«Казан утлары». 1967 ел, 7нче сан.*

## Айдар Хәлим

### Дусларга

Хәл сорашып, хат язып тормагыз.
Хәлне күзгә карап белешербез.
Диктатура кайта. Озакламый
«Кирәк урыннар»да күрешербез.

Түздек. Түзәчәкбез. Кемнәр, кайчан
Сөйли алыр безнең түзгәннәрне?
Әмма түзә-түзә булмадыкмы
Бу яктыдан якты карбаздагы
Бәрәңгенең сукыр күзәнәге?

*«Казан утлары». 1995 ел, 12нче сан.*

## Әхмәт Рәшит

### Россия

Россия, мин – синең татар улың,
Мин – яраң да синең, дәваң да,
Яңа буыннарның башы да мин,
Үткән буыннарга дәвам да.

Урап кайтсам кайчак узганнарга,
Бу – кер эзләү түгел тарихтан;
Бары күңел бабайларның хәлен
Белер өчен шулай зарыккан.

Эзләмим мин аннан канлы эзләр,
Кынысыннан чыккан кылычны.
Бүгенгегә карыйм: Уртак Ватан –
Советларның күге тынычмы?!

Дөнья булгач, бар да булган инде –
Төйнәлгәндер байтак төеннәр,
Араларда кара мәче йөргән –
Дошман көлгән, дошман сөенгән.

Дошман сөйли кояш баткан якка
Карап безнең кылыч айкауны.
Ә мин телгә алам ике дусны –
Рус Пугачёв, татар Канкайны.

Ә мин Пушкиннарны сагынып яшим.
Ирек җәлладлары кулыннан
Пуляларны үзем алып, Аны
Аралыйсым килә үлемнән.

Ә мин таңнар саен курганнарда
Ил иреге өчен баш салган
Солдатларны санап өзгәләнәм:
Кайсы, кайчан?.. Кайсы яклардан?..

Безгә инде башка иман инде,
Безнең кыйбла – дуслык кояшы,
Коммунизм – безнең уртак язмыш,
Ленин – безгә уртак юлбашчы.

Алкынланып Идел аккан илдә
Төзибез без якты, яңаны.
Россия, мин – синең тугры улың –
Буыннарның яңа дәвамы.

*«Казан утлары». 1972 ел, 5нче сан.*

# Флёра Гыйззәтуллина

***

Сайлаган юлымнан барыбер ваз кичмәм,
атлавы җиңелме, авырмы?
Ник кирәк күкрәвем, ник кирәк явымым
бастыра алмасам давылны?!
Ник кирәк сөюем? Сөюдән көч алып,
иң ачы нәфрәтне җиңмәсәм.
Сөюем хакына җиде кат җан биреп,
җиде кат терелә белмәсәм.
Ник кирәк яшәвем, әгәр дә нибары
яшәсәм тәнемдә җан барга.
Юк, язмыш, шаярма! Мин инде өйрәндем
җиңәргә, сөяргә, янарга!

*«Казан утлары». 1971 ел, 10нчы сан.*

# Фаил Шәфигуллин

## Бер уч печән

Юлдан олау узды. Шул олаудан
Бер уч печән алып иснәдем.
Исерттеме әллә бер уч печән?
Нишләдем мин, тукта, нишләдем?

Ак чәчәктән балкып тагын килдең,
Ак алъяпкыч сиңа килешә,
Болын гүя дәртле Сабан туе –
Тальян чыңлый, кызлар көлешә.

Печән төсле яшькелт күзләреңдә
Әйтеп булмый торган матурлык.
Шул көнне без иң беренче тапкыр
Иңне иңгә куеп утырдык.

Тәүге канат, ах, шул канатларда
Баскан җирне тоймый йөрүләр...
Кулларыңнан алып сөяргә дә
Ник кыймадым икән, мин юләр?!

Юлдан олау узды. Шул олаудан
Бер уч печән алып иснәдем.
Менә хәзер, әле яңа гына
Бөреләнде гүя хисләрем.

*«Казан утлары». 1965 ел, 10нчы сан.*

# Кадыйр Сибгатуллин

## Картлар

Җиңел чагы туры килмәгәнгә,
онытылмаган әле авыр чаклар.
Зарланмыйча гына дәшми йөри,
хәтер бетте диеп, тыйнак картлар.

Үз гомере белән үлчәп карый,
сынап карый: болар нинди затлар?
Нәрсә бөркәнсәк тә, безне таный,
заманны таный сизгер картлар.

Төскә түгел, алар төпкә карый.
Нигә сүзләр, нигә ялган антлар?!
Эшебезне, үзебезне аңлый
үзебездән элек зирәк картлар.

Үзләренә әле без түлисе
онытылмый торган олы хак бар.
Үзләреннән туган изгелеккә
рәхмәт укып йөри сабый картлар.

Кер булганга түгел, сер булганга
гүргә кадәр бәлки әйтми саклар.
Оланнарга зыян килмәсен дип,
кирәк булса әгәр – сабыр картлар.

Карап кына, санап, барлап кына
бу тормышның гел алдыннан атлар.
Әйтерсең лә әле яшәмәгән,
бер дә картаймаган даһи картлар.

*«Казан утлары». 1978 ел, 10нчы сан.*

# Зиннур Насыйбуллин

## Кара шәле килә сөйрәлеп

Шомлы еллар иде. Январь җиле
Өйне-тышны йөри бер итеп.
Сыңар күзем белән тышка карыйм,
Тәрәз бозын өреп эретеп.
Ыңгырашкан кебек шыгырдатып,
Хат ташучы ачты капканы,
Шомландырып, керер-кермәс торды
Һәм борылып кире атлады.
Нигә китте? Нигә хат-хәбәрдән
Мәхрүм калды безнең өй генә?
Анам күңеле нидер сизде бугай,
Кара шәлен салып иңенә,
Ул урамга чыкты. Өерелеп
Кышкы салкын керде ишектән.
(Салкын гынамыни ул елларда
кешеләрнең җанын өшеткән?)
Тиз урады әнкәй, ләкин өйне
Узып китте. Никтер кермәде.
Яланаяк каршы чыкканымны
Әллә күрде, әллә күрмәде.
Каерылган кош канаты кебек
Кара шәле кардан сөйрәлә.
– Әни, әни. Нәрсә булды, әни?
Сөйлә, әни. Хәер... сөйләмә.
Шатлыкларга күнегелә бугай,
Тик кайгыга булмый өйрәнеп.
Ничәмә ел...
Ничәмә ел инде әниемнең
Кара шәле килә сөйрәлеп.

*«Казан утлары». 1969 ел, 7нче сан.*

Мөхәммәт
Мәһдиев

# БӘХИЛЛӘШҮ

ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК*

Ипи салу...

Нигә нәкъ менә «ипи салу» дигән сүз, ул каян килгән? Тел белгечләре аңлатып бирсәләр иде. Зур сүз бит. Сугыш вакытында яки аңарчы, аннан соңгы авыр елларда халык телендә шундый зур хәбәр йөри иде:

– Хәбирнекеләр ипи салып яши...

Бу хәбәрнең көчен, куәтен бүгенге нинди төшенчә белән чагыштырып була икән? Чама белән менә мондыйдыр:

– Хәбирнекеләр кече малайларына да «Волга» алганнар. Әле кичә генә киленнәре Мәскәүдән япон телевизоры алып кайткан иде. Утыз сигез меңлек...

Ипи салу. Дөньяда иң игелекле, мәгънәле иҗади бер эш ул. Ипи салу хатын-кызның бер тәүлеккә сузылган эше. Бу тәүлектә йортта – зур, тыныч шатлык, тынлык, тантана. Ипи салган тәүлектә ир белән хатын арасында ызгыш-талаш булмый. Ыбыр-чыбырлы бала-чага да бу тәүлектә тынып тора. Беләләр: әни ипи сала. Татар халкында әни белән ипи сүзе бергә йөри. Аларның мәгънә төсмерләре бертигез. Халык үзенең телен ясаганда ук, иң газиз әйберләргә ике яки өч кенә аваз сарыф итеп сүз ясаган. Ике яки өч авазлы сүзләр – халкыбызның иң беренче, димәк, иң кадерле сүзләре: әни, әти, әби, апа, ил, ипи, сөт, май, су, ай, чәч, ут, өн, уй, аш, көн, төн, күз, кыш, яз, җәй, баш, кан, кул, күз, он, аш, бал, аяк, җыр, җир...

Ипи салу, Ул – ничек? Аңа ниләр кирәк? Кирәк әйбер күп түгел. Иң беренче – эш ярата торган, бай күңелле хатын кирәк. Аннан кала каен утыныннан тиешле эсселек тудыра алырдай уңышлы, игелекле мич кирәк. Әлбәттә, коры утын кирәк. Кара чыршы, каен, имән утыны. Калганнары – зирек, юкә, ак чыршы, нарат ярамый. Ләкин аларның да үз урыны бар: әйтик, коймак, кабартма пешергәндә, сөян (Казан артында: «сөям») кирәк. Тагын ниләр? Күәс чиләге. Ипи бары тик юкә агачыннан эшләнгән күәс чиләгендә генә чын ипи була! Кызганыч, әлегә безнең тел гыйлемендә сүзләрнең килеп чыгышын күрсәткән махсус сүзлек юк. Әйтик, «күәс» сүзе каян килеп чыккан? «Күәс» дигән сүз нинди тамырдан ясалган? «Квас» белән берме ул? Татарга рустан кергәнме, әллә киресенчәме? «Ачыту» дигән сүзме ул? Һәм ни өчен «ачыту чиләге» түгел, ә «күәс чиләге»? «Чиләк» дигәне каян, ничек килеп чыккан? Килер

* М.Мәһдиевнең «Бәхилләшү» повесте журналда 1989 елның 1, 2 нче саннарында басылып чыга.

бер заман, бездә дә гаҗәп-гаҗәп сүзләрнең килеп чыгышын аңлаткан китап-сүзлекләр туар әле.

Күәс чиләгенең төбен кырып бетермичә, анда ачы камыр калдырасың. Күәс чиләге, мәһабәт булып, атна буе мич башында утыра. Ә инде көннәрдән бер көнне өйдә тантаналы сүз әйтелә: бүген ипи изәсе бар. Хуҗа хатын шул мизгелдән соң патша хатынына әйләнә. Бетте, дөнья ваклыклары юкка чыкты, чөнки – бүген ипи изәргә кирәк. Ир кеше йөзенә бик горур кыяфәт биреп (әйтерсең, халыкара мәсьәләне хәл итәр өчен Женевага чыгып китә), келәткә таба юл ала, бераздан, дәшмичә генә, чиләк белән он алып керә, аны җилпучка сала, тау итеп, матур итеп сала (Жилпуч? Бу сүз каян? Булачак тел галимнәренә эш иллә дә күп әле бездә). Хатын күәс чиләгенең төбенә җылы су сала, ипи калагы дигән хикмәтле агач калак белән күәс төбендә электән калган ачы камырны туглап җанландыра. Бу – «баш» дип атала. Баш күперә тора, бераздан мич башындагы җилпучта он да җылына, хуҗа хатын он иләргә әзерләнә. Ләкин моны ул төнлә, ялгыз калып эшли. Хатын моңа тотынганчы йорт хуҗасы ир абзар-кураны бер әйләнеп керергә тиеш; бала-чага, сәкедә байтак сугышып алгач, арып-изрәп йокыга тәгәрәргә тиеш. Хуҗа хатын шул вакытта хуш исле арыш оны белән күзгә-күз ялгыз кала һәм шунда шигърият башлана. Бу шигърият он иләү дип атала. Иләк берничә төрле. Юкә иләк – ондагы чүп-чарны гына тотып кала, кайвакытта шуннан иләп тә ипи пешерәләр: шәп! Хуш ис! Җиз иләк чәч юанлыгында гына җиз чыбыктан эшләнгән саргылт-алтын челтәрле иләк. Моннан уздырылган он гел кершән генә була иде. Кыл иләк. Йа Хода! Монысы инде онның ялтысын гына аска төшерә. Безнең халыкта, вакчылрак берәү турында сүз барса, «Кыл иләктән уздыра инде», дип сөйлиләр. Фәлән хатын турында матур сүз әйтергә кирәк булса, безнең Казан артында менә болай диләр:

– Җиз иләктән ипи пешергән...

– Кыл иләктән генә иләп, коймак пешергән. Теленңне йотарлык.

Әлеге «баш» турында сөйлибез бит әле. Он җылынгач, иләнгәч, кайнаган җылымса су салып, күәс чиләгендә ипи изелә. Бер күәс чиләгеннән алты-җиде ипи чыгарга тиеш. Тук-тук-тук... Хатын төн уртасына хәтле шулай ипи изә. Йортка әчкелтем камыр исе чыга, бу ис канны сафландыра, бу искә чыдап булмый. Хатын-әнидән башка бөтен кеше шул искә изрәп йоклый. Йокламаска мөмкин дә түгел: тук-тук-тук. Шулай төн җитә. Иртәнге якта йокыдан уянып, хатын да, ир дә рәхәтләнеп тыңлап ята: мич башына куелган күәс чиләгендәге камыр сулыш ала, яши, күперә:

– Пышт, пышт...

Хатын йокысыз ята, тора, юына, бисмилласын әйтеп, күәс чиләге янына килә. Анда Тормышның үзе! Камыр сөйләшә, күтәрелә, җаныкаем, хуш ис тарата. Ул арада ир дә киерелә-киерелә, йокысыннан тора. Җылы су белән әйбәтләп юына (юынмаган көе ипи, он, камыр янына килергә ярамый), мыйкылдап утырган күәс чиләген кочаклап, күкрәгенә ала да, сәкегә китереп куя: ипи басасы бар. Шуның белән ирнең вазифасы әлегә тәмам. Хатын исә, чәчләрен төреп, яулык астына яшерә, җылы су, сабын белән беләкләрен юа, озаклап юа, озаклап сөртенә һәм... күпереп утырган күәскә беләген тыга. Шулай «ипи басу» башлана.

Камыр сөйләшә, хуҗа хатын белән фикер алыша: кул хәрәкәтенә җавап биреп «кошт-кошт» дип ала. Йортка эчкелтем хуш ис чыга. Хатын ипи басканда, ире бер кочак коры утын алып керә, чыра телә, булыша. Иртәнге чәйне әзерләп, бала-чаганы мәктәпкә озаткан арада «баскан» камыр күтәрелеп өлгерә. Хатын инде мич томалап йөри, сәгатькә караштырып ала, күәс чиләгендәге камыр да бит тик ятмый, холык күрсәтә – өскә таба күтәрелә, ташып чыкмакчы була. Һәм хатын ашыга башлый зур театрның режиссёры премьера алдыннан шулай дулкынланадыр дип уйлыйм мин (сәхнә артын минем бер тапкыр да күргәнем юк, чама белән генә сөйлим). Мич томалана, кисәү агачы дигән хикмәтле корал белән күмер тартыла, мич пумаласы хәрәкәткә килә, аңа су бөркисең дә, кайнар мичнең төбеннән кайнар көлне әвәләп, пумала мунчаласына аласың. Мич төбе әзер. Кайнар, чиста. Шул вакытта «режиссёр пәрдәне ача». Әлеге хатын юылган чиста куллары белән күәс чиләгеннән учлап-учлап камыр ала да «әпе-төпе» китереп, ачы камырдан ипи ясый. Бу – «ипи әвәләү» дип атала. Безнең өйдә исә бу хәл башкачарак иде. Әти Арча базарыннан җиде бадьян алып кайткан. Шулай итеп безнең өйдә кырып ясалган җиде бадьян – ипи савыты бар. Әни ачы камырны шуларга сала да күпереп маташканда гына әйләндереп, ипи көрәгенә куя һәм мич төбенә озата. Гадәттә, җиде ипи. Соңгысы – агач саплы тимер кыргыч белән күәс чиләген кырып җыелган камырдан пешкән кечкенә ипи. Монысы – иң тәмлесе. Монысы төпчек, иркә бала. «Күәс төбе» дип атала ул.

Бер истәлек. 1936 ел. Яз. Авылда кызамык. Көн саен хәбәр: Мәликә үлгән, Рокыя үлгән, Динислам, Әхмәдулла, Фәсәхәт. Кызамык безнең өйне дә бәреп салды: бөтенебез кызамыктан егылдык. Ул вакытта «температура» дигән сүз юк. «Фәлән градус» дип әйтелми, әни кеше яки әти кеше яныңа килә дә кытыршы уч төбен маңгаеңа куя: «Башы эссе», – ди.

«Башы эссе». Бу инде – авылда иң бөек диагноз. Утыз алтынчы елда, кызамык чорында «башы эссе» балаларның бик күбесе дөньядан китеп барды. Истәлек шул – барыбыз да идәндә, сәкедә тәгәрәп ятабыз. Барыбызның да башы эссе. Берөзлексез чәй эчәсе килә. Самавыр чәе. Ләкин андый мөмкинлек юк. Самавырны кичә генә алып чыгып киттеләр. Ул елларда шундый сүз бар иде. Ягъни вакытында түләнмәгән налог өчен авыл җитәкчеләре фәлән әйберне алып чыгып китәләр дә, шуны «торги»га куеп саталар һәм синең налогыңа акча керә. Җыры да бар иде:

Торги була, торги була,
Торги була яшьләргә.
Торгидан калган яшьләргә –
Мәҗбүри эш эшләргә.

Мәҗбүри эш шулай ук хәтәр сүз иде, налогын вакытында түли алмаган кешеләрне әнә шул «мәҗбүри эш» эшләргә ерак җирләргә озаталар иде.

Шулай чәй эчәсе килә. Әни йөгереп йөри. Аш пешерә торган казанда чәй кайната. Безгә эчерә. Чәйдән бәрәңге, казан, тимер тәме килә. Аны эчкәч, косасыны китерә. Ләкин без бәхетле әле, әни ипи салган. Иртән без эссе баш белән уянганда, өйгә ипи исе чыккан булуы зур бәхет. Әйе, истәлек шул: дүрт яшьлек сеңлем Гөлчәчәк үләренә бер сәгать калганда, әнидән әнә шуны – күәс төбе ипиен сорады.

– Ән-ни, теге кечкенә ипине бир, – диде. Әни морҗадагы шүрлек сыман чыгынтыдан кечкенә күәс ипиен алып, аңа тоттырды. Шуны кырыеннан тешләгәч, сеңлем үлде. Мин бала әле. «Үлде» дигәнне аңламыйм, ләкин карчыклар җыелып, аның мәетен юганда күрдем: авызында күәс төбе ипиенең йотылмаган кисәге бар иде. Аны бармак тыгып алдылар.

Күңелсез якка кереп киттем әле. Ләкин нишлисең?

Әйдәгез, авырулары булмаган сәламәт өйгә, монда ипи салган көнне керик әле. Хуҗа хатын, әпе-төпе китереп, ипи әвәли. Мичтә соңгы утын чартлый-чартлый яна. Хуҗа хатын ашыга: мәсьәләне минутлар хәл итә: аз гына хата җибәрдеңме, бөтен күрше-тирәгә (ә авылча «күршелек» кырык йортка кадәр) таралачак:

– Миңлекамалның ипие катлаулы булган...

– Гайнижамалның ипиен суык тешләгән...

Беренчесе: ипине мичтән алып суынырга куйганда, хәлиткеч мизгел ычкындырылган, ипинең кетердәвекле кызгылт тышчасы йомшагыннан аерылган. Бу хәл булмасын өчен ипине мичтән алып, ашъяулык җәелгән өстәлгә тезгәндә, хуҗа хатын очлы пычак белән ипи өстенә төрткәләп ала, пошт-пошт итеп кайнар парны чыгара.

Тукта, мин юлдан адашканмын икән бит, күр әле.

Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит «Шүрәле».

Әйе, минем максат башка иде. «Таба ипие» дигән хикмәтле бер ризык турында сөйләү иде. Моны мич тартыр алдыннан, күмер төшкәч пешерәләр. Хуҗа хатын бу вакытта зур бер оркестрның дирижёрына әйләнә. Сөйләшү-эндәшү юк. Мичтә йодрык кадәр алтынсу күмерләр ялкын бәрә. Мичне тартыр алдыннан гына күәс чиләге дә инде ташырга әзерләнә (димәк, камыр уңган!), аны учлап алып «әпәләп» ясарга, бадьянга урнаштырырга кирәк, ләкин шул арада әле таба ипие пешереп аласы бар. Монысы – балалар өчен. Балалар болай да инде мич тирәсендә әшер-өшер киләләр, кул астына керәләр, әни кеше әнә шул кызу, аяк арасына кыл сыймаган бер вакытта матавыклап йөргән балаларына инде чын күңелдән, ләкин йомшак кына итеп биргәләп тә ала:

– Һай, дуңгызлар, чисти үзәгемә үттегез бит.

– Һай, юньсезләр, китегез аяк астыннан, дим.

Әмма «дуңгызлар, юньсезләр» китми. Дөресрәге – алар китә алмый. Чөнки әни кеше таба майлап ята. Бу инде бик тә матур күренеш, таба теге алтынсыман эре күмер өстенә куела, чыжлый башлый. Әнә шул минутта аңа ачы камыр – ипи камыры саласы. Теге «юньсезләр» шуны көтә. Йомшак итеп артларына төшереп алу түгел, ник шунда кисәү таягы белән бәргәләмисең – болар инде әнә шул затлы ризыкны эләктермичә, мич буеннан китмәячәкләр. Ул арада таба ипие күпереп пешә дә башлый, йортка ачы камыр ипие, май исе чыга. Башлар әйләнеп китә... Әни кешенең дә бите пәрәмәч кебек кызарган, күзләр нурланган. Ничә генә минут үтәдер – теге «дуңгызлар» өчен бөтен бер гомер инде ул – әни кеше табаны күмер өстеннән табагач белән тартып та ала. Пешкән таба ипиенә пычак очы белән төрткәләп, парын җибәрә, бармакларына өргәләп, теге хикмәтле ипине дүрткә аерып, балаларга тоттырып та куя. Шуның белән мич янындагы ыгы-зыгы тәмам. Хуҗа хатын анда ялгыз кала. Мичкә ипи

тыгу дигән бөек бер эш башлана. Бу вакытта хуҗа хатынның янына килергә ярамый: ник шунда җиде буын бабасы кабердән торып кайтып төшми! Берләшкән Милләтләр Оешмасының утырышын шулай зур әһәмият белән ачалардыр кебек миңа. Алты-җиде ипи мич төбенә урнаштырылды, мич капкачы ябылды, мич томаланды, учакка тартылган күмернең куәте әрәм китмәсенгә казанга су салынды. Шулвакыт хуҗа хатын олы якка чыгып, стена сәгатенә күз ташлый:

– Унбер тулып чирек, – ди ул үз-үзенә. Бу хәтердә калсын өчен әйтелә, димәк. Ипине фәлән сәгать фәлән минуттан аласы. Йөзе көймәсен. Ипине мичтә нәкъ сәгать ярым тотасы. Хуҗа хатын, яулыгын артка чөеп, урамга хәл алырга чыга. Күрше-тирә белеп тора инде: бүген ул ипи салды. Чөнки кичә генә кич Хәернисага кереп, әҗәткә бер кыерчык ипи алып торган иде – авылда гел шулай: ике ипи салу арасында бер өзеклекне әҗәткә кереп ялгыйсы, бу– күршелекне беркетеп торучы гаять әһәмиятле бер хәл. Икенче төрлесе дә була: фәлән җиңги күәс чиләгендәге «баш»ны саклый алмаган. «Баш»ны суык тешләгән. Моны бөтен күрше белә. Кечкенә чүлмәк, савыт тотып, бер-береңә «баш» алырга керү гаять тә җаваплы дипломатик аралашу алымнарының берсе иде. Чөнки һәркемнең үз күәсе тәме, үз «баш»ы бар, боларны күрше-тирә исеннән, рәвешеннән сизә.

Ә... теге балалар бар бит әле. Таба ипие ашаучылар. Алар умырып бирелгән теге таба ипиен, һичшиксез, урамда ашыйлар, чөнки бөтен урам белеп тора: болар бүген ипи салдылар. Хуҗа хатын урамдагы балаларына бәхетле карап ала: эт тә тук, кош та тук. Бәхетләре ташыган балалар умырып кына бүленгән кайнар камырны бөтен тирә тереклеге белән бергә ашыйлар, бигрәк тә әтәчнең көне – көн: кеше чутыннан унбиш-егерме тавыкны сыйлый. Хуҗа хатын үз йортының морҗа башына карап ала, аннан арыш ипиенең хуш исе кайнар һава булып, урамга тарала. Ләкин хатын урамда озак юанмый, йөгереп кереп китә. Мич капкачын ачып, ипиләргә күз салырга кирәк: ипинең йөзе килгәнме? Көеп китәрлек булса, мич капкачын ачып, ипигә бераз хәл кертәсе. Шулай герле сәгать белән мич арасында йөреп тора хатын, ул арада күәс чиләген алдагы атнага әзерләргә кирәк. Әгәр бу ипи уңышлы – күзәнәкле, әчкелтем, тышкы яктан кетердәвекле булып чыкса, димәк, күәс төбендә аның «нәселен» калдырырга кирәк. Аннан, төш вакыты җиткәндә, самавыр куеп, кайнар ипине кыерчыкларга сындырып (беренче чәйгә ипине пычак белән кисәргә уңайсыз да, алай ямьсез дә чыга), бөтен гаиләңә бәйрәм ясап, чәй эчертергә. Ләкин бу әле бәйрәмнең башы гына. Бала-чага белеп тора: почмак яктагы чүлмәктә ике көн инде борчак бүртә, бүген кич, һичшиксез, борчак чумары булачак. Чөнки әни ачыган ипи камырын «чумар» өчен бераз алып калды. Әти кеше кичен аш өлгерер алдыннан гына кар базына төшеп, бер савыт катык алып менәчәк. Әчкелтем чумарлы борчак ашын ашаганда, авыл кешесенең физиологик канәгатьлеге шул дәрәҗәгә җитә ки, зур-зур отельләрдә, кафе-рестор采ннарда виски эчеп, сигара тартып утыручы бизнесменнар «без генә рәхәт чигәбез» дип, никадәр ялгышканнарын белмиләр дә. Ә кичке аш өлгергәнче әле вакыт бар. Ипиләр бераз суына төшкәч, хуҗа хатын аның иң матурын урталайга, дүрткә кисеп, кыерчык ясап, бер-ике күршесенә кичәге, бүгенге әҗәтен түләр. Әҗәт түләү – күршелек кануннарының,

үзара дипломатик мөнәсәбәтләрнең берсе – моны үтәгәндә, хатын-кыз иллә дә вәкаләтле. Мондый чакта ул дөньядагы иң җитди эш башкаручыга әйләнә. Әҗәт түләргә керер алдыннан бик чиста киндер тастымал алыныр, ипи аңа зур саклык белән төрелер, әле моны да хуҗа хатын чиста, матур алъяпкычының уң як итәген бераз күтәреп каплар һәм урам буйлап матур итеп атлап, әҗәт түләргә китәр. Бүген аның ипие уңган, бүген ул – шушы урамда патшабикә, ханша һәм тагын әллә кем. Һәм әҗәтне түләгәндә ул һич тә мактанмаячак.

– Менәтерәк, мич башым салкынрак булган. Изеп куюым булды, төнге унбер иде, күәс чиләгемне утыртуым булды, йөрәгем жууу итеп китте. Ай, минәйтәм, мич башында җылылык җитәрлек түгел бит. Ай, минәйтәм, камырым харап була бит. Менә шул: камырымны суык тешләгән...

Күршесе дә аны дөрес аңлый:

– И-и Миңкамал, алай димә син. Синең ипи әйбәт була, аны бөтен күрше белә. Әнә бит – Хәмденисаның бер дә уңмый. Аның өчен Хәмдениса иске чүпрәдән баш ясый. Чүпрәсенең куәте беткән. Аннан әнә Шәмсенисаны кара: ипие гел кайраклы (ягъни ипинең өске яки аскы катысы янында ике сантиметр чамасы калынлыкта күзәнәксез камыр була). Алай димә син.

Бәхетле, рухи яктан киң, тирән мизгелләр...

## *Безне котлыйлар*



**Юрий СЕМЕНДЕР,**
Чувашия Республикасының халык шагыйре.
1974 – 2005 елларда Чувашия Республикасының «Ялав» (Байрак) әдәби-иҗтимагый журналы баш мөхәррире

*Кадерле дуслар!*

*Барлык чуваш язучылары һәм әдәбият сөючеләре исеменнән «Казан утлары» журналы коллективын журналның 100 еллык юбилее белән кайнар котлыйбыз.*

*«Казан утлары», чыга башлаган көненнән бирле, чуваш әдәбиятына игътибарлы булды. Анда Шәләби һәм Эльгер, Хузангай һәм Ухсай, Алга һәм Калган, Талвир һәм Турхан, Уяр һәм Илбәк, Садай һәм Емельянов, Артемьев һәм Алендей, Юхма һәм Гордеев, Анатрий һәм Ефимов, Афанасьев һәм Тургай, Сарби һәм Азамат кебек башка бик күп чуваш әдипләренең әсәрләре басылды. Без журналның чуваш әдипләренә карата кардәшлек мөнәсәбәтләрен һәрчак тоеп яшәдек. Чуваш язучылары «Казан утлары» авторы булыр өчен һәрчак татар язучылары югарылыгындагы әсәрләр язарга омтылдылар һәм киләчәктә дә бу биеклекне югары тотарга дигән максат белән иҗат итәрбез дип ышандырабыз.*

*Зур рәхмәт, дуслар!*

Аяз
Гыйләҗев

# ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА![*]

РОМАН-ХАТИРӘДӘН ӨЗЕК

Вагоннарны бушатып бетереп, кара тирне сыпырып алырга да өлгермибез, безне кирпеч төяргә җибәрәләр. Ай-һай, авыр эш! Гофман мичләре алдына кирпечләрне шакмак-шакмак тау итеп өйгәннәр, шул өемнәрдән вагон платформаларга тимер тасмалар сузасың, алтмыш-җитмеш кирпеч төялгән тачкаларны җан көчең белән этә-этә, вагон тирәсенә китереп туктатасың. Һәр платформага дүрт мең яки артыграк кирпеч сыя. Нормасын хәтерләмим, мәгәр үткер кырлы, чын чынаяк кебек, зыңгылдап торган ап-ак кирпечләрне ташый-ташый кәҗә маең чыга, бияләйләр теткәләнеп бетә, бияләй тишекләреннән чыккан бармаклар суелып чиләнә, каный. Җәрәхәтләргә кат-кат утырган тузаннан чыдар әмәл юк. Төйисең, авыр тачка артыннан йөгерәсең, вагонга бер менәсең, бер төшәсең. Лобков бригадир буларак явыз түгел, мәгәр тик торганны сөйми торган шактый быткыч адәм иде. Норма һәр көн үтәлергә тиеш! Һәр көн! Җитмәсә, бер бригадир тирәсендә өч-дүрт кеше ялмана, алар эшкә төп-төгәл чыгалар, завод ихатасына кергәч, күздән югалалар, кайтыр алдыннан тагын пәйда булалар. Фёдор Лобков тирәсенә шактый сәер кешеләр тупланган, бригадирның тән сакчылары дип тә атап булмый аларны, аның көнкүрешен кайгырта вә җиңеләйтә торган адәмнәр дә түгел... Полковник Каршаков Василий Фёдорович. Төрмәдә дә таудай корсагы шиңмәгән, куе кунык белән капланган эре тешле, калын тавышлы, юк өчен дә шаркылдап җибәрә торган бу гамьсез-ваемсыз кеше белән Лобковның ни уртаклыгы бар? Ясмык-ясмык шадралар бизәгән битле, тар чебеш күкрәкле, зәгыйфь кәкре аяклы Иван Домрачёв. (Икенче фамилиясе Бочарников иде!) Карабас триосының күренекле җырчысы Володя Кондаков бу өергә каян килеп кергән тагын?.. Юньләп эшләмиләр, ашаганда, кашыкның дәве алар кулында, эштән буш чакларда Лобков ятагы янына елышалар да, кияүгә китә алмаган кызлар сыман, чышын-пышын өзлексез сөйләшәләр. Ишеттермиләр, каһәрләр!.. Димәк, ниндидер серләре бар. Димәк, катлаулы һәм чуалчык зона тормышының мин белә алмаган үз серләре, үз мөнәсәбәтләре бар. Өчесе тиң шактый өркәк, моңа кадәр шактый чуар зоналар аша үтеп, карак-угрыларның гадәт-йолаларын иярткән Володя белән Иван бандеровчылардан бик нык шүрлиләр иде. Артларында

[*] А.Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!» роман-хатирәсе беренче тапкыр «Казан утлары» журналында 1993 елның 10-12 нче саннарында басылып чыга.

пычрак эзләре бар идеме, белмим, анда-монда, украиннар белән урыслар әрепләшкән мизгелләрдә койрыкларын кысалар иде. Ә бандеровчылар үз көчләрен еш-еш күрсәтеп, зонадагы өстенлекләрен расларга яраттылар.

Менә секция ишеге киерелеп ачыла, аннан ун-унбиш егет җил-давыл булып бәреп керә, алар тамак төпләреннән гайрәтле аваз чыгарып: «Утыр! Кузгалма! Утырырга!» – дип боерык бирәләр. Кулларда пычак-хәнҗәрләр җем-җем итә, пычак чыгармаганнар кулларын итек кунычларында, билләрендә тоталар. Алары да кораллы! Секция шым булып сеңә, без тын тартырга да кыймыйча керүчеләрне күз чите белән күзәтәбез. Кемне эзәрлекли алар, максатлары ни, сорашырга куркыныч, ә төркем үзәгендә торган бандеровчылар арасында минем якыннарым юк иде.

Кемнәрдер бер-берсенә тартылалар, оешалар, шуннан тәм, юаныч табалар. Әллә бүтән серләр аларны берләштерәме?.. Диндарлар: «Субботниклар», «Иегово шаһитлары», моңарчы ишеткәнем дә булмаган тар мәзһәб вәкилләре туктаусыз эзләнәләр... Озын буйлы, тотлыгып сөйләшүче майор Тихомировны «Иегово шаһитлары» барлап, үзенә тартты. Әсир төшкән, немецта йөз мәртәбә кыйналган, үзебездә мең мәртәбә тукмалып, теле тотлыккан, җаны теткәләнгән арык бу кешене асылынган җиреннән бавын өзеп тартып төшергәннәр... Хәзер асылынмас, кайгы-хәсрәте дә кимрәк булыр: диндарлар арасында аның абруе зур!..

Зонада ниндидер хәрәкәтләр бара, ул тере, кыймылдый, кайгыра, бәргәләнә. Карабастан килгән Николай Лаврентьевич Новиков вафат. Тамагы ач булса да, кич буе җырлап утырган, җыры хырылдауга күчкән. Сүзен дә әйтә алмаган... Хәер, ни әйтәсе калды икән бичараның?.. Безгә күрше секциядә заводның тимер-томыр тирәсендә кайнашучылары яшәп ята. Бригадирлары Сидоров фамилияле аю, фил дисәң дә ярый, тап-таза гайрәтле урыс. Әмма чебенне дә рәнҗетми торган әүлия, үз бригадасына тап булган гарип-горабаны да чит итми, зарланмый, ничек та җаен табып, тамагын туйдырырга тырыша. Асыл ир! Тимер-томыр тирәсендә белмәгәне юк дип сөйлиләр. Зонаның күркәм кешеләре дә, эте-кошы да күзгә бәрелеп, аерылып тора башлады. Барак ишеген кергәч тә сул кул якта, иң читтә старостаның нәни генә секциясе. Безнең староста – Хөсәен Зәлиханов исемле балкар. Алтын тешле, ак чырайлы, тезләрен бөгеп, аяк башларын аерып ипләп кенә йөрүче бу адәмгә якын барырлык түгел, һавалы, тәкәббер, текә кеше. Барактагы эчке тәртип өчен ил җавап бирә, диләр. Якташы балкар Магомед Толгу кыяфәте белән дә, торыр-тотышы белән дә кара крестьян. Җир кешесе. Зәлиханов түгәрәгендә тагын ике сәер кеше бар, икесе дә кабардиннар. Хәмит исемлесе безне күптән инкубатор чебешләре итеп бертөрле киемнәргә урасалар да, һаман үз өс-башыннан йөри. Шулкадәр шома, елгыр егет Хәмит, заводка чыга, кыл да кыймылдатмый, гел механиклар тирәсендә урала. Хәмит дөньяның мөгезеннән эләктергән егет, заводта хәнҗәр ясый, кыра, үткенли, әле бандеровчыларга, әле урысның кәттә егетләренә шуларны сата, дигән сүзләр йөри. Дөрес булгандыр ул!.. Мал таба, яхшы ризыктан өзелми, бандеровчылар арасыннан яшьрәкләрне, симез-түгәрәкләрне сайлап, «куенына ала» дип тә сөйлиләр. Булыр, булыр... Староста чоланыннан соңгы кеше Алихан атлы кабардин иде. Калын, башмак иренле, карасу-тутлы йөзле бу кеше Магомед шикелле үк крестьян

иде булса кирәк. Әлеге зона буржуазиясенең ишеген ачып караганым булмады, нигәдер бу төркем вәкилләренә катнашып китәргә курыктым, алай да Магомед Толгуров миңа бик якынайды. Балкарча эндәшә, мин татарчалыйм, бер-беребезне җиңел аңлыйбыз. Хәер, зонада ятлар белән аңлашканда, телгә ничә сүз кыстырасың инде? Күпчелек тамак ягын кайгырта, сүз гел шул тирәдә әйләнә. Хөсәен Залихановның мине туктатып эндәшкәне, ары-бире хәл белешкәне юк иде шикелле. Барак старостасы зур кеше, надзирательләр дә аңа баш кагып, күрешеп китәләр, кичләрен секциядән җыр тавышлары яңгырый. Хәзер беләм, «придуроклар» кәеф-сафа коралар, чифир эчәләр һәм ач малайларны бозалар...

Зонада тормыш гел буталышлардан, чуалышлардан тора. Бер буталыш икенчесен тудыра. Җәзачылар да тынмый, арабыздан күренеклерәк шәхесләрне чүпләп-чүпләп алалар да этапка куалар. Кемдер китә, кемдер килә. Украинаның көнбатыш өлкәләрендә ир-ат калдымы икән? Львов, Тернополь, Ровно өлкәләреннән халык килә тора, сеңә тора. Александр Хуродзены Спасск төрмә-лазаретына алып киттеләр. Үләргә. Аның соңгы сәгате якынлашканын врачлар да, лагерь хуҗалары да белеп тора, һаман рәхим-шәфкать юк бичарага! Җан биргәндә, авызына су салучы да булмаячак! «Империя таралачак!» дип ымсындырган, дәртемне кузгаткан беренче кеше идең син, Хуродзе агай!..

Кемнәргә таянып, нинди уйларга чумып, шундый нәтиҗәгә килә алды икән ул? Әллә шул утлы фикердән чыгып, лагерьдагы беренче көннәремдә мин юлдашымнан риза булмыйчарак мырлап яшәдемме?.. Кем хокук биргән мин – авыл гыйбадына бөтен кешеләрдән нидер таләп итәргә, таләпләрем үтәлмәгәндә, нарасыйлык күрсәтеп сукранырга, эчтән янарга?

Хәзерге акылым белән уйлыйм: мин үземне белә-белгәннән язучы булу турында хыялландым!.. Дүртенче класста шигырь-поэмалар язып, аннан хикәя-пьесаларга күчеп, язучы булып яшәдем. Төрмәдә дә мин язучы идем. Әзерлегем бәләкәй, офыкларым бикләнгән булса да, күңелем чикләрне үтеп чыга алырлык дәртле иде. Тормышны да мин әдәбият мәйданы, сәхнә итебрәк күрдем шикелле. Әнә шул югарылык, биеклек, язучы дигән җаваплы исем бик яшьли сеңгәнгә, мин еш кына буш хыялый, җилле давыллырак җан булып калдым бугай. Бүтәннәргә караганда бер өстенлегем дә бар иде: дөньяга мин әдип күзе белән карый идем. Кешеләрдән дә шундый үзенчәлекле тормыш мисаллары көткәнгә, Градобоевларга да, Гостевларга да өстән торып, хөкемдар рәвешендә карадым. Мин һәр адымым белән әнә шул бөек максатыма – язучылыкка якынайганда, күңелгәниләр килеп китмәгәндер дисең?! Иптәшләр бер мәлгә таралды, мин моны шактый авыр кичердем, ләкин ул дәвердәге таныш-белешләремә мин гомергә рәхмәтлемен: без алар белән бергә Карабас дигән мәктәпне үттек. Карабас Актасны әзерләде. Әдип исә тормышны тоташ хәрәкәттә, бербөтен итеп күрергә тиеш. Юк икән, аның иҗатын сугарып торучы чишмәләр юк, коесы кипкән... Меңләгән җаннарны бер бик астында йомарлап тоткан Актас мине яңа кешеләр, җанымның кайнарлыгын, намусымның сафлыгын саклап калырга ярдәм иткән гаҗәеп бай кешеләр арасына выжгытып алып кереп китте.

Нурихан
Фәттах

# ТӘНКЫЙТЬЧЕ

САТИРА-ЮМОР

Мин бик тәүфыйклы кеше: эчмим, тартмыйм, хатын-кыз белән чуалмыйм. Аннан да бигрәк, мин беркайчан да беркем белән дә ачуланышмыйм. Аннары мин бик сак кеше. Әйе, сак кеше. Югыйсә безнең агай-эне бик алама бит ул. Берәр ничек кыек басканыңны сагалап кына тора. Күрдеме, шундук тотып ашарга әзер. Шуңа күрә һәрвакыт алдыңны-артыңны карап йөргәнең яхшы. Берничек тә бәйләнерлек булмасын. Кыскасы, син миңа тимә, мин сиңа тимим. Вәссәлам! Жаның тыныч, ярмаң – аш...

Тагын шул, миндә әле сизгерлек дигән нәрсә дә бар. Мин кешенең аяк атлавыннан ук беләм – дусмы ул, дошманмы сиңа... Кирәк икән, җиде кат җир астында җылан күшәгәнен ишетәм мин! Җыеп кына әйткәндә, менә шундый әйбәт кеше инде мин.

Ләкин шулай була торып та, кайбер агай-эне мине никтер яратып җиткерми. Чынлап, яратмыйлар. Күзгә карап та әйтәләр, карамыйча да әйтәләр: мыштым, диләр, ялагай, диләр, начальство алдында тәлинкә тота, диләр.

Алар, билгеле, көнләшкәнгә күрә шулай диләр. Чөнки бары мин генә диярлек мастерлардан Фәлән Фәләнеч белән яхшы мөнәсәбәттә. Шулай булмыйча, начальство белән телгә-тешкә керергә башыма тай типкәнме әллә минем?! Юк, анысы инде булмас. Башкалар теләсә нишләсен, әмма ләкин мин үзем андый юлга басмам! Ә бездә башсыз халык җитәрлек – кемнең кем булуына карамыйлар, селкеп салырга гына торалар.

Шулай бер җыелышта безнең агай-эне Фәлән Фәләнечкә каршы ябырылды. Бирделәр кирәген! Ярый әле мин яклап чыктым үзен, югыйсә эшләре шәптән түгел иде безнең цех начальнигының.

Җыелыш беткәч, без ничектер моның белән бергә туры килдек. Кайсыдыр безне күреп калган. Икенче көнне килсәм... мине... шундый тәртипле кешене гәҗиткә төшергәннәр! Озын куллы итеп, Фәлән Фәләнеч алдында бишкә бөгелгән итеп төшергәннәр. Йөзем шундый ялагай, муеным нечкә, кулымда тәлинкә. Тәлинкәдә Фәлән Фәләнечнең эшләпәсе. Фәлән Фәләнеч юан корсаклы, борыны югары чөелгән. Миңа карамый да.

Кеше-ни ишетә күрмәсен... үзара гына әйткәндә, Фәлән Фәләнечне дөрес эшләгәннәр. Ул чыннан да шундый зур корсаклы, тупас, эре. Бары мине генә мыскыллаганнар. Беркайчан да минем Фәлән Фәләнечнең эшләпәсен тәлинкәгә салып та, салмыйча да тотканым юк. Шулай ук минем исемнән әйтелгән: «Эшләпәгезнең тузанын кактым, кияргә була, Фәлән Фәләнеч!» – дигән сүзләр дә ялган. Ачуымнан нишләргә дә белмәдем инде үзем дә! Шулай да түздем. «Ярар, күрсәтермен әле мин сезгә күрмәгәнегезне!» дип уйладым күңелемнән.

Хәзер мин үч алырга җай чыкканын гына көтеп йөри башладым. Озак көтәргә дә туры килмәде – берзаман җае да чыкты моның.

Ләкин шул чагында мин чирләп киттем, өч көн бүлитендә яттым.

Дүртенче көнне эшкә бардым. Барсам, тагын җыелыш җыйдылар. Докладчы сөйләп бетерер-бетермәс борын, мин беренче булып, сүз сорадым да беренче булып, трибунага менеп киттем. Менеп бастым да трибуна янына, кырып, ачулы гына башлап киттем:

– Иптәшләр, ни өчен безнең цех артта бара? – дидем. – Чөнки, иптәшләр, безнең җитәкчеләр начар, ягъни мәсәлән, цех начальнигы Фәлән Фәләнеч... Сез беләсез, иптәшләр, Фәлән Фәләнеч – дорфа кеше, эшчеләр белән рәтләп сөйләшми, кеше сүзенә колак салмый... Өстәл сугып кына кычкыра...

Шундыйрак сүзләр белән теттем генә Фәлән Фәләнечне! Кинәнгәнче тәнкыйтьләдем! Бөтен зал мине тын да алмый тыңлап торды. Исләре китеп, авызларын ачып тыңлыйлар. Күрәсең, минем кыюлыкка хәйран калганнар. Уен эшмени, миңа кадәр әле иң усал теллеләрнең дә Фәлән Фәләнечкә шулкадәр каты бәрелгәннәре юк иде бугай.

Халыкны әйтәм, тыңлап-тыңлап утырдылар да, кинәт исләренә килделәр, шаркылдап көләргә, шаулашырга тотындылар. Көләләр бөгелеп-бөгелеп! Көләләр эчләрен тотып! Мин инде аларның көлүенә игътибар итеп тормадым. Әйтәсе сүземне әйттем дә залга төштем, күкрәкне киереп, үземнең урынга таба атладым. Ә көлү тавышы һаман туктамый. Колак төбендә төрле сүзләр ишетелеп китә.

– Менә сиңа Мыштымбай! – диләр. – Соңгарак калгансың шул: кичәгенәк Фәлән Фәләнечне эшеннән алдылар! – диләр. Һы, әйттеләр яңалык! Аның алыначагы турында мин инде бер атна элек белгән идем.

*1964 ел.*

Афзал
Шамов

# ЖУРНАЛНЫҢ БЕР НӨСХӘСЕ

Бөек Ватан сугышы елларында без, фронттагы язучылар «Совет әдәбияты» журналының һәр санын бик сагынып, зарыгып көтеп ала идек. Безнең өчен бик кадерле кунак иде ул. Аның яңа саны килгән саен көннәр күңелле бер бәйрәмгә әверелә дисәм дә, арттыру булмас.

Кызганычка каршы, журналны тәртипле рәвештә ала алмый идек. Хәрәкәттәге армиягә подписка юк иде. Бары бандероль белән генә килә иде ул безгә. Ул еллардагы журнал редакциясе коллективына һәм Язучылар союзы җитәкчеләренә рәхмәт, алар фронттагы татар газеталарын онытып бетермиләр, журналның яңа саннарын җибәргәләп торалар иде.

Шулай да 1943 елны журналны алдыруда шактый зур өзеклек булды. Тылга, каләмдәш иптәшләребез хатлар язып, ялынып, ялварып та алдыра алмаган чакларыбыз булгалады. Андый вакытларда журналның яңа санын гына түгел, хәтта күптәнге саннарын күрү өчен дә әллә ни бирергә әзер идек без.

Журналның чираттагы саннарын күрергә сусап йөргән шундый айларның берсендә әле дә хәтердә, сентябрьдә, хәзер Бөек Ватан сугышы тарихында 1943 елдагы «Смоленск операциясе» дип аталган каты сугышлар барган көннәрдә, алгы сызыкта бер лейтенант миңа, сүз ара сүз чыгып:

– Безгә моннан бер ай чамасы элек «Совет әдәбияты» журналы килде, – диде. Бу хәбәр мине бик кызыксындырды. Аларга килгән, ә безгә юк.

– Кайсы саны?

– Май саны.

Бу санны күргәнем юк иде.

Мин сорашуымда дәвам иттем:

– Кемгә соң ул сезгә?

Мәхмүд Максудов дигән сугышчыга килгән булган. Бусы инде минем өчен чамадан тыш гаҗәп хәбәр булды. Мин, лейтенантны янымнан китеп бармасын дигәндәй, аның портупеясыннан тотып алдым.

– Кем соң ул Максудов? Язучы Мәхмүд Максуд түгелдер бит? Капитан?

Егет гамьсез генә җавап кайтарды:

– Кем белгән аны.

Ә минем сорауларым артканнан-арта бара иде: кайда ул Максудов? Кем булып хезмәт итә? Күргәнең бармы? Төсе-бите, кыяфәте ничегрәк?

Дустым Мәхмүд Максудтан күптән хат юк иде. Аның тылдагы хәрби частьтан фронтка киткәнен ишеткән идем, ләкин кайсы фронтка икәнен белми идем. Шуңа күрә бу исем мине бик кызыксындырды. «Безнең фронттамы икән әллә?» – дип уйлап алдым мин.

Лейтенант бу юлы да сорауларыма күңелне канәгатьләндерерлек җавап бирмәде.

– Батальоныбызда андый офицер юк, – диде ул һәм шунда ук өстәп әйтеп куйды: – Хәер, кем белә аны? Бәлки, булгандыр да. Мондый каты сугышларда бүген киләләр, иртәгә китеп тә баралар. Күбесе дөньядан ук китә. Нишлисең, сугыш.

– Батальоныгызда булмаса, полкыгызда яисә дивизиягездә Максудов дигән офицер юкмы?

Егет батальондагы офицерларны гына белә икән.

Ахырда мин Мәхмуд Максудовның кем икәнен, аның хәзер кайдалыгын полк яисә дивизия штабында ачыкларммын дип уйлап, соңгы соравымны бирдем.

– Ул журнал кайда соң? Миңа биреп тора алмыйсыңмы?

Кызганычка каршы, биреп тора алмый икән: Оборонада торганда, журнал батальондагы татар сугышчылары арасында кулдан-кулга күчеп йөргән, аны аерым-аерым да, җыйнаулашып та укыганнар. Ә хәзер ул күрше батальондагы татар сугышчыларында икән.

Лейтенантның әйтүенә караганда, сугышчылар аны бик кызыксынып, яратып укыганнар, хәтта ул татар сугышчылары арасында хәрби политик тәрбия алып бару өчен кулланма булып та хезмәт иткән. Сугышчылар аны тылдан, туганнарыннан, әти-әниләреннән килгән хат кебек итеп укыганнар.

Эзли торгач, ул журналны мин күрше батальоннарның берсеннән таптым. Табуы ансат булмады. Дөресен әйтергә кирәк: бик авыр булды. Каты һөҗүм сугышлары барган көннәрдә аерым сугышчыларны гына түгел, хәтта син күрергә теләгән офицерларны табуы да, алар янына бару да бик читен иде. Ике арада өзлексез ут астында тотылган, снарядлар, миналар белән актарылып, пулялар белән мыжлап торган территория ята иде.

Шулай да мин әлеге журналны табу бәхетенә ирештем. 1943 елда чыккан 5 нче санның бер нөсхәсе иде ул.

Гадәттәге нөсхә. Сугыш елларындагы начар сыйфатлы саргылтсу кәгазьгә басылган. Буявы шактый тонык. Хәреф хаталары да житәрлек. Шулай да аның тышкы күренеше, торышы һәм язмышы кызык иде.

Тышлыгын ертып алганнар. Әлеге лейтенантның әйтүенә караганда, анын эчке ягы буш булган, ягъни аңа бернәрсә дә басылмаган. Кәгазь юклыктан йөдәгән сугышчылар моңа бик шатланганнар, шунда ук аны ертып алып, тылга, әти-әниләренә туганнарына хат язганнар. Ике хатка җиткән, ике кешене бәхетле иткән.

Журналның текстлы өлеше беренче битеннән алып соңгы битенә кадәр тулысынча сакланган. Әмма ул, укыла-укыла, кулдан-кулга йөри-йөри, шул кадәр тузган, таушалган, күпереп, калынаеп киткән аерым юллары хәтта танымаслык хәлгә җиткән иде, – кыскасы, иң бәхетле, иң укылган китап язмышын башыннан кичергән иде ул. Сугышның тынып торган минутлары иде. Тынып торган дигәч тә, атышлар тәмам туктаган вакыт түгел, ә бераз басылып торган минутлары гына иде.

Мин күптән түгел генә немецлар ташлап качкан, әле һаман дары исе, үлем исе аңкып торган тәбәнәк бер землянкада журнал битләрен ашыгып-ашыгып актарырга, кайбер урыннарын укырга керештем. Сугышчылар аны миңа, дөресе, бер сержант, вакытлыча гына биреп торды.

– Зинһар, иптәш капитан, аны миңа кире кайтарып бирергә онытмагыз, – диде ул миңа, ялынган һәм үтенгән тон белән: – Бик кирәкле журнал ул. Миңа бик кирәк. Ротадагы татарлар, башкортлар, казакълар, үзбәкләр арасында агитатор мин. Аларга укыйм мин аны. Барысы да аңлый. Күрсәгез сез, татар халкының каян килеп чыгуы турында бик кызыклы мәкалә бар анда. Шигырьләр, хикәяләр да бар. Очерклар да.

Чыннан да бу санда Х.Гыймадиның «Урта Идел буе халыкларының татар-монгол игосына каршы көрәше тарихыннан» дигән мәкаләсе бар иде.

Журналны озак актарып торырга насыйп булмады. Атышлар көчәйде. Егетем минем янга ашыгып йөгереп керде дә:

– Гафу итегез, иптәш капитан, журналны мин алып китәргә мәҗбүр булам, – диде. – Батальоныбыз хәзер кузгала. Җыеналар. Ул журналга таба кулын сузды. Мин аңа каршы килмәдем, бирдем. Ул акланырга, миннән гафу үтенергә теләгәндәй:

– Бик кирәкле журнал шул ул, – дип кабатлады. – Безнең борынгы бабаларыбыз Идел буендагы башка халыклар белән бергә, бер сафта торып, монгол оккупантларына каршы сугышканнар икән. Бүген дә без...

Сержант әйтәсе сүзен әйтеп бетермәде, сөйләшеп торырга вакыты юк иде аның. Кадерле журналны противогаз сумкасына тыкты да йөгереп чыгып китте. Миңа да инде монда калырга кирәк түгел иде. Ашыгыч эшләрем, үтисе бурычларым бар иде.

Шулчак күңелемдә сакланып калган уемны әйтим: журналдан аерылу җиңел булмады миңа, якын дустымнан, кадерле иптәшемнән аерылган кебек хис иттем мин үземне.

Соңыннан билгеле булды: редакция чыннан да бу журналны көньяк фронтларның берсендә хезмәт итүче язучы Мәхмүд Максудка җибәргән булган икән (бу санда аның «Фәриднең хатлары» исемле очеркы да басылган иде), ләкин полевая почта күрсәткән цифрларның берсе ялгыш язылу аркасында, ул әдип кулына барып кермәгән, ә бөтенләй икенче якка китеп, Калинин фронтындагы бер батальонга эләккән һәм шунда аның бик кызыклы язмышы башланган.

Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң, Совет Армиясе сафыннан кайткан журнал редколлегиясенең бер утырышында мин бу вакыйганы иптәшләргә сөйләдем. Алар моны бик кызыксынып тыңладылар. Тик бер иптәшнең генә сугыш елларында фронтларда чыгып килгән татар газеталары редакцияләренә журналның яңа саннарын җибәрү эше йөкләтелгән сотрудникның гына кәефе бик китте, моны сөйләгән өчен миңа чынлап үпкәләде. Ул, үзенең хатасызлыгына бик нык ышанып, ачуланып:

– Әгәр анда сезнең полевая почталарыгыз адресны саташтырганнар икән, анда минем гаебем юк, – диде ул миңа.

Сүз шуның белән бетәр дип уйлаган идем мин, ләкин бетмәде. Редколлегия утырышында катнашучы өлкән язучыларның берсе, әлеге сотрудникка дусларча карап:

– Тукта әле, син нигә үпкәлисең моңа? – диде. – Афзал сине гаепләмәде бит, бары булган хәлне генә сөйләде. Әгәр төптәнрәк уйлап карасаң, син моңа үпкәләргә түгел, ә шатланырга тиеш. Беләсеңме нигә? Син ялгышып җибәргән журнал алгы сызыктагы сугышчылар кулына барып кергән, аларны көрәшкә, батырлыкларга рухландырган, фашизмга каршы сугышкан, атакаларга барган, бөек Җиңүне даулаган. Син менә бу вакыйганың шул ягын уйлыйсыңмы, юкмы?.. Ни дигән сүз бу? Журналыбыз халык белән бергә бара дигән сүз түгелме соң! Ә син үпкәләгән буласың. Үпкәләргә түгел, ә моны сөйләгән өчен рәхмәт әйтергә кирәк.

Өлкән язучының, аксакалыбызның сүзләрендә тирән фәлсәфи мәгънә бар иде. Чыннан да, журналыбыз халык белән бергә бара, аңа хезмәт итә, укучыларны ленинчыл рухта тәрбияли, аларны бөек коммунистик җәмгыять өчен көрәшкә өнди, чакыра.

Бу кызыклы вакыйгадан соң инде бик күп еллар үтте, бик күп сулар акты. Шулай да журналыбызның әлеге укыла-укыла тузып, керләнеп, каралып беткән нөсхәсе, аның язмышы әле һаман күңелемдә, күз алдымда.

*1972, №5*

# Гомәр Бәширов

## «ЯКТЫ ТӘРӘЗӘЛӘР»

Матбугат йортына якынлашканда, мин һәрвакыт ничектер үзеннән-үзе бишенче каттагы якты тәрәзәләргә күтәрелеп карыйм. Мин анда эшләгән еллардан соң инде бик күп вакыт узды, тормышка да зур үзгәрешләр керде, әдәбиятка да бик күп яңа көчләр килде. Ләкин шуңа карамастан, ул тәрәзәләр минем җаныма якын, мин аларны оныта алмыйм, алар минем күңелемдә кадерле истәлекләр уяталар, бергә эшләгән дусларымны, иптәшләремне исемә төшерәләр. Ул истәлекләрнең күңелгә аеруча газиз булып, аеруча онытылмастай булып калганнары, ихтимал, журнал редакциясендә бергә эшләгән иптәшләрнең матур әдәбиятка кайнар мәхәббәтләре, чиксез ихтирамнары, сәнгать һәм әдәбиятның яшәешкә тәэсир көче биниһая дип аңлаулары, шунлыктан, аңа мөкатдәс эш дип карап, җаннары-тәннәре белән бирелеп эшләүләредер.

1936 елда мин «Совет әдәбияты»ның җаваплы секретаре булып эшли башлаганда, журналның редакторы Гомәр Гали, поэзия бүлегенә Хәсән Туфан җитәкчелек итә, редколлегия членнары профессор Галимҗан Нигъмәти, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин һ.б. иде. Журналга керәчәк әдәби әсәрләрнең зурларын, җитдиләрен редколлегия утырышына куеп күмәк рәвештә фикер алышу кебек яхшы гадәт бар иде, кайчагында шул фикер алышулар әдәбиятның теге яки бу жанры, әдәби алымнар, гомумән, фәлән шагыйрьнең яки әдипнең яңа әсәрләрендә кая таба үсүе хакында кайнар бәхәскә дә әйләнеп киткәли иде. Ул чагында ук барлык шагыйрьләрнең һәм шигырь сөючеләрнең кумирына әверелгән Хәсән Туфан шигырь уку ритмына яшь авторның кулъязмасын селки-селки, әсәрдә оригиналь образ, философик фикер барлыгын расларга керешә. Зур белеменә, озак еллар әдәбият фәне укыту тәҗрибәсенә таянып, Галимҗан Нигъмәти сабыр гына үз сүзен әйтә. Шәриф абзый да үз фикереннән тиз генә кире кайта торган кеше түгел иде. Фатих Сәйфи-Казанлы исә, гомумән, бәхәсне бик тә яратыр иде. Ул да түгел, күп әсәрләргә ирония белән карарга, инкарь итәргә яратучан Гомәр Толымбайский, зур гәүдәсе белән чайкалгалап, кычкырып көлеп җибәрә. Кайчакларны бу сүз көрәштерүләр шундый кызып китә ки, Гомәр Гали, карандашы белән лампа абажурына суккалап, бәхәсләшүчеләрне тынычландырырга мәҗбүр булыр иде.

Кайбер укучыларда шундый сорау туарга да мөмкин: нинди бәхәс? Нәрсә турында шулкадәр кызып бәхәсләшергә? Эш шунда ки, ул елларда яңа аякка басып, яңа ныгып килүче совет әдәбиятының иҗат алымнары, гомумән, әдәбият фәне хәзерге кебек барлык нечкәлекләренә кадәр җентекләп өйрәнелеп, эшләнеп бетмәгән иде әле, әдәби иҗатка бәйләнешле күп кенә катлаулы теоретик мәсьәләләрне тирәнтен өйрәнәсе, ачыклыйсы бар иде. Борынгыдан калган бай әдәби мирастан ни рәвешле, ничек файдаланырга? Аның кайсы өлеше хәзерге заман таләпләренә хезмәт итә ала, кайсы өлешеннән ваз кичәргә туры киләчәк? Ул вакытта, мәсәлән, Фатих Әмирханны буржуа язучысы дип танып, аның әдәби мирасыннан баш тартырга өндәүчеләр дә юк түгел иде... Азмыни әдәбиятта уйлануны, фикер алышуны сорый торган катлаулы сораулар? Фәлән әсәр хәзерге әдәбиятка берәр яңалык өстиме, әллә элеккеләрне генә кабатлыймы? Бу әсәрдә нинди яңа образ, яңа сүз, яңа алым бар? Андый бәхәсләр вакытында Мирсәй Әмирнең «Агыйдел» повесте еш кына уңай яктан үрнәк итеп китерелә торган иде. Кыскасы, бу кешеләр журналга килгән әсәрләрдәге һәр яңалыкка, талантлы әсәр язган һәр авторга чын күңелдән куана беләләр, андыйларга журналда киң юл ачалар иде. Менә шундый бәхәсләр кайбер көннәрне ярты төнгә кадәр сузылгалый, тынып калган Казан урамнарыннан мин шул хакта юл буе уйланып кайткалый идем.

Аннан соң мин матур әдәбият, аның халык тормышында нинди әһәмиятле урын тотуы, аның эстетик тәэсиренең халыкта әдәп, әхлак тәрбияләүдә башка берни белән дә алыштырып булмый торган зур көч булуы хакында күп нәрсә белдем. Бу хакта зур съездларда, фәнни конференцияләрдә исеме бөтен дөньяга танылган мәшһүр галимнәр, язучылар фикерен дә ишеттем. Ләкин болар барысы да соңыннан гына килеп өстәлделәр. Сәнгатькә һәм матур әдәбиятка кайнар мәхәббәт һәм бөек ихтирам, алар халык тормышында могҗизалар тудырырга сәләтле дип инану, әдәби иҗат белән эш иткәндә, саф вөҗданлы, пакь куллы булу – менә болар, һичбер җилләр-давыллар дә үзгәртә алмастай катгый әхлак кагыйдәләре булып, минем күңелдә әнә шул якты тәрәзәле кечкенә бүлмәдә ныгып калдылар.

Истәлекләрнең күбесендә без әдәбиятны яки сәнгатьне әйдәп баручы эрерәк затлар яки башкалардан аерылып торучы зур талантлар турында язарга гадәтләнгән. Ихтимал, шулай кирәктер дә ул. Чөнки ул затлар үзләрен генә түгел, заманнарына хас типик халәтләрне дә гомумиләштереп күрсәтергә ярдәм итәләр. Ләкин сәнгать һәм әдәбият язмышын ул гали затлар фәкать үзләре генә хәл итеп бетерә алмый, аларга ярдәмче көчләр дә бар бит әле. Алар җәмәгатьчелек күзенә артык чалынмыйлар, исемнәре дә, теләсә кайсы басмада булсын, вак хәрефләрдән генә җыела. Әмма аларның хезмәтләре ифрат зур тырышлык, түземлелек, пөхтәлек һәм төгәллек таләп итә, алар автор язган һәр сүз өчен генә түгел, һәр хәреф өчен да җаваплылык хисе белән эшлиләр. Кыскасы, алар тырышлыгыннан башка бер генә басма да дөнья күрә алмый. Болар – техник редакторлар, корректорлар, секретарьлар.

Журналист Габдулла Гомәр дә әнә шундый тыйнак һөнәр кешесе иде. Егерменче-кырыгынчы еллар арасында матур әдәбиятта һәм көндәлек матбугатта аны белмәгән, аңа йомышы төшмәгән берәр кеше булдымы икән? Ул шулкадар «үз» кеше, шундый иләшкән сөйкемле иптәш иде, хәтта аның исем-фамилиясен дә икесен бергә кушып «Агомәр» дип кенә йөрттеләр. Әмма үзенә берни дә дәгъва итмичә, күбесенчә күләгәдәрәк торырга яратучы шушы тыйнак кеше журнал редакцияләрендә башкарган күп еллык намуслы, тырыш хезмәте белән аны белүчеләрдә озак онытылмаслык яхшы истәлек калдырды. Элекке зыялыларча һәрвакыт җыйнак костюмнан, һәйбәт галстук бәйләп, алтын чылбырлы пенсне киеп йөрүче бу интеллигент кыяфәтле журналистны без яратып «аяклы энциклопедия» дип атый идек. Бу исемгә бик тә лаек иде Габдулла, чыннан да анын белмәгәне юк иде. Кайсы зур әдәби вакыйга кайчан һәм кайда булган, ул хакта материалны каян табарга? Кайсы журнал яки газета кайчан чыга башлаган? Шуның ише тагын мең төрле сорауга һичбер мәшәкатьсез фәкать аннан гына җавап алып була иде.

1937 елның урталарыннан «Совет әдәбияты» журналын Габдулла Гомәр белән без икәү чыгара башладык. Мин вакытлы редактор вазифасын үтим, Габдулла Гомәр исә берүк вакытта җаваплы секретарь да, техник редактор да, корректор да, журналның тиражын тәэмин итәрлек кәгазь даулау да аңа йөкләнгән иде. Ул эшкә иртүк килә, журнал чыгасы көннәрдә типографиядә төнгә калып эшли, билгеле, эштән чыгып арый иде. Әмма мин Габдулланың бер генә мәртәбә дә зарлануын ишетмәдем. Аның каравы, журналның әле генә төпләнгән, буяу исе дә таралып җитмәгән яңа санын иртә белән редакция өстәленә китереп салганда, аның шатлануын күрсәгез иде! Калын пенсне пыяласы артында аның зәңгәр күзләре елтырый, үзе рәхәтләнеп елмая. Үзенең матур хезмәте нәтиҗәсенә чын күңелдән куанып яшәүчеләр миндә гомер буе тирән ихтирам хисе уята торган булдылар. Шушы шатлыклы вакыйганы билгеләп, без аның белән кара-каршы утырып сөйләшә-сөйләшә, бик тәмләп чәй эчә торган идек.

Бөек Ватан сугышы башланып, берничә ай узуга, язмыш безне яңадан шул ук журнал редакциясендә очраштырды. Матбугат йортының бишенче катында кечерәк кенә бүлмә (хәзер анда китап нәшрияты музее), бүлмә уртасында тимер мич. Аның бер ягында мин журналга килгән кульязмаларны редакцияләп утырам, мичнең икенче кырыенда Габдулла үзенә йөкләнгән эш белән мәшгуль. Тимер мичнең шунысы

яхшы – аның янында кулларга да җылы, кара савытындагы кара да бозланып катмый. Язучылар союзының хәзер инде дүрт кешелек кенә булып кечерәеп калган партия оешмасының (Хөсни Кәрим, Гази Кашшаф, Кави Нәҗми һәм мин) җыелышлары да, төрле утырышлар да шушы мич янында уздырыла иде.

1941 елның 16 ноябре көнне иртә белән без эшкә килгәндә, бөтен Матбугат йорты шау-гөр килеп тора, коридорлар, Габдулла Тукай клубының залы, күрше бүлмәләр Мәскәү язучылары, аларның гаилә әгъзалары белән тулган, сәхнәдәге зур рояль өстендә рәттән тезелешеп, балалар йоклап ята. Аларның әти-әниләре исә кайберләре Чистайга озатуны, кайберләре Казанда квартирага урнаштыруны көтәләр иде.

Безнең редакциянең ишеге төбендә мин портретлары буенча электән үк таныш булган уртача гына буйлы, чәченә чал керә башлаган, ябык кына чибәр кеше белән очраштым. Бу Италия язучысы Джерманетто Джованни иде. Хатыны белән икәү утырырга урын булмаганлыктан, басып торалар, балалары чемодан өстендә аркасын стенага терәп йоклап утыра иде. Габдулла белән без бер-беребезгә карашып алгач ук аңлаштык. Ишегең төбендә шундый хәлләр булып торганда, ни җаның белән ул бүлмәдә тынычлап эшләмәк кирәк? Джерманеттоны гаиләсе белән бүлмәгә кертеп урнаштырдык та үзебез белеш-таныш, дус-ишләр бүлмәсенә өйдәш булып кердек.

Джованни Джерманетто ифрат якты чырайлы, иркен күңелле, чын мәгънәсендә интеллигент кеше иде. Бездән гафу үтенә-үтенә, ул квартира табылганчы гаиләсе белән редакция бүлмәсендә яшәп торды. Тырыша торгач, Габдулла Гомәр аны Болак буенда яшәүче бик һәйбәт кешеләргә илтеп урнаштырды. Шул көннән башлап бу кунагыбыз Язучылар союзы янында оештырылган агитбригаданың иң актив членнарыннан берсе булып китте. Ул русча ярыйсы гына белә иде – завод-фабрикаларда, Тукай клубында оештырылган кичәләрдә фашизмның ерткычлыгын фаш итеп ялкынлы речьләр белән чыга башлады. Кичәләрдә итальян теленә тәрҗемә итеп Г.Тукай шигырьләрен дә укый иде.

Татарстан язучылары Мәскәү кунакларын, туганнарча якты чырай белән каршы алып, байтагысын үз квартираларына керттеләр. Кунаклар Казанда һәм Чистай шәһәрендә урнашып, берникадәр тормышлары тәртипкә салынганнан соң, Г.Тукай клубында әдәби кичәләр булып алды. Ул кичәләрдә, Джерманеттодан тыш, тагын француз драматургы Жан Ришар Блок, немец язучысы Вилли Бредель, Мәскәүдән Александр Фадеев, Алексей Толстой, Демьян Бедный, бездән Кави Нәҗми, Нур Баян катнашуы истә калган. Габдулла Гомәр белән безгә журнал чыгарудан тыш, байтак кына җәмәгать эшләре дә башкарырга туры килә иде.

Тагын шунысын да онытмыйк: сугыш вакытында журналларның күбесе чыкмый башлады. Әмма хәзерге «Казан утлары»ның абыйсы «Совет әдәбияты» юкарак булып калса калды, тиражын киметсә киметте – ничек итсә итте, әмма бер генә санын да чыгармыйча калмады. Моның өчен барыннан да элек партия өлкә комитетының ул еллардагы секретаре Самат иптәш Мәхәммәтовны һәм миннән соң редактор булып килгән, бу юнәлештә зур фидакарьлек күрсәткән мәрхүм Гази Кашшафны рәхмәт сүзләре белән искә алырга кирәк.

...Менә истәлекләр тәмамланып та килә. Иң әһәмиятле фактларны искә төшердем кебек. Инде нокта куярга да бик вакыт. Менә хәзер... Ләкин күңел түрендә тагын нидер бар икән ләбаса, кулның нигәдер нокта куясы килми... Шул чакны телефон чылтырады. Алсам, Диләрә Зөбәерова икән.

– Гомәр абый! Кырык беренче елда редакция ишеге төбендәге чемодан өстендә йоклап утырган баланың исемен әйтимме? – диде.

Мин хәйран калып сүз таба алмыйча торганда, Диләрә аңлатып та бирде:

– Ул Иоанна исемле. Хәзер бик чибәр ханым инде, Мәскәү радиосында бик җаваплы эштә. Алар әнисе белән Казанны һаман искә алалар, рәхмәтләре бик зур...

Әнә шундый искиткеч акыллы да, гыйбрәтле дә ул тормыш.

*1982, №5*

Гази
Кашшаф

# НИГЕЗ ТАШЛАРЫН САЛГАНДА

Һәрбер редакциянең үзенең «ломовой аты», авыр йөк тартып баручы хезмәткәре була. «Казан утлары» журналы редакциясендә дә андый хезмәткәрләр булды. Редакциянең бүгенге көнен телгә алмаска да мөмкин, чөнки киңәйде. Бүген эш төрләре хезмәткәрләр арасында тигез бүленгән. Барыннан да бигрәк журналга материал эзләп, төрле якка чабасы юк. Хәзер роман, повестьларны эзләмиләр, калын-калын кулъязмалар басылырга чират көтеп ята. Без тиешле югарылыктагы материалны каян алырга белми интегә идек. Бөек Ватан сугышы еллары хәтердә нык уелып калган. Партиянең Татарстан өлкә комитеты «Совет әдәбияты» журналын саклап калырга булды. Шул ук вакытта аппараттагы әдәби хезмәткәр штаты кыскартылды. Ул чакта журналны Гомәр Бәширов редакцияли иде. Озак та узмастан, партия оешмасы Гомәр Бәшировны фронтка, озак сроклы командировкага җибәрде. Бөтен эш Абдулла Гомәр җилкәсенә өелеп калды. 1942 елны Гомәр Бәшировны мин алыштырдым. Гомәр Бәширов Татарстан радиосының баш мөхәррире итеп билгеләнде. Журналда хәл авырлыгына котып салкыннары килеп кушылды. 1941 елның кышыннан бирле Матбугат йорты ягылмый иде. Менә без, Абдулла Гомәр белән икәү, «Совет әдәбияты» журналының нәүбәттәге санын әзерлибез. Бүлмәдә бер сәгатьтән артык утырып булмый. Салкын үзәккә үтә. Һәм без урамнан әйләнеп керәбез. Матбугат йортына караганда, урамда җылырак шикелле тоела безгә. Менә шундый авыр шартларда кемнең нәрсәгә сәләтле һәм ни дәрәҗәдә чыдам икәнен күрәсең. Абдулла Гомәр журналга барлык энергиясен салып эшләде. Сугыш сузылган саен кыенлыклар арта бара: кәгазь кытлыгы, типографиядәге авырлык, кулъязмалар җитмәү һәм башкалар. Өстәвенә баш мөхәррир айлар буе чәчү, урып-җыю кампанияләрендә йөри. 1943 елның җәендә типографиядә җыелмыйча хәрәкәтсез яткан журналларыбызның саны җидегә җитте. Димәк, җиде ай буе без укучыларыбызга журналны җибәрә алмыйча тордык. Бу өзеклекне бетерү өчен, билгеле, партия оешмалары күп тырыштылар. Ләкин типографиянең эшен, сугыш заказларын үтәүне тыярга кемнең кулы күтәрелсен?! Ул чакта Абдулла Гомәр дә нәшрияткa күчерелде. Без башта Әнәс Камал белән калдык. Бераздан Фатих Хөсни килеп кушылды. 1943 елның октябрендә миңа тагын бер эш йөкләделәр. Мөхәррирлектән бушатмыйча гына Татарстан Язучылар оешмасының җитәкчесе итеп сайладылар. Бер көнне кич белән мине җитәкче итеп сайладылар, икенче көнне Мәскәүгә юл алдык. Таҗи Гыйззәт, Кави Нәҗми, Нәкый Исәнбәт һәм мин, Мәскәүгә китәргә һәм СССР Язучылар союзының президиумында хисап бирергә тиеш идек. Язучылар союзы президиумында хисап докладын мин ясадым. Безнең эшебез мактанырлык түгел иде. Шуңа күрә кимчелекләрне һәм аның сәбәпләрен түкми-чәчми сөйләп бирдем. Утырышны Александр Фадеев алып барды. Моңа кадәр ул Казанда ике тапкыр булып киткән һәм хәлләр белән яхшы таныш иде. Бу безнең мәсьәләне президиум утырышына куеп, кулдан килгәнчә гамәли ярдәм күрсәтү, булышу теләге белән эшләнгән иде.

Президиумда ачыктан-ачык житди сөйләшү булды. Әйбәт, эшлекле тәкъдимнәр әйтелде. Ләкин Александр Фадеевны мондый сөйләшүләр генә канәгатьләндермәде. Шушындагы сөйләшүләрнең гамәли нәтиҗәсе булсын өчен ул безне Партиянең Үзәк Комитетына алып барырга теләген әйтте. Икенче көнне Таҗи Гыйззәт, Кави Нәҗми һәм мин Александр Фадеев белән Үзәк Комитетка юнәлдек. Үзәк

Комитетның пропаганда бүлегендә миңа шактый зур хисап доклады сөйләргә туры килде: Татарстандагы әдәби хәрәкәтнең торышы, нәшрият эшләре, язучы кадрларның барысы да диярлек фронтның алгы ут сызыгында булуы, аларның солдат хезмәтен үтәү белән бергә язучылык эшен дә алып барулары, үзебезнең дә бик авыр шартларда яшәвебез хакында сөйләдем. «Уңышлар турында сөйләмим, кимчелекләр турында әйтәсе килә», дип башлаган идем сүзне. Кызып киткәч, бердәнбер әдәби журналыбызның бик мөшкел хәле турында да сөйләргә туры килде. Кинәт мине сөйләүдән бүлдерделәр. «Ничек, сездә журнал чыгамыни?» Фадеев мин утырган урындык артында басып тора иде. Сорауны аңа да бирделәр: «Ә сез, Александр Александрович, бу хәлне беләсезме?» Миңа Фадеевның йөзе күренми, ул һаман кулын минем җилкәмә куеп басып тора һәм бик гади нәрсәне раслаган төсле үзенең ягымлы тавышы белән: «А как же, без җитәклибез», – диде. Фадеев чыннан да бу хәлне белә иде. Шуңа күрә аның сүзе: «Бу шулай һәм шулай булырга тиеш», – дигән мәгънәдә яңгырады. Казанда вакытлыча туктаган хәрби эшелоннардан бер генә данә булса да журнал бирегез дип килүче офицерлар турында, үзем командировкада йөргәндә, күрше Башкортстан районнарыннан берәр журнал сорап, кеше җибәргән колхоз рәисләре турында, редакциягә килгән хатлар турында сөйләдем. Үзәк Комитеттагы иптәшләр безнең хәлне яхшы аңладылар, авырлык белән булса да, журналны туктатмыйча чыгарып килүебезне хупладылар. Бу «подвиг» диделәр. Бу мактауны без Татарстан өлкә комитетының һәм журналда актив катнашучы барлык язучыларның уртак казанышы дип кабул иттек.

***

*Мин рядовой солдат бу сугышта,*
*Тик бер нәрсә белән аерылам:*
*Рядовойлар төнен йоклаганда,*
*Мин йокламыйм шатлык-кайгыдан.*
*Бер минут та башка тынгы бирми,*
*Окоп почмагында утырам.*
*Аламын да куен дәфтәремне,*
*Янып җыр язарга тотынам».*

Фатих Кәримнең бу шигыре татар фронтовик язучыларының күмәк портретын дөрес сурәтли. Шәрәф Мөдәррис, Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Әхмәт Ерикәй, Ибраһим Гази, Шәйхи Маннур, Гадел Кутуй, Мөхәммәт Садри, Хатыйп Госман, Гали Хуҗи, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Риза Ишморат, Әхмәт Исхак, Абдулла Әхмәт һәм башка фронтовик язучыларның эзлекле ярдәмнәре булмаса, журналны чыгару мөмкин булмас иде.

«Совет әдәбияты»ның һәрбер саны, кимчелекләре булуга да карамастан, теткәләнеп беткәнче укыла, кулдан кулга күчә. Тылдан бик кадерле бүләк төсендә, фронтка юнәлә. Хәрби частьлардан махсус соратып алалар, кичектерми фәлән-фәлән саннарын җибәрегез дип таләп итәләр. Әгәр дә алар сораган саннар барып житмәсә, шактый каты шелтәле сүзләр белән хат җибәрәләр. Мондый хатларны без тылдан да ала идек, очрашу вакытларында да шушы мәсьәлә күтәрелә иде. Шул рәвешчә, «Совет әдәбияты» журналы сугыш елларында халыкның юлдашы, сердәше, юанычы һәм куанычы булды.

*1972, №5.*

Фатих Хөсни

# АНЫҢ ЯКТЫСЫНДА...

Кайчандыр Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Гали кебек мөхтәрәм әдипләребез редакциясендә, «Безнең юл» исеме белән чыгарыла башлаган бу журнал соңыннан берничә мәртәбә исемен алыштырды, редакторлары алышынды – берәүләре китте, икенчеләре килде, ләкин журнал үзе китмәде, дөресрәге, без аңардан китмәдек, ул безнең өчен – татар язучылары өчен гел шулай безнең юл булып калуында дәвам итте. Әле дә шулай! Рус классикларыннан берсе, ялгышмасам, Тургенев бугай, әйтә: «Без барыбыз да Гогольның «Шинел»еннән чыккан кешеләр», ди. Шуңарга охшатып, бүген без – әлегә исән булган татар язучылары, бер авыздан диярлек әйтә алабыз: әйе, без шул бер юлдан – «Безнең юл»дан килдек һәм шул юлдан килеп ялгышмадык, шикелле...

Шәхсән, мин үзем әдәбиятка күп кенә борылмалы юллар үтеп, хаталар да ясаштыргалап, кайнаша-эзләнә кергән кеше. Элегрәк яшьләр матбугатында, пионер газеталарында кулымны сынадым. Әмма үземнең чын әдәби язмышымны 1927 елда «Безнең юл» журналында басылган «Дөнья матур миңа» дигән шат рухлы шигырем белән башладым дип, горурлык белән әйтә алам. Хәер, саный китсәк, күп алар. Ләкин укучыларга билгеле булган (минем шулай уйларга тәвәккәллегем җитә!) төп әсәрем – «Йөзек кашы», «Гыйльмениса», «Минем тәрәзәләрем», «Язмыш шуклыгы» кебек, үзем бик яратып язган повестьларым, «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» кебек романнарым һәм күп санлы хикәяләрем – бөтенесе шушы журнал битләрендә беренче укучыларын таптылар. Җәннәткә барып кергәнче иң элек сират күпере аркылы үтәсе бар – дини мифология шулай, ди. Әлбәттә, без дә җәннәткә йөгереп кенә барып кермәгәнбездер, без алай изге бәндәләрдән түгел, безне дә тараганнардыр, безнең да нервларыбызны бозганнардыр. Әдәбиятта шунсыз мөмкин түгел, шуның өчен редакция дигән «сират күпере» бар, анда, үч иткән кебек, үтә дә төпченүчән, үтә дә ортодоксаль, гади телгә күчереп әйтсәк, үтә дә «каеш» кешеләрне утыртып куялар. О, беләбез инде без аларны, йөрәгебезгә үтмәсә, бу чаклы сузып әйтмәс тә идек! Ә бит начарлык теләп түгел, яхшылык теләп – укучыга, язучының үзенә, ниһаять, гомуми әдәби хәзинәбезгә яхшылык теләп шулай эшлиләр, рәхмәт төшкерләре. Шуны истә тотып, журналның бу тантаналы көннәрендә аларга – редакциядә эшләп киткән кешеләрнең элеккеләренә дә, хәзергеләренә дә чын ихластан язучы рәхмәте җиткерәсе килә. (Рәхмәтне хәзергеләренә күбрәк тә «ишәргә» була, узганнары – инде узган, хәзергеләре белән алда әле маңгайга-маңгай очрашасы бар!)

Уен-муен калып торсын, ниһаять, менә без «Казан утлары» яктылыгына килеп чыктык. Шул игелекле юл, безнең юл, үз юлыбыз белән килеп чыктык. Журналда хәзер яңа, яшь көчләр эшли. Яшь көчләр дигән сүз, икенче төрле әйткәндә, яшь тешләр дигән сүз дә ул. Алар белән уен корып булмый, әйберең яхшы булса гына кил. Тулаем алганда, журнал, аның хәзерге торышы, утызынчы еллар, сугыш алды еллары белән чагыштырганда, күз генә тимәсен, сизелерлек яхшырды. Журналның тематик диапазоны киңәйде, басылган әсәрләрдә вакыйга өстеннән койрык чәнчеп чабуга караганда, кеше күңеленә тирәнрәк үтәргә тырышу сизелә, журнал соңгы елларда күп кенә яшь каләмнәр тәрбияләп үстерде. Болары – шулай, боларын безнең кулдан инде, шәт, тартып алмаслар. Әмма борын чөяргә ашыкмыйк, шулай ук, булып җитмәгәннәре дә юк түгел. Басылган кайбер әсәрләргә караганда, журнал редакциясендә утыручы «яшь тешләргә» кай очракта үткенлек, яхшы мәгънәсендәге «каешлык» җитешеп бетми. Темасы бөтенесен да аклый, дип карау да бар кебек. Аннары журналның гомуми культурасын күтәрү, фактларга карата төгәллек, гыйльмилек критериен саклау, әдәби

тел сафлыгына игътибарлылык, иҗтимагый тормышыбызның төрле өлкәләреннән төрлерәк каләмнәрне тарту кебек мәсьәләләрне дә көн тәртибенә куярга вакыттыр.

Ничек кенә димик, кай яктан гына килмик, без – татар язучылары – гел шул үзебезнең ияләшенгән «Казан утлары» яктылыгына килеп чыгабыз. Аның нурлары әлегә күзне чагылдырырлык ук булмаса да, шулай да азып-тузып йөрмәүче без тәүфыйк ияләренә җитәрлек. Аның яктысында яшь бөреләр ачылганнан-ачыла бара, урта буын ир-егетләре мәйдан тота, безнең ише карт-коры, карт мәчеләр кебек нигезгә сузылып ятып, сөякләрен җылыта. Ара-тирә сырт йоннарын бик кабартмыйча гына, мыраулап та куйган булабыз.

*1972, №5*

# Әмирхан Еники

## «БЕЗНЕҢ ЮЛ» – «КАЗАН УТЛАРЫ»

Уйлап утырам... Беренче әйберем («Озын көй тыңлаганда» дигән нәсер иде ул) «Безнең юл»да басылып чыкканда, миңа унҗиде яшь булган икән. Ә хәзер... Хәзергесен әйтеп тормаганда да була. Кыскасы, шул заманнан бирле кырык алты ел узып та киткән. Журналга исә менә илле яшь тулды. Димәк, без бергә картайганбыз?! Хәер, журнал картаямыни ул?.. Журнал яши дә яши, буыннардан буыннарга күчә-күчә яши, тик без генә олыгаябыз, китәбез, алышынып торабыз... Һәм шулай булырга тиеш тә ул!

Егерменче елларның икенче яртысында мин «Безнең юл»да берничә хикәя һәм вактөяк нәсер чыгарып өлгердем. Заманның барлык исемле язучылары катнашкан җитди журналда басылырлык булгач, ул әйберләр шул чактагы таләпләргә азмы-күпме җавап биргәннәрдер инде, әмма хәзерге таләпләрдән чыгып караганда, алар бик зәгыйфь нәрсәләр, шуңа күрә мин аларны искә төшерергә яратмыйм да.

Утызынчы елларның башында булса кирәк, журнал исемен үзгәртте: ул «Атака»га әйләнде. Исеменә ияреп, эчтәлеге дә бик нык үзгәрде. Мин үзем «Атака»га катнаша алмадым – ул елларда инде әдәбияттан читкә киткән идем.

Аннары журнал исемен тагын алыштырды – «Совет әдәбияты» булып чыга башлады. Аның бу исеме озын гомерле булды, һәм минем да яңадан әкренләп әдәбиятка кайтуым аның шушы чорына туры килә. Дөрес, сугышка чаклы мин аңардан һаман читтә идем әле, тик фронттан яза башлагач кына, ниһаять, аның бусагасыннан атлап кердем дия алам. Сугышның бу җәһәттән файдасы тиде – ул безне җыйды, туплады, берләштерде.

Соңгы егерме биш ел дәвамында инде мин журналның даими авторларыннан берсе булып танылдым дип әйтсәм, бу, шәт, мактанудан саналмас. Һәрхәлдә, барлык повестьларым һәм хикәяләремнең күп өлеше, шулай ук очерк-мәкаләләрем аның битләрендә басылып чыктылар. Билгеле, мин аңа бик ияләштем, төп иҗат йортым итеп карарга өйрәндем. Ләкин бу әле безнең арадагы мөнәсәбәт һәрвакытта тату-шома гына барды дигән сүз түгел. Нык кына тартышкан, бәхәсләшкән чаклар да күп булды. Әдәбият бик нечкә, бик четерекле нәрсә ул, бәхәс-тартышсыз җиңел генә үткәреп булмый аны... Хәер, бу кадәресе инде аның язучысына карап та билгеләнә торгандыр.

Мин үзем җитлеккән әдәбият һәр җәһәттән дә бик төрле булырга тиеш дигән карашта торам. Һәр язучы, һәр шагыйрьнең үз дөньясы, үз йөзе булса гына талантлы һәм кызыклы әсәрләр туарга мөмкин. Менә безнең хөрмәтле «Казан утлары»быз, бай традицияле җитди журнал буларак, аңа шул төрлелекне идея бердәмлеге нигезендә куәтли һәм чагылдыра алса, ул киләчәктә дә әдәбиятыбызның чын көзгесе булып калыр дип ышанасы килә... Бик озын гомер телим мин аңа!

*1972, №5*

Габдрахман
Әпсәләмов

*Мин журналга Бөек Ватан сугышы алдыннан килдем һәм аның аппаратында эшли башладым. Журналны халык никадәр яратканын сугыш елларында үз күзем белән күрдем. Бу хакта фронттан кайткач, «Кызыл Татарстан» газетасында «Совет әдәбияты» журналы турында «Солдат хатлары» дигән мәкалә дә бастырган идем. Гаҗәп ул хатлар!*

*1972*

# «СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ» ЖУРНАЛЫ ТУРЫНДА СОЛДАТ ХАТЛАРЫ

Фронт газеталарында эшләгән вакытта безнең кечкенә генә китапханәбез бар иде. Ул китапханәнең төп байлыгы – «Совет әдәбияты» журналында эшләгән вакытта сугыш елларында чыгып килә торган номерларыннан гыйбарәт иде.

Алгы кырыйда матур әдәбиятка мохтаҗлык гаять зур булганлыктан, без, хәрби корреспондентлар, командировкаларга чыккан чагында һәрвакыт, сугышчыларга кыйммәтле бер бүләк итеп, кыр сумкаларыбызга «Совет әдәбияты» журналын сала идек һәм аны туктаган бер частьтә башыннан ахырына кадәр укып китә торган идек. Шуның белән бергә без үзебезнең хәрби хәбәрчеләребезгә, агитаторларга, офицерларга һәм сугышчыларга журналны почта аркылы җибәреп торуны да оештырдык. Мондый вакытларда без редакция исеменнән сугышчы иптәшләргә: «Журналны укып чыккач, ротагыздагы яисә батальоныгыздагы бүтән иптәшләргә дә укырга бирегез. Ә барыгыз да укып чыккач, үзегезгә нинди әсәрләр ошавын язып, журналны яңадан безгә кайтарыгыз, ә без сезгә яңаларын җибәрербез» дип хат та яза торган идек.

Айлар, еллар үткән саен безнең китапханәбез, журналның яңа чыккан номерлары исәбенә, баеганнан-байый барды. Фронтка «Совет әдәбияты»ның яңа номеры килүе редакциядә эшләүчеләр өчен генә түгел, фронттагы татар сугышчыларының зур өлеше өчен дә бәйрәм була торган иде. Карелия урманнарында да, салкын Заполярье тауларында да, Норвегиядә дә, соңыннан Маньчжурия кырларында һәм Харбин йортларында да татар совет сугышчылары «Совет әдәбияты»н сөеп, яратып укыдылар. Моңа аларның үз хатлары шаһитлар. Ул хатларның күбесе минем исемгә, яисә редакциянең бүтән работниклары исеменә килделәр. Ефрейтор Әхмәтша Әһлетдинов иптәш болай дип яза:

«...Вә һәм дә шул да мәгълүм булсын, җибәрелмеш журналыгызны алдым. Без аны татар уллары бергә җыелышып, коптилка яктысында, коптилканың мае беткәч, чыра яктысында укыдык. Бездә, Заполярьеда, хәзер көн бөтенләй булмый бит. Шуңа күрә гел ут ягарга туры килә. Безнең күңелебезгә Нәкый Исәнбәтов иптәшнең «Мәрьям» дигән әсәре бик ошады. Түлке аның ахыры юк. Сез ул пьесаның ахыры басылган журналны да безгә табып җибәрсә идегез. Безнең яшьрәк егетләрнең кайберләре Мәрьямгә гашыйк та булдылар. «Хат язарга адресы юкмы?» дип тә сорыйлар. Мин Мәрьям живой кеше түгел, литературада гына икәнен аңлаттым. Безнең бер сугышчыбыз миңа ышанмады, живой булмаган кешеләр турында язарга писательләр җүләрләр түгел, ди. Син Мәрьямнен адресын безгә бирмәс өчен генә әйтәсен, ди...»

Журналда басылып килүче Фатих Хөсни иптәшнең кызыклы хикәяләре, А.Расих иптәшнең сугыш хикәяләре, Кави Нәҗми иптәшнең «Фәридә»се, Мирсәй Әмир иптәшнең «Минлекамал»ы турында укучылардан бик күп җылы хатлар килеп торды. Алар бу пьесаларның сәхнәгә куелу-куелмаулары белән, «Фәридә»нең музыкасын кем язуы белән, андагы арияләрнең көйләрен ничек белергә мөмкинлек барлыгы белән кызыксындылар.

Күп кенә хатларда: «Г.Разин иптәш үзенең «Намус»ын язып бетермәдеме әле? Кайчан

бетерә? «Намус»тан бирелә торган өзекләр безнең йөрәкләрне генә җилкендерәләр... Без ул повестьны тулысынча укыйсыбыз килә» дигән юллар кабатлана иде.

Җитди мәсьәләләр, тәнкыйтьләр, хикәяләр белән беррәттән, сугышчылар журналдан ял иттерә, күңелне күтәрә торган әйберләр дә эзлиләр иде. Мәсәлән, Мирсәй Әмирнен «Мөстәкыйм карт йокысы» дигән юмористик хикәясе, Әнәс Камалның «Беренче апрель» дигән пьесасы сугышчылар арасында бик популяр булып, телдән-телгә сөйләнә башладылар.

«Совет әдәбияты»нда урнаштырылган шигырьләр, аеруча Фатих Кәрим, Әхмәт Ерикәй шигырьләре сугышчылар тарафыннан сөелеп укылдылар, сөйгән кызларына, әти-әниләренә җибәрер өчен күчереп алындылар. Менә сержант Зариф Хөснуллинның хаты. Ул аны Рыбачий ярыматавыннан яза:

«Фатих Кәримнең шигырьләрен укый башласам, аерыла алмыйм. Аның әйткәннәре йөрәккә шул кадәр якын, аның хисләре шул кадәр безнекечә, әйтерсең, ул безнең арада торып яза. Дөрестерме, юктырмы, ул үзе дә безнеңише солдат, диләр. Адресы булса, зинһар, җибәрегез, без аңа күмәкләшеп хат язар идек һәм кызылармеецлар рәхмәтен әйтер идек.

Бүген мин дәфтәрем тулганчы аның шигырләрен күчереп утырдым...

Кардәш Карелияне немец һәм фин баскыннарыннан азат иткән вакытта безнең бер укчы бригадабыз дошман тылына десант итеп төшерелде. Свирь операциясе тәмам булгангача диярлек бу бригада өзлексез сугышлар алып барды. Аның белән бәйләнеш бары тик радио һәм авиация ярдәмендә генә булды. Газета һәм журналларны да аларга самолёттан гына ташладылар. Менә шушы бригадада хезмәт итүче старшина Мөхетдин Галләмовтан мин түбәндәге хатны алдым.

«...Кәефебез яхшы. Финнарның котларын алып, урманнарны айкап йөрибез. Бүген самолёттан почта ташладылар. Бәхетсезлеккә каршы, капчык суга төште – бередә атлаган саен күлләр йә сазлар бит. Юеш капчыктан минем исемгә сез жибәргән «Совет әдәбияты» журналы килеп чыкты. Мин анын һәрбер битен учак жылысында киптереп чыктым. Аннары иптәшләр белән бергә җыелышып укый башладык.

Бу номерда сөекле шагыйребез Габдулла Тукай турында күп язганнар. Шушындый ерак җиргә Тукайның килеп җитүенә без чиксез шатландык. Аның турындагы мәкаләләрне, аның шигырьләрен без бик яратып укыдык. Иптәшләр журналны чыгаручыларга да, журналга язучыларга да, аны безгә җибәрүчеләргә дә зур рәхмәтләр әйтергә куштылар».

Менә тагын бер хат.

«Редакциядә эшләүче иптәшләр!

Бу хатны сезгә таныш булмаган кавалер ордена Славы ефрейтор Шәйхетдин Хәбибрахманов яза. Мин Дальный Востокка килгәнче Восточный Пруссиядә сугыштым, Кенигсбергны штурмовать иттем. Шунда мин бер иптәштән «Совет әдәбияты» журналын алып укыдым. Миңа «Рөстәм маҗаралары» бик ошады. Тулысы аның продолжениесен таба алмаган идем. Менә хәзер Маньчжурияне үтеп, Харбинга кергәч, безнең полк агитаторыннан татарча газеталар һәм «Совет әдәбияты» журналын алдым. Ул журнал миңа бик ошады. Ну анда да «Рөстәм маҗаралары»ның продолжениесе юк. Агитатор капитан Закиров әйтә, редакциягә хат яз, анда бардыр, ди. Сез миңа шул журналны һәм тагын яңа журналларны җибәрә алмассызмы? Минем бик укыйсым килә».

Шушындый эчкерсез, ихлас күңелдән ярату белән язылган солдат хатларын тагын да күбрәк китерергә мөмкин булыр иде. Ләкин китергән кадәресе дә «Совет әдәбияты» журналының безнең сугышчыларыбыз арасында яратып укыла торган бер журнал икәнен, Бөек Ватан сугышы елларында бу журнал фронтларның иң алдынгы сызыкларына барып җитеп, сугышчыларга җан азыгы бирүен, аларны явыз дошманны тизрәк тар-мар итәргә өндәвен, ягъни бөек Җиңүебезгә үз өлешен кертүен күрсәтәләр. Бу – журнал өчен дә, аңа катнашучы татар совет язучылары өчен дә зур шатлык.

*«Кызыл Татарстан», 1946, №1*

Зәки
Нури

# ЖУРНАЛ ӨЧЕН, ЖУРНАЛ БЕЛӘН

Журналга мин кордаш һәм чордаш буларак, бары берничә генә эчкерсез сүз әйтергә телим. Ничектер туры килеп, без журнал белән бер тирәдәрәк туганбыз: инде менә илле яшьтәгеләр булып чыктык. Ләкин дөресе шул: журналга мин инде сугышка чаклы елларда ук шигырьләр, ә соңыннан исә шигырьләр белән беррәттән тәрҗемәләр, рецензияләр, мәкаләләр һәм очерклар җибәрүдән һәм 1968-1971 елларда аның баш редакторы булып эшләүдән башка, бер нәрсә дә бирмәдем кебек. Киресенчә, ул үзе миңа, барыбызга да биргәнчә, бик күпне бирде. Саный калсаң, чыннан да аз түгел бит! Беренчедән, әдәбиятыбызның иң яңа һәм иң яхшы әсәрләрен ай саен килеп торган яңа саннардан вакытында укып бару мөмкинлеген безгә шул журнал бирде һәм бирә. Икенчедән, миңа, әле башлап кына язучы бер үсмергә, язучылар исеменнән Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Сибгат Хәким имзалары куелган хатлар алу бәхетен шул журнал китерде. Өченчедән, берәр язганың басылып чыкса – түбәләремне күккә тидереп шатлану минутларын мин шул журналны алгач кичердем. Дүртенчедән – минем өчен, бәлки, аеруча истәлекледер бу – Белоруссиягә Константин Заслонов җитәкләгән партизаннар берләшмәсенә самолёт белән килеп төшкән берничә журналны поход биштәремә салып, патрон белән бер дәрәҗәдә кадерле итеп йөрткән куанычлы көннәр һәм атналар гомер-гомергә онытылмастыр шикелле.

Менә ни өчен журналны мин һәрвакытта да безнең һәммәбездән дә олы булган остаз итеп санаййм һам санармын. Журналны без әдипләрнең иҗат тәҗрибәсен, аларның иҗтимагый политик эшчәнлеге үрнәкләрен, тугандаш әдәбиятлар белән аралашу практикасын өйрәнә, туплый һам пропагандалый торган бер үзәк дип тә беләбез. Дересрәге, иҗатны, тәҗрибәне, эш нәтиҗәләрен яктырта яки туплый гына түгел, ә практик эшне Язучылар союзы идарәсе белән бергә оештыра да ул. Биредә В.И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән татарча ленинианa материалларының иң зур күпчелеген журнал тапты, журнал яздырды, журнал тәрҗемә иттерде дисәк, һич ялгыш булмас. Юлбашчыбызның Себердәге сөрген еллары һәм Польшада чактагы зур эшче турында шигырьләрне һам репортажны мин журнал кушуы буенча шул якларга барып яздым. Бүтәннәр исә журналның шундый ук бик мөһим, социаль, политик һәм әдәби заказын Ульяновскига, Куйбышевка, Ленинградка, Шушенскоега, Уфага, Псковка һәм Ленин булган бүтән урыннарда йөреп кайткач үтәделәр. Нәтиҗә шул: хәзер безнең Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган биш томлы татарча ленинианабыз бар, аның алтынчы томы исә быел чыгачак! Димәк, журнал безне киң дөньяга чыгара, безнең эшчәнлекнең һәм географик, һәм тематик офыкларын киңәйтү эшенә зур өлеш кертә.

Безнең хөрмәтле укучыларыбыз өчен дә журнал яңадан-яңа офыкларны әледән-әле ача тора. Аның соңгы елларда «Якташларыбыз сәяхәттә», «Алар бездә булганнар», «Елмаеп-көлеп кенә...», «Балаларга укыгыз», «Бездә кунакта» кебек рубрика белән бирелгән әсәрләр бик хуплап каршыланды. Эзләнүләр һәм ачышлар уңышлы дәвам итә.

Без, әдипләр, заман героикасы материаллары белән журналның эчтәлеген тагын да тирәнәйтү, аның тематик колачы белән сәнгатьчә сыйфатын төрле яклап күтәрү өчен тагын да күбрәк тырышырга тиешбез әле. Журнал өчен ешрак һәм яхшырак язган әдип журнал белән бергә тизрәк үсәчәк!

*1972, №5*

Атилла
Расих

# ӘДӘБИЯТ МӘЙДАНЫНА ЮЛ АЧУЧЫ

Мин 1939 елны үземнең татар әдәбиятыннан башка яши алмавыма тормышымның бернинди дә мәгънәсе калмаячагына иман китереп, Кавказдан өйгә, Казанга, кайттым.

Исәбем әдәби эшчәнлегемне юмор һам сатирага багышлау иде. Әзер темаларым да, бер-ике хикәям дә бар иде. Шулай кайту белән дип әйтерлек мин «Совет әдәбияты» редакциясенә киттем. Ул вакыттагы редактор Төхфәт Имаметдинов шунда ук мине каршысына утыртып, хикәяләремне укып чыгарга кушты һәм, яратканлыгын белдереп, хикәяләрне якындагы саннарның берсендә бастырачагын әйтте.

Юбилярыбыз үзенең яшәү дәверендә татар совет әдәбияты көчләрен туплау, әдәби хәрәкәткә дөрес юнәлеш бирү өлкәсендә күп тырышлыклар күрсәтте. Бүген актив һәм нәтиҗәле эшләп килүче әдәбиятчыларның күпчелеге беренче фатиханы шул журналда алдылар, шуның битләре аша киң мәйданга аяк бастылар, шунда чыныктылар, шунда үстеләр.

Минем үзем өчен дә әдәбият мәйданына юл ачучы шул ук безнең кадерле юбилярыбыз булды. Ул минем фронтта язган хикәяләремне укучыга оператив рәвештә җиткереп, миңа фашизмга каршы олы мәйданда каләм белән дә көрәшергә мөмкинлек тудырды. Ниһаять, сугыштан кайткач, фронтта язган беренче повестемны («Бәхет орлыклары») мин шуның битләрендә бастырдым. Бу исә миндә олы формаларга мөрәҗәгать итү кыюлыгы тудырды.

Ләкин, кызганычка каршы, бу вакыйгадан соң унбиш еллар чамасы мин журнал өчен мәхәббәтсез үрдәк баласына әйләндем. Ул минем «Дустым Мансур»ны да, «Язгы авазлар»ны да һәм, гомумән, язган һәр әсәремне тибәрә килде. Нихәл итәсең? Ситуация шундыйрак иде, күрәсең, ул чорда...

Минемчә, журналның йөзен редактор вазифасын үтәүче, әдәбият хәрәкәте өчен үтә җаваплы кеше билгели. Юбилей көннәрендә мин редакторлар арасыннан аерата зур хөрмәт белән үземә дебют мөмкинлеге биргән Төхфәт Имаметдиновны, сугыш елларында хәрәкәттәге армиядән язган әсәрләремне тоткарлыксыз басып барган Гази Кашшафны, «Ике буйдак»ны укучыга җиткергән Газиз Мөхәммәтшинны, «Ямашев»ка каршылык күрсәтмәгән Рафаэль Мостафинны рәхмәт әйтеп искә аласым килә.

Туганнарча кайнар ярату хисләре белән мин бердәнбер журналыбызны илле еллыгы көнендә тәбрик итәм, аңа бәхетле киләчәк, озын гомер телим.

*1972, №5*

Гариф
Ахунов

# ӘДӘБИ МӘККӘБЕЗ ЯШӘСЕН!

Татар әдипләренең кыйбласы, Мәккәсе булган «Казан утлары» журналына җитмеш яшь тулды. Ул элек СССР дип аталган илдә нәшер ителә башлаган журналлар арасында иң беренче сафта тора. Россиянең дә, башка республикаларның да журналлары арасында «Казан утлары» белән ярыша ала торган ике генә басма бар. Аларның берсе «Октябрь», икенчесе – «Сибирские огни». «Казан утлары»н мин унике яшемнән укый башладым, инде менә илле биш ел буена кулымнан төшермим. Беренче мәртәбә мин аны Көтек авылында әдәбият яратучы бер абзыйдан алып укыган идем, шунда ук мин аңа таң калдым. Үсмер чагымда, кайчан да булса мин анда әсәрләремне бастырырмын, аннан да бигрәк, ун ел буена шушы журнал редакциясендә эшләрмен, әдәби хезмәткәрдән алып баш мөхәррир дәрәҗәсенә хәтле күтәрелермен дип, башыма да китерми идем. Язмыш исә, рәхмәт яугыры, бу бәхетне һәм гаять зур җаваплылыкны насыйп итте.

Шунлыктандыр, «Казан утлары»ның яшәве, эчтәлегенең елдан-ел баюы, татар әдәбиятының күпчелек очракта иң яхшы үрнәкләрен дөньяга чыгарып, халыкның рухын күтәрүе, эстетик зәвыгын тәрбияләве мине чиксез шатландыра.

Әйе, шатландыра һәм... соңгы вакытта куркуга салган хәл дә бар. Нигә? Ни өчен куркуга төшәм? Без бик авыр, бик болгавыр заманда яшибез. Гәзитләрдә һәм радио-телевидениедә көннән-көн куркынычрак хәбәрләр, йөрәккә шом сала, җанны өшетә торган хәбәрләр әйтеп торалар. Икмәккә бәя күтәрелүгә дә, кием-салым кыйммәтләнүгә дә – әгәр алар вакытлыча булса – түзәргә мөмкин әле. Ә менә кәгазь бәһасе күккә сикерүдә, алай гына да түгел, кәгазь кытлыгы килүгә түзәргә мөмкин түгел. Кәгазь кытлыгы котылгысыз рәвештә гәзит-журналларның ябылуына китерәчәк! Беренче чиратта – Рәсәйнең элекке колонияләрендә, ягъни бездә.

Бу инде милли аңны, милли рухны сытуга бәрабәр! Рәсәй «демократ»ларыннан бүген барысын да көтәргә була. Элекке автономияләргә бәйсезлек бирмәс өчен, аларның мәдәниятен үстермәс өчен, «демократ»ларның кыланмышлары чиктән ашты.

«Казан утлары»ның җитмеш еллыгына карата уй-фикерләремне яза башлаган көнне мин Александр Сергеевич Пушкинның һәлакәтен күрсәтүгә бәйле нәфис фильм карадым. Патша чиновникларының бөек Пушкинга булган мөнәсәбәтләреннән, аны күралмауларыннан тәннәр чымырдады.

«Әдәби талант – ул хакимлек, ул власть», – ди Пушкинның якын дусты шагыйрь Василий Андреевич Жуковский.

Моны ул бөек шагыйрь белән саубуллашырга килгән «кара» халыкны Пушкин яшәгән йорт яныннан куып җибәрергә кушкан барингa әйтә.

«Әдәби талант – власть». Ә властьны безгә, әдипләргә, бирергә теләүче бармы? Үз теләкләре белән әдипләргә властьны кем бирсен?!

«Безнең юл» журналын ачкан чакта Галимҗан Ибраһимов аның озын гомерле булуын, татар әдәбиятының көзгесе булуын теләгән. Аңардан соң инде ничәмә буын мөхәррир безнең бу рушан көзгебезне тутыктырмас өчен күпме көч сарыф иткән!

Җитмеш елда «Казан утлары»ның 835 саны басылды, ул хәтта Бөек Ватан сугышы елларында да чыгудан туктамады. 835 сан җитмеш елда татар халкының мәдәни үсеш тарихын чагылдырган 835 том. 15 меңнән артык әсәр. Алар арасында – 300 повесть һәм роман, меңләгән хикәя һәм шигырь, тәнкыйть мәкаләләре, культурабыз үсешенә бәгланышлы проблемалы хезмәтләр, халыкның йөрәк тибешен чагылдырган сәнгатьчә очерклар һәм кайнар публицистика!

Кинәт, көтмәгәндә, журналыбыз чыгудан туктаса? Кәгазь кытлыгын сылтау итеп! Моңа юл куярга ярамый! Без Татарстан хөкүмәтенең капкасын гел кагып, әдәби Мәккәбезгә куркыныч янаганын аның исенә төшереп торырга тиешбез.

Югыйсә бит әнә Татарстан китап нәшрияты ябылу алдында. Кәгазь булмау аркасында, быел 170 китапның, инде типографиягә бирелгән китапларның басылмавы мәгълүм булды.

Татарстан Министрлар Кабинетының «Казан утлары» журналын үз канаты астына алуы күңелдә өметләр уята. Хөкүмәтнең журналны оештыручылардан берсе булуы – журналның туктамаячагына гарантия.

Ә без, Татарстан язучылары һәм башка өлкәләрдән күтәрелә торган әдипләр, журналны сәнгатьнең югары законнарына таянып иҗат ителгән әсәрләребез белән югары кимәлдә тотарга, аңа һәр яктан булышырга сүз бирсәк икән.

Теләгебез бер генә – котлы булсын «Казан утлары»ның бәйрәме! Бу бәйрәм кадерле журналыбызга озын гомер алып килсен! Амин.

*1992, №5*

Илдар
Юзеев

## ЖУРНАЛЫБЫЗ ТУРЫНДА

Безнең балалык еллары Ватан сугышы чорына туры килде. Әтиләр сугышта, тормышны картлар, хатын-кызлар һәм көчтән килгән кадәр без, балалар, арбага-чанага да, сабанга да җигелеп алып барабыз. Керосин юк, китап-журналларны кичке караңгылыкта мич яктысында укыйбыз. «Совет әдәбияты» журналы ул елларда бик тә сагындырып кына килә, кайвакыт ике саны бер булып та чыга иде. Шуның өстенә почта да тоткарлана. Күз ачкысыз кышкы бураннарда авыл чигенә чыгып, еш кына почтаны каршылый идем. Тол хатыннар сугыштагы ирләреннән хәбәр көтә. Ә мин әтидән хат һәм Казан кебек нурлы «Совет әдәбияты» журналын көтәм. Әтидән хат юк, ә журнал бар! Ул әтидән килгән хат кебек! Журналда басылган әсәрләр тәэсирендә мин, ун яшьлек малай, капитан-артиллерист әтиемә шигырь белән хат язам:

*Дошманнарга төбәп аткан чакта,*
*Калтырамаслык булсын кулыгыз,*
*Сугышларда батыр булыгыз,*
*Сәлам белән «шагыйрь» улыгыз...*

Журналның элегрәк басылган саннарын табып, Газиз Иделленең «Дәүләт Бәдриев» пьесасын, дус малайлар белән җыелып, «сәхнә»дә – мунча ләүкәсендә куябыз. Икенче класста укыганда, үзем «Алсу гөлләр» исемле «пьеса» язып, анысын инде тагын да зуррак «сәхнәдә» – өйдә уйнадык. Өйдән мәктәп сәхнәсенә күтәрелдек: мин язган «Моңлы җыр тавышы»н үзебезнең пионер отряды көче белән куйдык.

Уеннан уймак чыгып, соңрак «Совет әдәбияты» мине моңлы, дәртле, нурлы Казанга – Тукай, Такташ, Сәйдәш Казанына тартты. Тора-бара журналның укучысыннан аның авторы, соңрак – штаттагы хезмәткәре булдым, әмма барыбер аның даими укучысы булып калдым. Менә кырык ел инде «Казан утлары»ның яктысын, нурын, җылысын тоеп яшим.

*1982, №5.*

Аяз
Гыйләҗев

# ЖУРНАЛНЫ ТАТАР ЯШӘТӘ

Журналның язмышы авыр булды, татар әдәбиятының да язмышы шулай иде. Әгәр ул хөр фикерләрне чыгара башласа, йә Мәскәүдән, йә Казаннан чукмар белән аның башын төеп тордылар. Аның хәтерен җимерделәр, әдипләребезне 37 нче елларда бер кырсалар, сугыш елларында алар икенче мәртәбә чалгы астында калып харап булдылар. Ләкин журнал чыга килде, журнал яшәде, журнал ул хәтәр җилләрнең уртасыннан барган очкыч кебек давылларга-җилләргә бирешмәде. Бусы хак. Булды, әллә ниләр күрде безнең башлар. Ләкин без монда үзебезнең татарны зур хөрмәт белән искә алыйк. Журналны әдипләр генә түгел, журналны сәяси белгечләр генә түгел, журналны шагыйрьләр генә түгел, журналны татар яклады. Журналны татар ясады, татар рухсытты, татар яшәтте.

Менә мин хәтерлим, сугыш елларында журнал ике мең, өч мең тираж белән чыга иде. Уйга калып, кайвакытта күз алдына китерәм, кемнәр язылды икән, кемнәр алды икән ул журналны, нинди хисләр, нинди уйлар белән кулларына тоттылар икән алар аны? Ничә буын татар «Казан утлары» журналын үзләренең канатлары итеп яшәп килде, татарлыкларын арттырдылар, татарлыкларын расладылар, журналны яшәттеләр һәм үзләре дә яшәделәр. Шушы уңайдан бер хәвефле уем белән уртаклашасы килә. Менә бүген журналга 70 ел. Әйдәгез әле, тагын бер 70 еллыкка сикереп уйлап карыйк, 60 еллыгына, 50 еллыгына, 30 еллыгына, 10 еллыгына. 10 елда буыннар алмашына, 10 елда буыннар үзгәрә, 20 елдан язучыларның әсәрләре ике процент кына кала. Менә күз алдына китереп карыйк. Бүгенге татар кем ул? Нинди ул? Без бит тынычландыру сүзләре генә әйтергә яратабыз. Имеш, татар йоклаган иде, менә хәзер, имеш, татар уянды. Нинди татар уяна? Карт татар уянамы, яшь татар уянамы? Нигездә татарлыгы аның канында калган, тамырларында ага торган өлкән буын татар уяна. Әле дин аны беркадәр саклап калган, әле ул элеккеге замандагы яхшы игътибарлы, мәрхәмәтле, шәфкатьле, изге татарларны күреп үскән. Ә хәзерге татар нәрсә күрә? Ул татар 10 елдан соң ничек булачак? Димәк, «Казан утлары» алдында бик күп бурычлар тора. Милли аңны үстерүдә ул бик зур эш башкарырга тиешле журнал. Ул әле шуны белергә тиеш: 20 елдан соң татарлар нинди булырга тиеш, 30 елдан соң нинди булырга тиеш – барсы турында кайгырту журнал өстендә. Чөнки без ваемсыз һәм гамьсез татарлар булмыйк инде. Дөнья безне нык өйрәтте бит. Без яратабыз юанырга һәм бер-беребезне юатырга, хәтта ипләп кенә шомартырга, алдашырга да. Ләкин милләт язмышы бервакытта да шомартуга мохтаҗ түгел һәм безнең алдагы мәсләгебез – еракка китеп карау. Шул ерактагы татарны күрә алсак, без татарны яшәтербез, һәм милләтнең дә эзе тарихта беркайчан да суынмас!

*1992*

Равил
Фәйзуллин

# ЖУРНАЛНЫҢ ҮЗ АРХИВЫН БУЛДЫРЫЙК

Бала чакта, без, малайлар, яр ягасына җыелып, кулларны каш өстенә куеп, озаклап, Камага хәйран калып карап тора идек. Мәгърур, тантаналы кыяфәттә ак пароходлар уза, җыйнак катерлар үтә, арлы-бирле җиңел көймәләр йөренә. Кайчак, Кама-Чулманны урталай яргандай итеп (ул чак сулар галәмәт җәелмәгән иде), сузаеп, озын-озын баржалар таккан буксирлар уза. Алар салмак бара, озак уза, чөнки йөкләре авыр, юллары авыр. Кайсы баржага күмер төялгән, кайсына бодай, кайсына агач, кайсына кавын-карбыз... Ә буксир тарта да тарта...

Мин үзебезнең «Казан утлары»н күп йөкләр сөйрәүче нәкъ шул буксирга охшатам. Ул – мәдәниятебезнең күп кырлы һәм күп санлы хаҗәтләрен хәл кадәри канәгатьләндереп бара торган бердәнбер калын нәфис журнал. Төп вазифасы – укучыларны әдәби хәрәкәтебезнең торышын билгеләүче әсәрләр белән таныштыру белән бергә, журналыбыз сәнгатьнең бүтән өлкәләрен дә колачларга тырыша. Фәнни хезмәтләр, тарихи материаллар, театр, музыка, рәсем сәнгатьләренең үсеш тенденцияләрен чагылдырган мәкаләләр... Кыскасы, иҗтимагый, рухи тормышның көзгесе ул «Казан утлары».

Инде журнал белән шәхсән минем багланышка килгәндә, 10 елга якын эшлекле мөнәсәбәттә торабыз дип саныйм. Бу дәвердә журнал битләрендә байтак шигырем басылып чыкты. Алардан тыш мәкаләләр белән дә катнашып киләм. Беренче шигырьләрем басылганнан алып, бүгенге көнгә кадәр (шәт, киләчәктә да шулай булыр дим) бу журналда басылуны бер сынау мәктәбе узу һәм зур дәрәҗә дип саныйм. Татар әдәбиятының үзеген тәшкил итүче язучыларның күпчелеге, мөгаен, бу журналны үсү мәктәбе дип таный торгандыр. Һәрхәлдә, соңгы ун елда әдәбиятка аяк баскан яшь язучылар өчен «Казан утлары» чын мәгънәсендә старт мәйданы, күтәрелү ноктасы булды. Бер генә мизгелгә «Казан утлары» юк дип фараз итик. Әкиятләрдәгечә күкне җиде кат дибез икән, ихтимал, рухи күгебезнең берничә каты җимерелеп төшәр иде. «Талантлы-канатлы» дибез икән, бу тәгъбирне белү генә җитми бит, канатлы икән, очарга да кирәк. Биеклек кирәк, күк кирәк!

Миңа үземә дә вакытлыча гына булса да, бу журнал редакциясендә беркадәр эшләп алырга насыйп булды. Ул – редактор булып, Р.Мостафин эшләгән вакыт, тираж берничә мәртәбә үскән, журналның укучылар арасында бик нык популярлаша бару чоры иде. Төрле бүлекләрдә аз-маз эшләштергәләгәнгә күрә, сотрудникларның эшләре дә беркадәр таныш. Бүлекләргә ул вакытта да җиңел түгел иде, хәзер язучылар күбәйгән, табигый, әсәрләр дә күбәя барган саен, эш катлаулана, әсәрләр, авторлар, ниһаять, укучылар алдында җаваплылык арта төшкән булырга тиеш. Алыйк тәнкыйть бүлеген генә. Асылда, бу әдәби тәнкыйть бүлеге генә түгел бит, сәнгатебезнең барлык төрләрен барлап баручы, гомумән, әдәби иҗтимагый фикер үсешен чагылдыручы бүлек. Журналның икенче яртысында вак хәреф белән басылган материалларның күләмен һәм эчтәлеген күздән кичереп, хисаплап карасаң, бүлек башкарган хезмәтне беркадәр чамаларга мөмкин. Әлбәттә, һәр бүлекнең үз спецификасы, үз мәшәкате, үз җаваплылыгы. Журналыбызның 50 еллык бу бәйрәме белән, күңелемдә йөрткән бер теләгемне дә әйтәсе килә: журналның чын үз архивын булдырырга иде! Мәдәнияткә караган күпме кульязма керә редакциягә! Бик күп бит. Әлбәттә, бөтенесе басылып бетә алмый, күпмеседер кала, күпмеседер беркадәр үзгәртелә, кайберсе авторга кайтарыла, кайберсе, еллар үткәч, югала да торгандыр... Бер заман кемнәрдер эзләячәк, киләчәк буын рәнҗиячәк. Әйтик, 50 еллык бәйрәмдә журналның «Безнең юл»дан «Казан утлары»ның бүгенге 5 санына кадәр саннарның тулы комплектлары булсын иде әле

редакциядә. Күргәзмә оештыр идең, күрсәт идең, тотып, актарып кара идең! Ә бу бит әле хыялланыр нәрсә түгел, табигый булырга тиеш, элементар нәрсә. Кыскасы, бу юнәлештә, гомумән, әдәби мирасның кыйммәтен аңлау һәм аны барлау юнәлешендә безнең һәрберебезгә уйларга уй, эшләргә эш җитәрлек.

«Журнал миңа нәрсә бирде» дигән сорауга бик күп рәхмәтле сүзләр белән җавап бирергә мөмкин. Журнал сөенеп басарлык, укучылар яратып укырлык әсәрләр язсак, бу – безнең иң чын рәхмәтебез булыр. Бәйрәм уңае белән, редколлегия членнарын, редакция аппаратында эшләүче хезмәткәрләрне ихлас котлыйм, фидакарь эшләрендә уңышлар телим. Якын елларда журналның тиражы 100 меңгә җитсен. Шулай булсын, республикабызның бай тормышын хәзер зур саннар-миллионнар, миллиардлар билгели.

*1972, №5*

# 50 ЕЛ УЗГАЧ

Журналыбызның 50 еллык юбилее уңае белән бу язманың басылуына да нәкъ 50 ел икән. «Ун елга якын эшлекле мөнәсәбәттә торам» дип тә әйткәнмен бит әле. Димәк, бүгенгедән караганда, бергә-бергә 60 еллап гомер кичерелгән. Үзе бер озын гомер!

Бу вакыт аралыгында дәрьяларда күпме сулар акты да, җир йөзендә ниләр генә булып бетмәде! Шушы дәвердә, ким дигәндә, ике буын алышынды; ил-мәмләкәтләрдә йөзләрчә патша-ханнар, президентлар хакимлек итеп китеп бардылар... Үзгәрәк булса да, рухи дөньяда да шундый ук үзгәреш-яңарышлар. Һәр чорның үз идеологиясе, үз социаль катламнары, үз хаким итү ысуллары. Үзебезнең ил-җирлекне генә алыйк. Өлкән буын хәтерли булыр: бишьеллыклар, шәхес культы чоры, «җепшеклек» еллары, торгынлык дәвере, үзгәртеп кору җилләре, демократик хәрәкәтләр, халыкларда милли үзаң уяну, СССР таркалу, дефолт галәмәтләре, халыкара ызгышлар, шовинизм чаткылары... Озак еллар буе, «шөкер, без сугыш күрмәгән буын» дип, эчке сөенү белән юанып йөрсәк тә, аның өшеткеч сулышы, барыбер, безне дә эләктереп алды (күрәсең, сугыш ул – кешелек яшәешенең бер формасыдыр инде...) Кемгә дә булса – күршеме, илдәш-җирдәшме – кайгы-хәсрәт килсә, ул иҗат кешесе, бу очракта язучы йөрәге аша үтә. Явызлык-яманлык белән көрәшү, гаделлеккә омтылу – ул язучының миссиясе, аның вөҗдан, намус эше.

«Казан утлары»ның 100 еллыгы уңае белән махсус китап-альбом әзерләгәндә, журнал архивын барлап, бер гасыр эчендә чыккан саннарны актарып-өйрәнеп утырганда килгән уйлар бу. Чыннан да, безнең язучыларыбызның күбесе халык тормышы белән яшәгән фидакяр затлар икән. Үз иман-идеаллары өчен көрәш юлында аларның байтагы корбан да булган. Журналда чыккан әсәрләрнең күбесе шуны раслый.

Фәкать үзебезнеке дип әйтерлек матди-милли байлыгыбыз юк диярлек. Әмма без зур рухи байлыкка ия. Ул – бөек мирас. Сүз уңаеннан, шунысын да әйтеп үтим: моннан 50 еллар элек күңелдә йөрткән хыял-теләкне дә тормышка ашырдык, ниһаять, журнал архивы булдырылды; журналның 100 елда чыккан саннарының иң зур өлеше редакциядә бар хәзер.)

«Казан утлары» мирасы исә – безнең рухи хәзинәбезнең төп өлешләренең берсе. Горурлык хисе уята торган мирас. Мондый хисне моннан 15 еллар элек, журналның 1000 саны чыгу уңае белән «Сүнмәс утлар балкышы» дигән уникаль китап әзерләгәндә дә тойган идем. Хәзер дә шундый хисләр кичерәм.

Алда әйтелгәнчә, 60 елларга сузылган әдәби гомерем турыдан-туры «Казан утлары» белән бәйләнгән (көнем «Казан утлары» дип язылган чынаяктан иртәнге чәй эчү белән башлана). Яшьлек елларымнан башлап, картлык көннәремә кадәр дип тә әйтеп буладыр. 60 еллар уртасында (студент елларында, армиягә хәтле һәм кайткач) редакциядә 2 еллап эшләп алган идем. Соңрак, 1989 елдан 2014 елга кадәр, ягъни 25

елга якын баш мөхәррир йөген тартырга туры килде. Хәзер дә, редакциядә эшләмәсәм дә, бүгенге эш вазифам буенча да, редколлегия әгъзасы буларак та, гомумән, күңел кушуы буенча да көн саен диярлек редакциягә кереп чыгам. Шулай итеп, «Казан утлары» яшәү мәгънәмнең төп бер өлеше булып чыкты. Язмышка рәхмәт! Аның 100 еллык юбилей бәйрәмендә якын хезмәттәшләр белән бер сафта булу үзе бер бәхет бит!

*Май, 2022 ел*

## «Казан утлары» журналы редакциясендә эшләгән хезмәткәрләр исемлеге

***Баш мөхәррирләр:*** *Рафаэль Мостафин, Гариф Ахунов, Зәки Нури, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Илфак Ибраһимов, Рөстәм Галиуллин.*

***Бүлек мөхәррире вазифасын башкаручылар:***

*Әхсән Баян, Ләбибә Ихсанова, Яхья Халитов, Вакыйф Нуруллин, Нури Арсланов, Малик Хәмитов, Фәрваз Миңнуллин, Вил Ганиев, Рәдиф Гаташ, Мансур Вәлиев, Хәмзә Зарипов, Гәрәй Рәхим, Илдар Юзеев, Әхәт Гаффар, Ринат Мөхәммәдиев, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, Кояш Тимбикова, Мөдәррис Вәлиев, Зиннур Мансуров, Рәшит Әхмәтҗанов, Солтан Шәмси, Тәүфикъ Әйди, Рашат Низамиев, Нияз Акмал, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Марс Шабаев, Флүс Латыйфи, Наис Гамбәр, Рамил Исламов, Мәгъсүм Хуҗин, Әхмәт Рәшитов, Камил Сәгъдәтшин, Шаһинур Мостафин, Мәгъсүм Гәрәев, Алмаз Гыймадиев, Факил Сафин, Камил Кәримов, Марат Закир, Раиф Мәрданов, Ихтыяр Гаязов, Рәдиф Сәгъди, Галимҗан Гыйльманов, Алмаз Хәмзин, Ләбиб Лерон, Гөлзадә Бәйрәмова, Әлфәт Закирҗанов, Вакыйф Нуриев, Рамил Ханнанов, Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Ландыш Әбүдәрова, Рафис Корбан.*

***Гамәли хезмәткәр булып эшләүчеләр:*** *Роза Сөләйманова, Фәүзия Бәйрәмова, Роза Нәбиуллина, Сәмига Бәдретдинова, Асия Минһаҗева, Илсөяр Иксанова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлшат Салихҗанова, Рәзифә Вафина, Нурфия Закирова, Лилия Гатауллина, Флёра Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова, Тәгъзимә Шиһабиева, Рәмис Гәрәев, Маргарита Лузина, Флёра Гафурова, Альбина Әхмәтова, Диләрә Максутова, Радик Вәлиев, Асия Рәхимова, Эльвира Камалова, Равил Гәрәев, Элеонора Җамалиева, Ләйсән Солтанова, Гөлнара Галиева, Люция Сөләйманова, Рәзилә Хәйретдинова, Наил Кадыйров, Лилия Вагыйзова, Илгизә Сабирова, Ләйсән Зарипова, Гөлия Сәлахова, Алинә Хәбибуллина.*

Туфан
Миңнуллин

# «ӘЛДЕРМЕШТӘН ӘЛМӘНДӘР»

Әдәбиятта һәм сәнгатьтә, кешелек дөньясының нинди генә формаларга кереп яшәвенә карамастан, беркайчан да искерми, актуальлеген югалтмый торган темалар бар. Мәхәббәт һәм Нәфрәт, Яхшылык һәм Явызлык, Яшәү һәм Үлем. Борынгы заманнардан алып бүгенге көнгәчә бер генә язучы да бу темаларга кагылмыйча үтә алмый. Мин дә, табигый, аларны читләтеп уза алмадым. Яшәү һәм Үлем турында язучы буларак, ныклап уйланырга иң якын кешеләрем – эти белән әнинең бер-бер артлы үлеп китүләре дә этәргеч булды. «Кеше нигә туа да, нигә бик тиз генә үлеп китә соң әле?» дигән, беренче карашка беркатлы булып тоелган сорау туктаусыз борчып йөрде мине.

Ул сорауга җавапны һәр язучы үзенчә эзли торгандыр, күрәсең. Мин исә җавапны үзебезнең авыл кешеләреннән эзләдем. Шул чакта бер кызыклы ачыш та ясадым шикелле. Мин белгән агайлар, бабайлар, тормышлары җиңел булмаса да, яшәү дәртен югалтмаучылар иде. Үлем турында да алар көлебрәк сөйлиләр иде.

Әниемнең өлкән абыйсы (без аны Яшь бабай дип йөртә идек), мәсәлән, үлемнең табигый, котылгысыз бер нәрсә икәнен күз алдына да китерми иде. Аныңча, кеше үлемсез, мәңгелеккә яратылган зат иде. Авылда тегеяки бу кеше вафат булса, Яшь бабайча, ул очраклы хәл генә иде. «Үлә торган кеше түгел иде Вафа абзый, кызыл борычны күп ашап, үңәчен яндырып кына харап булды, Касыйм салкын аракы эчеп, үпкәсенә суык тидермәсә, мәңге яшисе иде»,– дип, һәр очракта үлүченең үзен гаепле итеп калдыра иде.

Яшәүнең тәмен белеп, кызык итеп яшәде Яшь бабай. Картая белми, дип әйтәләр иде аның турында. Туганнары ул сүзне ачуланыбрак, бүтәннәр шаяртып, сокланып һәм яратып әйтәләр иде. Туксанга аз гына җитмичә дөнья куйды Яшь бабай. Инде үлем чире эләгеп, бу дөньядан китәчәген сизгәч тә, анда баруга үзенчә әзерләнгән ул. «Мине кәфенгә урасагыз да, кысып бәйләмәгез, кәфен өстеннән җылы юрган белән төреп, яшьшиккә салыгыз»,– дигән. Яшьшикне исә иркен итеп, «борылып ятарлык» итеп, үзе эшләп калдырган.

Картая белмәүчеләрдән тагын бер бабайны күздә тоттым мин «Әлдермештән Әлмәндәр»не язганда. Гыйльми бабай иде ул. Туксаннан узды шикелле. Җыен юк-барны сөйләп кеше көлдерүче әкәмәтрәк кеше иде инде. Аның юк-бар сүзләрен бөтенебез дә рәхәтләнеп тыңлый идек. Чөнки ул сөйләгәннәрнең төбендә мәгънә ята иде.

Бервакыт Гыйльми бабай әкрен генә Инеш тавыннан менеп бара иде. Исәнләштем.

– Кая юл тоттың, Гыйльми бабай? – дим.

– Хәлиуллаларга менеп барам әле, – ди бу. – Тик тауга каршы менүе авыррак, олан,

Газраил чалбар балагына асылынган, – ди. – Аның каравы, өйгә кайтканда, тауга түбән төшәсе, анда инде элдертәм генә, Газраил елап артта калачак, – ди.

Мәхмүт бабай бар иде тагын, Минһаҗ бабай...

Үлем – куркыныч нәрсә. Ул үзе белән шаярганны яратмый. Әмма аңардан бик үк өркеп китмәүчеләрнең дә барлыгы язылачак пьесаның юнәлешен, жанрын билгеләде. Ул, әлбәттә, комедия булырга тиеш иде. Әҗәлнең үзен дә кеше кыяфәтенә кертеп, сәхнәгә чыгарырга кирәк санадым. Күрсеннәр кешеләр, әллә ни явыз түгеллегенә ышансыннар. Үлем турында түгел, Яшәү турында уйлансыннар. Югыйсә кайвакыт япь-яшь кенә берәүне тыңлап торасың да, аның туктаусыз зарлануыннан, шыңшуыннан яшисе килми башлый. Ачу кабара, бетсәң бет инде, дип, Әҗәлне чакырып китерәсе, «Әҗәл агай-эне, алып кит әле шушы елак бәндәне, яшәүнең ямен бозып йөрмәсен», дип әйтәсе килә.

Менә шуңа күрә дә әсәрнең үзәгендә үлемсезлек символы булган туксан бер яшьлек Әлмәндәр торырга тиеш иде.

Комедиянең исеме очраклы түгел. Борынгы татар авылларының исемнәреннән алынган: Әлдермеш – Биектау районындагы авыл. Әлмәндәр – Апас районында. Алар, билгеле, татар кешесенең исемнәре.

Татар дигәннән, әсәрдә Әлмәндәрнең үлемсезлеген милләтебезнең үлемсезлеге итеп тә күрсәтү максаты бар. Тамашачыларның сизгеррәкләре игътибар итә дә: «Бер мең дә биш йөз илленче номер әҗәлне Газраил янына җибәрегез», – дигән реплика бар. Бүгенге көндә булса, әлбәттә, әҗәлгә бер мең дә биш йөз илле икенче санын бирер идем. Әсәр 1976 елда язылды, ул заманда 1552 санын кычкырып әйтсәң, пьесаның сәхнәгә чыкмый калуы бик мөмкин хәл иде.

Комедия язылып бетте. Һәм мин аны бик тиз яздым. Унике көндә. Ул чакта Мәскәүдә югары курсларда укый идем. Минем белән бергә укучы шагыйрь Зөлфәт: «Туфан Абдуллович халтурщик, унике көндә пьеса язып ыргытты», – дип көлеп тә йөрде.

Әсәрне беренче тапкыр ниндидер уңай белән Мәскәүгә килгән язучыларга укыдым. Ошаттылар. Фикер алышуда кызыклы, файдалы киңәшләр дә бирделәр. Татарстан мәдәният министры урынбасары, мәсәлән, Әлмәндәрне Социалистик Хезмәт Герое итәргә кирәк түгелме, дигән киңәш тә бирде. Ярый әле, кирәк дип өздереп әйтмәде. Начальство сүзенә буйсынып, Әлмәндәрне Социалистик Хезмәт Герое итсәм, үлемсез Әлмәндәрне үз кулым белән үтергән була идем.

Дөресен әйтим, язганда һәм язып бетергәч тә, комедиянең болай ук популяр булачагы башыма да килмәде. Соңыннан Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә күргәч кенә, кара, ничава әйбер язылган икән, дип сөенеп куйдым.

*1993*



**Диләвәр ОСМАН,**
«Йолдыз» кырымтатар әдәби-нәфис журналының
баш мөхәррире, Кырым Республикасының атказанган
сәнгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган
мәдәният хезмәткәре

*«Казан утлары» үзенең данлы юбилеен билгеләп үтә. Бер гасырга сузылган юлны үтү һәр басмага да язмаган. Иң мөһиме шунда, бу юл нинди озынлыкта гына булмасын, «Казан утлары» берниндн сынауларга да карамастан, еллар һәм юллар аша татар сүзе һәм әдәбиятының байрагын лаеклы алып бара, үзенең әхлакый идеалларына, максатларына тугры булып кала. Үз юлында аның бәрәкәтле нурлары планетабызның төрле төбәкләренә таралып яшәүче бөтен татар дөньясын яктыртып тора, бу дөньяны берләштерә, аңа төрле яклап хезмәт итә һәм саклый. Әгәр Исмәгыйль Гаспралының Бахчасарайда чыгарган (1883-1918) «Тәрҗеман» газетасын шул заман төрки дөньясының көзгесе дип атасак, «Казан утлары»н, һич арттырусыз, татар әдәбиятының һәм мәдәниятенең көзгесе һәм энциклопедиясе дип әйтә алабыз. Йөз ел эчендә журналның бер меңнән артык саны дөнья күрде. Моны төрле чорларны, вакыйгаларны, тарихның кискен борылышларын, иң мөһиме – татар халкының әдәби әсәрләрдә чагылыш тапкан язмышын һәм бик җиңелдән булмаган үткән юлын чагылдырган меңнән артык китап дип санарга була. Журнал – Казан ханлыгының үсешен һәм һәлакәтен күргән, күп җиңүләр һәм җиңелүләр кичергән, азатлык юлында рухы ныгыган халык тормышының елъязмасы. Халык авыз иҗатында, әкият һәм риваятьләрендә, Кол Гали, Тукай, Дәрдемәнд һәм барлык татар язучыларының әсәрләрендә җырланган бу рух «Казан утлары» журналының данлы юлын тәшкил итә. Шулай ук Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете мең еллык Казанның изге символлары булып тора; «Казан утлары» журналы да Казан тарихында, һичшиксез, шундый ук урынны били. Төрле елларда журналны җитәкләгән баш мөхәррирләр, коллектив, редколлегия әгъзаларының тырыш хезмәте белән барган йөз еллык юл артта калган. Аларның һәркайсы журнал яшәсен, әдәбиятка хезмәт итсен, алга барсын өчен үзенең хәленнән килгән барлык эшне дә намус белән башкарган. Журнал тарихының бу чоры татар әдәбияты тарихына алтын хәрефләр белән язылып куелачак һәм бу көн алдагы йөз еллык өчен яңа эстафетаны ачачак.*

*«Казан утлары» редакциясе коллективын, язучыларны һәм татар җәмәгатьчелеген журналның 100 еллык юбилее белән чын күңелдән котлыйм!*

*Балкый «Казан утлары»,*
*Күзгә күренмәс уклары.*
*Богауланса куллары,*
*Яңгырар саф җырлары.*

*Кырымда балкый «Йолдыз»,*
*Ул да чәчә нурларын.*
*Казан, Кырым улларының*
*Бергә булсын юллары!*

# Мөдәррис Әгъләм

## Хәерле юл сүзгә

Казанымнан автомашинада
Китеп барам. Чагылып кала күзгә
Ерак юлга китүчеләр өчен
Язып куйган: «Хәерле юл сезгә!»

...Сары чәчен иңнәремә салып
Назлы кызлар сыман минем тездә
Көз утыра. Уйланулар чәчеп
Ул да китәр: «Хәерле юл көзгә».

Ә без һаман юлда, сәяхәттә.
Ил юлында кала безнең эзләр –
Әнә шулай бер китәрбез дә без
Һәм кайтмабыз, тол калырлар көзләр.

Тол калырлар җәйләр, кышлар, язлар,
Без үтелгән юллар тол калырлар...
Ил уллары хезмәтләрен илгә
Бирерләр дә китеп югалырлар.

Кайтыр алар тугры Тукай булып,
Йә кызыллык булып гамьсез йөзгә...
Шуңа бүген минем күкрәгемдә
Теләкнамә: «Хәерле юл сүзгә».

Сүзләрең хак, кыска булган чакта
Гомерең озын, барыр юлың озын,
Киләчәккә карап китеп барам,
Без барасы офык: коммунизм.

Әйтер сүзләр безнең тузга язган.
Безнең йөрәк әйтерсең лә туздан,
Бөгәрләнеп кысыла, шундый кызган,
Гомере учак тирәсендә узган.

Көн килер дә йолдыз атылгандай
Күкрәк читлегеннән аерылыр ул.
Һәм яңгырау кайтыр еллар кичеп,
Бер яңгырау кайтыр: «Хәерле юл...»

Озатырлар автомашинада,
Йә күтәргән хәлдә, яки атта...
Тузга язган сүзләр генә калыр –
Дөрес сүзләр генә, безнең хакта.

Ерак әле аңа, канатларың
Әллә ничә тапкыр каерылыр...
«Хәерле юл» бөтен хөр акылга,
Тузга язган сүзгә хәерле юл!

*«Казан утлары». 1972 ел, 5нче сан.*

# Зөлфәт

## Болын

Монда, имеш, яулар җир селкеткән,
Юк ителгән, имеш, халыклар.
Җир астында калган иске нигез,
Талир тәңкә, көмеш савытлар...
Төкерми дә вакыт! – Юа, күмә –
Эзләп кара җилне даладан!
Безнең язмышларны сулар юган,
Туфрак күмгән, ялкын ялаган.
Шушы кырдан мәгърур ханнар үткән,
Кабиләләр үткән, күченеп.

Бүген анда «Алга» колхозының
Ат көтүе йөри чемченеп.
Сабан туйлар гөрелтесе сеңеп,
Бик тирәндә калган нигездә,
Алмачуар бия, койрык селкеп,
Тыныч кына колын имезә.
Вакыт күмгән, һаман күмә тора,
Ул куймаган әле көрәгеен.
...Нигезләрдә яткан авыр ташлар
Кысылгандай кысыл, йөрәгем.
Бу төбәктә кайсы кабиләләр,
Нинди утлар ягып җылынган?
– Мин ял итәм – яңа гасыр улы! –
Болонья плащым җәеп болынга...

*«Казан утлары». 1970 ел, 7нче сан.*

## Фәннур Сафин

### Ил бәйрәмен котлап

Нинди чүлләр кичеп килдең, күңел,
Кай тарафка синең юл бара?
Яңа туган гүзәл кыйсса кебек
Әйтер сүзең бармы дөньяга?

Тынлыкмы син, тыныч сабырмы син,
Тау елгасы сыман ярсумы?
Гамьсезме син, ихлас көрәшчеме,
Нәрсәгә дә булса каршымы?..

Яшисеңме – ягъни кайныйсыңмы
Уртасында җилле заманның?
Хисләреңне төнге утлар итеп
Чөяргәме җирдә яралдың?

Тоташ моңмы, серле сараймы син,
Җырлаганда чыккан тавышмы?..
Җир өстенә йолдыз атылганда
Йөрәк тоткан айлы сагышмы?

Мин җир буйлап киләм сине уйлап,
Акыл һаман сине кайгырта.
Киләм сиңа, түргә узам. Барлыйм –
Йөргән кебек гаҗәп бай йортта.

Җан бездән дә алдан тоядыр ла,
Ашкына гел туар таңнарга.
Ил бәйрәмен иңнәр күтәргәндә
Күңелләрдә Сөю яңара!

*«Казан утлары». 1982 ел, 5нче сан.*

## Роберт Миңнуллин

### Халык шагыйрьләре

*Сибгат ага Хәким истәлегенә*

Халык шагыйрьләре берәү, икәү...
Күпме алар безнең халыкта?
Халыкныкы булалмаганнар бар.
Тарихларда аты калып та.

Әй, татарның Алып шагыйрьләре!..
Һәркем сыймый андый калыпка.
Халыкныкы алар! Шагыйрьләрнең
Калганнары керә халыкка.

Халык шагыйрьләре үзләре дә
Халык арасыннан калыккан.
Әллә шуңа, читтән караганда,
Аерып та булмый халыктан.

Сибгат Хәким буйлы гына алар,
Хәсән Туфан төсле чал, чандыр.
Тукай гына чалармаган килеш,
Япь-яшь килеш киткән кайчандыр.

Кайгы килсә, алар үз халкының
Күз яшьләре белән язгандыр.
Кан белән дә, яшь белән дә язу
Алар язмышына язгандыр.

Күз яшьләре сүз яшьләре булып
Җырга тамган андый елларда.
Ул яшьләрне кемнәр сөртте икән,
Ярамаганда да еларга?

Ә аларны исән чакларында
Кадерләрлек юкса, санларлык.
Болай да бит алар өчәү, дүртәү...
Бармак белән генә санарлык.

Халык шагыйрьләре китә тора –
Кемнәр килер, кемнәр танылыр?!
Исән булсын халкым! Халкы булса,
Шагыйрьләре аның табылыр!

*«Казан утлары». 1997 ел, 5нче сан.*

# Харрас Әюп

## Исәнлек

Кичләремә: «Хәерле кич!» – диләр,
«Исәнмесез!» – диләр иртәмә.
Көннәремнән хәл белешә дөнья.
Уйга салып йөртә-йөртә дә...

Һәр теләге ләкин кабул булмас,
Хәл белүдән дәрман табылмас:
Илгә-җиргә тоташ ирләр җаны
«Сау бул!» – диеп кенә сау булмас.

Ир саулыгы – ил тынычта гына,
Бәхет белән көннәр хәерле;
Исәнлекме – үксез сабыйларның
Күз яшьләре телсә бәгырьне?!

Явызлыклар өстен чыкса әгәр,
Егылып калса сафлык, тапталса...
Җинаятьтер – җирдә хаксызлыкны
Күрә торып, җаның сау калса!

«Исәнме?» – дип хәл сорыйлар дуслар,
Дөрес булыр икән ни дисәм?
Илләр имин чакта – бәхетле мин,
Бәхет барда җирдә – мин исән!..

*«Казан утлары». 1983 ел, 11нче сан.*

# Разил Вәлиев

## Авылда туй...

Киереп ач урыс капкаларны!
Керсен кунак безнең өйгә дә.
Авылда туй. Тракторчы егет
Сыер савучыга өйләнә.

Урамнар тар бүген егетләргә,
Җыр агыла басу ягына.
Бии бабай. «Кеше көлдермә», – дип,
Еламсырап әби ялына.

Коеларның суы эчелеп беткән.
Колхоз аты баткан күбеккә,
Иске җырлар яңа булып яңгырый:
Тургай кунганмыни күреккә!

Авылда туй. Гап-гади бер егет
Гап-гади бер кызга өйләнә.
Машиналар тынып калган бүген...
Атлар чаба, атлар... әл-лә-лә!

Калым да бар, бирнә дә бар туйда...
Искелек бит бу хәл! димә лә:
Егет батырлыгы  калым булса,
Кызның матурлыгы – бирнәгә.

Чаба торгач тезгеннәрне өздек,
Тик һаман да җырлар өзелми!
Гасырлардан күчә-күчә килгән
Кыңгыраулар илдә зеңгелди.

Урамнарны иңләп шатлык килә,
Дус сөенә, дошман көенә.
Каерып ач урыс капкаларны!
Керсен бәйрәм дуслар өенә.

*«Казан утлары». 1971 ел, 11нче сан.*

# Наис Гамбәр

***

Бу өйдә күптәннән яшәми берәү дә;
Капкасы – йозаклы. Коймасы – терәүдә.
Тик һәр иртә бу юллар
Себерелгән, көрәлгән булырлар.
Кешеләр ничектер елмаеп
Үтәләр аларның турыннан:
«Һай, үзе дә сиксәндә,
Гаптери кайчан бу эшеннән тыелыр:
Дөнья бит – кары да явылыр.
Канат та, яфрак та коелыр».
... Кемнәрдер: «Җүләрдер!» – диделәр.
Кемнәрдер: «Әҗерен...» – диделәр.
«Җүләрме?», «Әҗереме?» – бер Хода беләдер,
Алар бит күршеләр иделәр.

*«Казан утлары». 1999 ел, 10нчы сан.*

# Лена Шагыйрьҗан

## Ул чакта

Алда нинди олы бәхет булган,
Кем уйлаган аны ул чакта,
Яңакларны куеп яңакларга.
Сөйләшербез диеп шул хакта.

Алда нинди шатлык торган безнең,
Хыялландык микән ул чакта,
Утырырбыз диеп чыбык ташлап
Икәү бергә яккан учакка...

Алда олы бер юл көткән икән,
Атласак та төрле сукмактан.
Йөрәкләр дә бергә типкән икән,
Тоймаганбыз гына ул чакта.

Безне алга бер моң дәшкән икән,
Килде микән башка шул чакта,
Кушылырбыз диеп, бер җыр булып,
Икебез ике ташкын булсак та.

*«Казан утлары». 1973 ел, 6нчы сан.*

## Зиннур Мансуров

### Малай чакны искә төшергәндә

Бар иде кочып караган,
хәтта бар иде үпкән...
...Без озатып йөргән кызлар
инде тормышта күптән.

Өзелдең безне бәйләгән
Син, мәхәббәт зынҗырым,
Беренче садә шигырем,
Минем беренче җырым...

Күрсәм, ни дип дәшим сиңа?
«Саумы»,– диярмен бары...
Сөяргә өйрәтеп киткән.
Миңа язмаган ярым.

*«Казан утлары». 1972 ел, 5нче сан.*

## Госман Садә

### Яңгыр

Яшьнәде дә күкрәп, җәйге яңгыр
Китеп барды таулар артына.
Яңгырдан соң гөлләр уяндылар,
Бер кыз чыкты капка алдына.

Яңгыр үтте кинәт кенә шаулап,
Тын бакчалар калды яшәреп.
Егет китте, китте ерак юлга.
Кыз күзләре калды яшьләнеп.

Күкрәүләрме аны тетрәттеләр,
Шук җилләрме кагылып үттеләр;
Тамчылармы әллә елатканчы
Керфек очларыннан үптеләр.

*«Казан утлары». 1972 ел, 9нчы сан.*

## Рашат Низами

### Чаган

Юл кырына төште орлык,
Үсеп чыкты яшь чаган.
Канат төрткән кош кебек ул
Омтылды өскә табан.

Карлы-бозлы бураннарның
Килер әле ничәсе!
Күпме язны каршылыйсы,
Күпме җәйне кичәсе.

Күпме божра ишәйтәсе,
Күпме яфрак коясы,–
Каршында тора чаганның
Башланмаган дөньясы...

Юл буеннан үтеп тора
Җәяүлеләр, атлылар.
Чыбыркы сабына диеп,
Яшь чаганны... чаптылар.

*«Казан утлары». 1974 ел, 11нче сан.*

Марсель
Галиев

# ХЫЯНӘТКӘ – КЫЯМӘТ

ЭССЕ

Курай тавы башында офыктан күтәрелеп килгән галәм шәме – Кояш ягына карап, өч баһадир тора. Уртада – ак атка атланганы – Билге хан. Аның уң ягында – алмачуар атны иярләгәне – Төньюкук. Сул ягында – күк атның өзәңгесенә басканы – Күл тәгин.

Өч иләмән ир үз халкына карата акыл ияләре тарафыннан әйтелгән төрле фикерләрне искә төшереп, гәпләшеп тора. Сүзне Билге хан ала:

– Түрек – диңгез кабырчыгындагы энҗе кебек. Кайчан ул кабырчыкны ярып чыга, шул чакта ул патша таҗларын бизәрлек бәһасез кыйммәткә әверелә, дигән Кытайның бер акыл иясе.

Кытайда укып, тәрбия-белем алган Төньюкук, һәрвакыттагыча, әйтеләсе фикеренең күләгәле-караңгы ягын сайлый:

– Ишеткәнегез бармы икән, безнең түрек халкы турында кытайлар ни ди? «Алар, агулы бөҗәкләр кебек, бер-берсен кыралар», – диләр.

– Үзләре шуңа котыртып яшәгәч, алар белми әйтмиләрдер, – ди Билге хан.

– Аларның безнең гаскәр турында болай дип әйткәне дә бар, – дип, сүзгә кушыла Күлтәгин: «Түрекләр – бүреләр. Алар – төп тамыр. Ә калган кавемнәре – яфраклы ботаклар»...

Түрек иленең иминлеге шушы өч баһадир иңендә утыра. Билге хан, Күлтәгин һәм Төньюкук – бу өч берлек Кытай белән ике арада гасырлар буена бер кабынып, бер сүнеп торган бәрелешләрне туктатып, тыныч сулыш алырга җай бирергә, тирә-юньдәге кандаш-кардәш кабиләләр белән уртак телгә килергә тиеш. Шулай булмаса, түрек иленә яшәү юк...

Көнбатыш түрек каганаты Идел-Урал, Кавказның төньягын, Кубан даласын, Кырымны һәм Босфорга кадәрге җирләрне биләп, Византия белән килешү төзеп, Иранга каршы сугышып яткан ил иде. Көнчыгыш чиге – Әму-Дәрьяның урта агымына чаклы җәелгән иде. Атилла һуннарыннан чәчелеп калган халык – үтүргур, уннаһундур, анагур кабиләләрен берләштереп, нәсел шәҗәрәсе Атиллага тоташкан Кубрат хан Болгар дәүләтен төзи. Каспий ярында Хәзәр каганаты төзелә. Түрек карыныннан яралып чыккан бу ике илне төп каганат та танып, Олы ефәк юлын кулда тотуда бергә килешеп, эш йөртә башлый.

Ә менә Көнчыгыш тарафта күк түрекләрнең хәле мөшкелләнеп бара. Алар үзләре нигезләгән Тан империясе, үзләре исем кушкан табгач халкы отыры көчәя, Кытай дәүләтенең төп көченә әверелә бара. Табгачлар түрекчә киенеп, түрекнең моңлы җырларына мөкиббән киткән булып, түрек аксөякләрен зур урыннарга утыртып, гаскәр башлыклары итеп куеп, аларны дәүләтчелек хәтерен оныттырып, сиздерми генә кытайлаштырып бара. Конфуций алымы белән, ягъни камчы белән түгел, ә ягымлы елмаеп буйсындыра баралар. Бөек дала кодрәтен Кытайга суырып алу табгачларның төп максаты була.

Тоньюкук тарафыннан язылган ташъязмада болай диелә: «Мәңге Күк болай диде, ахрысы: «Мин сиңа хан бирдем, Син үз ханыңны калдырып, бүтәнгә буйсындың. Шул буйсынуың өчен сиңа Күк кизәнеп, һәлак итте. Түрек халкы хәлсезләнде, көчен җуеп юкка чыга барды».

Йоллыг тәгин (Билге ханның улы) Кытайда укып-белем алган тарихчы, акын була, ул абыйсы Котлык Илтереш каган исеменнән ташка болай дип уеп калдыра: «Табгач халкы мулдан кыланып, безләргә күп алтын-көмеш, ашлык, ефәк төргәкләре бирә килде. Сүзләре татлы, байлыклары затлы иде. Еракта яшәүче кавемнәрне шулай тәмле сүзе, камкалы байлыгы белән кызыктырып, үзләренә тарттылар. Тегеләр шуңа алданып күченеп килделәр һәм кытайларча уйлау гаменә бирелделәр».

Йоллыг тәгин Кытайның гореф-гадәтләре күчмәннәр көнкүрешенә нәкъ менә матди байлыклар аша савылып керүе хакында әйтә: «Аларның җылы сүзләренә, биргән зиннәтләренә алданып, син, и түрек халкы, күпме кешеләреңне харап иттең. Мәкерле хакимнәр түрек халкына: «Кем еракта яши, аңа бүләкнең арзаны бирелә, кем якыныбызда – аңа бүләкнең кыйммәтлесе бирелә...» – дип күнектерделәр. Ә сез, сай акыллы адәмнәр, шул сүзләргә алданып, аларның якын-тирәсенә күченеп килдегез һәм күпләп кырылдыгыз...»

Шулай... Бүләкне рәхмәт ишетер өчен генә бирмиләр. Күпме түрек ире исемен алыштырып, табгач титулы алып, яугир булып, Кояш чыгышы илләренә – Маньчжуриягә кадәр, Урта Азиягә – Тимер Капкага (Дербент шәһәре) кадәр барып җитеп, Кытай данын яклап, яуларда башын салды. Әле яшәп, әле үлеп, төрле илләргә сибелеп калды.

Ниһаять, халыкта уяну башлана. Шул чорның ташка уелган язуыннан: «Мин дәүләтле халык идем. Кайда минем дәүләтем? Мин каганлы халык идем, кайда минем каганым? Кайсы каганга мин үз хезмәтемне, үз көчемне бирәм?! Аннары түрек халкы Кояш чыгышы, кояш батышы тарафына, көньякка табгачларга, төньякка – кара тайгага агылды, каһарманнары таш балбалга әверелеп калды, исеме сүнә башлады. Шул чакта Тәңре әйтте: «Юк, түрек халкы бетмәс, юк, түрек халкы корбан булмас!»

Түрекләр бердәм күтәрелеп чыгалар. Табгачлар өчен бу көтелмәгән түнтәреш була. Элеккеге әмирләр, аксөякләр ун меңлек түрек гаскәре туплап өлгерәләр. Бу, әлбәттә, миллионнар белән исәпләнгән табгач халкы белән чагыштырганда, бик аз күренә. Әмма ярсу түрекләрнең ирек даулау, хакимлекне кулга алу дәртен берни белән дә туктатырлык көч сизелми. Табгач дәүләте өчен бил бөгүдән туйган түрек халкы үлемгә әзер була:

«Үз-үзебезне бетерәбез, тамырыбызны корытабыз!» – дип, төрек халкы үз һәлакәтенә таба үзе ташлана.

Гаскәр башлыгы урынын биләгән Котлуг үзенә Илтерес каган дигән яңгыравыклы титул алып, үз даирәсенә төрекнең элекке аксөякләрен, кытай армиясендә хезмәт иткән тәҗрибәле тутуннарны туплый. Шулай итеп, 682 ел тулаемы белән гаскәрне тәртипкә китерүгә, оештыруга сарыф ителә. Төрекнең атлы яугирләре Биек кытай дивары эргәсендәге Ордостан Көнчыгышка таба урнашкан регуляр армияне таркатып, биш хәрби округны җиңүгә ирешә. Моңа уңай сәбәпләр бик вакытлы килеп чыгып тора. Беренчедән, тол калган кытай императрицасы У-хоу тәхет тирәсендә чуалыш куптара. Яраннарын асу-кисү башлана. Икенчедән, Юннан джунглиеннан алып, текә ярлы Хуанхэ елгасы, комлы Турфан даласын һәм урманлы үзәк Тянь-Шань тауларына чаклы биләгән Тибет фронтына сугышка кытайның иң көчле, иң әзерлекле гаскәре озатыла. Котлугның җиңүләргә ирешүенә шушы сәбәпләр уңай форсат бирә дә инде. Котлуг кырык җиде тапкыр яу сәфәренә чыга. «Ул дошманнарын солыхка китерде. Тезе булганнарны тезләндерде, башы булганнарның башын идерде», диелә ташъязмада.

Шул дәвердә Йоллыг тәгин болай дип яза: «Уңда (көньякта) табгач халкы дошман иде, сулда (төньякта) Баз каган әмирлегендәге тугыз угыз халкы дошман иде, кыргызлар, курыканнар, утыз татарлар, кидан һәм татаблар – барысы да безгә дошман иде».

Төрекләр өчен бик куркыныч хәл килеп туа. Баз каган Кытайга илчеләр җибәрә. Котлугка каршы бар көчләр белән берьюлы һөҗүм итәргә тиеш була: табгачлар – көньяктан, киданнар – көнчыгыштан, уйгурлар – төньяктан. Шымчылар бу хәбәрне Котлуг урдасына бик тиз арада җиткерәләр. Шул мизгелдә үк ике меңлек гаскәр туплап, Төньюкук төньякка, тугыз угызларга каршы юнәлә. Ул Баз каганнан алдарак килеп җитә, Тола елгасы ярыннан уйгур гаскәрен эшереп төшерә, исән калганнарын кылычтан үткәрә. Баз каган яу вакытында һәлак була. Шулай итеп, уйгурлар күк төрекләргә буйсынуын белдерә.

693 елда Котлуг хан дөньядан китә. Тәхет аның энесе Мочурга күчә. Ул Капаган каган титулын ала.

Төрек каганатын яңадан торгызу бик авыр бара. 709 елгы хәлне Төньюкук болай тасвирлый: «Табгач каганы безнең дошман иде. Унук каганы безнең дошман иде. Иң көчле дошманыбыз кыргызларның гаярь каганы иде. Бу өч каган берләшеп, Алтын җиренә барырга дип киңәштеләр. «Төрек каганына каршы көнчыгыш тарафка яу чабабыз. Әгәр без аңа каршы бармасак, ул безне бетерәчәк. Каган – каһарман, киңәшчесе – акыл иясе, алар безне кырып салганчы, өчәү берләшеп, яу сәфәренә чыгабыз».

Гамәлдә, төрекләр чолганышта калган була. Моннан дошманнарның башына килмәслек берәр көтелмәгән чара кулланып кына котылырга мөмкин. Акыл иясе Төньюкук башында шундый бер хәйләкәр план өлгерә. Кыргызларга һөҗүмне җәй җиткәнен көтмичә, кыш аенда оештырырга кирәк. Кыргызлар Саян кыялары аръягында, сугарулы кырлар үзәнлегендә бергә тупланып яши. Кинәттән һөҗүм итеп кенә, аларны тар-мар итәргә мөмкин. Моның өчен Саян тау кыяларының моңа кадәр беркемнең башына

килмәгән һәм кем дә аяк басмаган иң хәтәр урынын сайларга, шуннан аргы якка чыгарга кирәк. Капаган каган бу акыл җитмәслек җүләр планны кабул итә һәм гаскәр башы итеп Тоньюкукның үзен билгели.

Түрекләр далада яшәүче ас кабиләсеннән тауларда оста йөри белүче бер ирне яллап, сәфәргә кузгалалар. Тоньюкук бу мәхшәрне ташка басып калдыра: «...Ак-Тәрмел аша чыккач, стан корып, туктап алдык. Аннары атларга атланып кар ерып бардык. Аннары, иярдән төшеп, атларны тезгененнән тотып, тирән кар ерып киттек. Колгаларга таянып барып, тау сыртына күтәрелдек. Алдан яугирләр юл сабып барды. Урманлы кыя сыртларын үткәч, бик авырлык белән ун төн буена аска таба төшә башладык (дошман сизмәсен дип, төнлә генә хәрәкәт иттек). Упкынны үтеп, тау битенә килеп җиттек. Юнәлешне бутаган юл күрсәтүчене чәнчеп калдырдык. Ана елгасы буйлап, түбәнгә төштек. Атларны тезгененнән агачларга бәйләп куеп, гаскәриләрне тезеп барладык. Төнен дә, көнен дә туктаусыз атларны чаптырдык. Сөңгеләр белән юл ярып, кыргызларга йокыда чагында һөҗүм иттек».

Бу һөҗүм турында Йоллыг тәгин болай дип хәбәр бирә: «Күл тәгин байрыкларның ак атына атланып һөҗүмгә ташланды. Бер яугирне уктан атып аударды, ике ирне сөңге белән чәнчеде: башта – берсен, аннары – икенчесен. Бу орышта ул байрыкларның ак атының билен сындырды. Кыргыз ханын һәлак итеп, илен буйсындырдык».

Тоньюкук ачыклап куя: «Ханын үтердек. Кыргыз халкы каган кул астына кереп, безгә буйсынуын белдерде...»

Шулай итеп, Тоньюкукның акыллы алымы, Күлтәгиннең батырлыгы, күк түрек яугирләренең чыдам-гаярьлеге аркасында Түрек каганаты, үзен борчып торган тагын бер дошманны коралсызландыра.

Күлтәгин дүрт ел буена (711-715) карлуклар белән көрәшә. Ниһаять, ул Тамаг дигән изге тауда карлукларны тәмам җиңүгә ирешә һәм каганатка буйсындыра. Урдага кайтып җитүгә, ул төрле кабилә-ырулар арасында чуалыш купканын белеп ала. Әмма аның яудагы уңышларыннан көнләшкән Капаган каган туганы Күлтәгинне «өйдә» калдыра, тугыз угызлар белән сугышка керәсе гаскәрне үзе җитәкли. Шул мәлдә карлуклар Алтайдан ике төркем гаскәр китертеп, хан урдасына һөҗүм оештыра. Күлтәгин аз санлы яугирләр белән урданың иминлеген саклап, андагы хатын-кызлар һәм бала-чагаларны әсирлеккә эләгүдән йолып кала. Ташбасмадагы язу бу вакыйганы кыскача гына әйтеп бирә: «Ул тугыз баһадирны чәнчеде, урданы бирмәде».

Бу вакытта Капаган каган тугыз угызларны җиңеп, байрык кабиләсенә һөҗүм башлый, Тола елгасы ярында аларны тар-мар итә. Канәгать калып, горур уйланып кайтып барышлый, урманга килеп кергәнен сизми дә кала. Агач артына яшеренеп көтеп торган байрыклар каганны ат өстеннән тартып төшереп, башын чабып өзәләр. Каганның башы Кытай илчесе аша Тан императорына озатыла (һәммә адым шулай Кытайның күңелен күрү өчен эшләнә).

Күк түрекләр урдасында тәхеткә кемне утыртырга дигән сорау калка. Варислыкка тугры калган очракта, сәләтсез кешене куярга кирәк, бу катлаулы чорда моңа барып булмый, шунлыктан, Күлтәгин хәрби түнтәреш

ясап, яңа титул биреп, тәхеткә үз туганы – Билге ханны утырта. Гадәттә, илбашы алмашынганда, тәхет тирәсендә була торган асу-кисүләр Капаган каганның бер-ике якынына гына кагыла. Билге хан ташъязмада бу хакта болай ди: «Мин хан булып утыргач, үзләренең кырыласын көткән түрек бәкләре һәм халык өскә (тәхет ягына) тыныч күз белән бакты»...

Билге хан моңа кадәр кыерсытылып йөргән акыл иясе Тоньюкукка бәк тархан титулын кайтара һәм дәүләт киңәшчесе итә. Шулай итеп, Түрек каганаты Билге хан, Күлтәгин һәм Тоньюкук берлегендәге өч баһадир кулында алтын бүре башы төшерелгән данлы байракны югары күтәрә.

Түрек илендә яңа җилләр исә башлый. Каты бәгырьле Капаган каганга үч итеп, кытай ягына күчеп киткән телес кабиләләре кире кайтып төшә. Билге хан шулай ук, җир-суларын ташлап китеп, табгачларга барып кушылган тугыз угызларга чакыру җибәрә: «Табгач ханы аларны җинаятькә этәрде. Табгачларда аларның исеме һәм даны юкка чыкты», – ди ул. Шулай итеп, Билге хан кардәш ыруларны берәмләп, үз канат астына туплый башлый.

Ясмык шулпасына алданып, иленнән йөзен борып киткәннәрне ул гамәлгә ашар максатка юнәлтә: Каганатны торгызу! «И түрек халкы, син теге якка юнәлсәң, һәлак ителәсе упкын чигенә басасың. Атакөн җирендә калсаң, син үз дәүләтеңне корып, тук яшәрсең». Һәм ул Котлыг каганның әйткәнен искә төшерә: «Каган булгач, мин үлеп баручы халкымны аягүрә бастырдым. Юксыл халкымны бай иттем, аз санлы халкымны күп санлы иттем».

Кытай империясе белән үзара тынычлык урнаштырмый торып, күп нәрсәгә ирешеп булмаячагын Билге каган яхшы аңлый. Шуңа күрә, тышкы сәясәтне бераз үзгәртеп җибәрергә була. Императорга шундый мөрәҗәгать белән чыга: «Син Күк улы буларак, миңа ата бул», – ди. Император моның белән килешә.

722 елда Билге каган, Тоньюкук һәм Күл тәгингә Кытайдан чакыру килә. Тайшан тавында, император корбан чалу бәйрәме үткәрәчәк икән, шул тантанада катнашуларын үтенеп, зурлап хат җибәрә.

Тоньюкук белән Күл тәгинне хан чатырына чакырталар. Ни хикмәт, хан аларны үзе ишек төбенә чыгып каршы ала. Ишек турыннан өскәрәк гөмбәзгә беркетелгән, самшит агачыннан үз зурлыгында ясалган өч бөркет сынына ымлап, ул игътибарны шунда юнәлтә. Бөркетләр шулкадәр чын итеп ясалган ки, хәтта асылташ куелган күзләренең зәһәр чәчеп янып торуы да, тере ут шикелле, йөрәкне чагып ала. Бөркетләрнең уңдагысы яңа килеп кунган, әле канатларын җыеп бетереп кенә килә. Уртадагысы тыныч кына утыра. Сулдагысы менә-менә очып китәргә җыенып, канатларын киерергә чамалаган.

Билге хан, бөркет сыннарына сокланып каравыннан аерыласы килмичә, сорап куя:

– Шушылай утырган өч бөркетне бер ук белән, бер атуда алып буламы?

Күлтәгин әле уңга, әле сулга чыгып, бөркетләрнең торышын җентекләп карый да:

– Дөрес ноктадан торып атсаң – була, – ди.

– Әгәр угың кытай тимереннән булса, – дип өсти Тоньюкук.

Парчалы ефәк белән каймаланган чатыр эченә кереп, калын фарсы

келәменә батып кергән кыска тәпиле өстәл кырыена түгәрәкләнеп, алар касәдәге салкын кымызны уртлый-уртлый гәпләшеп ала. Билге ханның баягы мизгелдә гөмбәздәге бөркет сыннарына ишарәләп бирелгән соравы карынында җавабы да тибенеп ята. Өчесе бер карарга килделәр. Император бәйрәменә бармаска. Өчебезне дә тотык итеп, зинданга ташлаячаклар. Түрек каганаты ул чакта башсыз калачак, дигән уртак фикергә киләләр.

– Кытайларны, үзләре төзегән диварлар артыннан бу якка чыгармыйча, һуннар ничә гасыр тотты. Соңыннан алар да, түзә алмыйча, Көнбатыш тарафка юл алды. Кытайлар отыры көчәя, ә без, үзара орышып, таркала барабыз. Инде безнең кардәш ыруларыбыз Көнбатыш тарафта каганатлар төзеде. Ә безгә нишләргә? Кытайны үзе төзегән диварлар аша безнең якка – Алтай-Себер-Урта Азия далаларына чыгармыйча ничек тотарга? Әгәр без – Кытайның һәр бөртек керфеге селкенүдән дә эчтә нинди фикер уянганын тоя белмәсәк, кытайның сиңа эчкерсез кыяфәт чыгарып елмаеп торган арада итәк астыннан хәнҗәрен кайрап алуын сизмәсәк, алар табынган аждаһаның авызы көлеп түгел, ә сине кабып, чәйнәп йотарга дип ачылганын аңламасак... Без кем булабыз? Ак бүре каныннан яралган гаярь түрекләрме?! Әйе, без ак бүре каныннан яралганбыз. Бүре – усал хайван. Бер ярсып ала да тиз тына. Әмма бүре, үзенә тиң дошманын егып салганнан соң, аны бөтенләй ботарлап юк итми, өстенә менеп чәпрә итә дә ташлап китә. Ә дошманы, савыкканнан соң, кабат аягына басып, тагын да явызрак дошманга әверелеп, кире кайтасын уйламый. Без – дала халкы, артык беркатлы, ышанучан, гадел халык. Бу сыйфатлар белән көчле дәүләтне озакка төзеп булмый. Ә Кытай – башка... Конфуций өйрәтмәләрен канына сеңдереп яшәгән бу халык, үз дошманын яратып үтерә белә, яисә кытай булып өлгергәнен сабыр гына көтә. Күз алдыбызда бит, күпме кавем-кабиләләр кытай карынында йотылып, үз иманын җуйдылар. Кытайлар сан ягыннан бүгенге чорда илле миллионнан артып китте. Дөньяда андый күп санлы халык тагын бармы? Юк, әлбәттә...

Саргаскәр Күлтәгиннең аягүрә басып, халык каршында сөйләгән кебек чыгышын Билге хан белән Тоньюкук башларын иеп тыңладылар. Хан чатырының ачык ишеге аша еракта, таулар артында, офык алланып бара. Әллә нинди кичке моңсулык тымызык кына иңеп килә. Түрек иленең бәгыреннән өзелгән кан тамчысы булып, Кояш бүген дә мәңгелек Саян тау итәгенә тамып төште...

* * *

731 елда кырык җиде яшьлек Күлтәгиннең үлеме бөтен түрек дөньясын тетрәтә. Ачы хәбәр Алтай-Саян кыяларын үтеп, Хинган тауларына, Тарбагатай далаларына, Урал сыртлары аша үтеп, Идел буйларына, Кубан далаларына кадәр барып җитә. Бу көтелмәгән хәбәрдән дошманнар дошманлыгын онытты, карендәшләр карендәшлеген искә төшерде, яудашлар яудашлыгы белән горурлану кичерде.

Төрле ил-җирләрдән кайгы мәрәсименә җыелдылар. Кытай императоры, кайгы уртаклашуын белдергән язма мөрәҗәгатен биреп, рәсми илчелек җибәрә. Кидан һәм татабилардан махсус сыгытчылар (җеназа вакытында җыгълаучы) килә. Табгач каганы исеменнән килгән тәхет яраннары йөге

белән алтын-көмеш әйберләр бүләк итәләр. Тибет каганы үзенең баш вәзирен җибәрә. Кояш баешы тарафыннан: Сәгъди, Берчекәр һәм Бохара иленнән – тарханнар, унук халкыннан һәм түргеш каганыннан мөһер саклаучылар килә. Җунгариядән басмал, Минусин үзәнлегеннән кыргыз, Алтайдан кыпчак вәкилләре җыйнала.

Күлтәгингә багланган Төрбәне төзергә дип, табгач каганы ташчылар, бизәк төшерүчеләр, ташка чокып яза белүчеләр, мигъмарлар, таш сын ясаучы осталар, рәссамнар, бина салучы һәм түбә ябучылар җибәрә. Бизәк кисүче осталарны тойгуннар, әлтәбәрләр алып килә.

Архан елгасы буенда, түбәҗирдә эш кайный. Бу четерекле эшне оештыру Йоллыг тәгин җилкәсенә төшә. Төньюкук белән икесе язган күк түрекләр тарихы зур ташларга кытайча һәм түрекчә рун хәрефләре белән күчерелергә тиеш. Моңа Йоллыг тәгин аеруча зур игътибар бирә. Түрекләрнең шанлы һәм данлы тарихы шушы ташларда киләчәк буыннарга барып җитәчәгенә ул шикләнми. Әтисе Билге хан исә төзелешнең казу, таш кисү кебек тупас көч сорый торган өлешләрендә күзәтчелек итә. Төньюкук язуларның, түрекчәсенең дә, кытайчасының да хәрефен хәрефкә дөреслеген тикшереп бара.

Ниһаять, 732 нче Маймыл елында, (27 июльдә) Күлтәгингә багланган Төрбәне ачу тантанасы була.

Башта төрле илләрдән килгән кунакларга Төрбә мәйданын күрсәтеп чыгалар. Зурлыгы сиксәнгә кырык адымнар булыр, тирән ур белән уратып алынган. Бизәкләп эшләнгән төп капканың як-ягында бөтерелеп торган горур мөгезле, мәрмәрдән эшләнгән ике тәкә бер-берсенә карап тора. Капкадан ясмык кебек кенә вак ташлар тигезләп җәелгән юл керә. Ишегалды уртасында саф сулы кечкенә күл. Яңгырлар вакытында күл суы ташып чыкмасын өчен ярга батырып, кызыл балчыктан яндырып эшләнгән торбалар салынган. Күлнең аргы ягында чирәп түбәле чатырда бик зур мәрмәр ташбака сыртына  язулы ике мәрмәр таш беркетелгән. Бер ташка түрекчә, икенчесенә кытайча язылган. Диварлары акшарланган чатырдан чыгуга юл сине гыйбадәтханәгә алып бара. Юлның як-ягында Күл тәгин яраннары һәм ялчыларының табигый зурлыктагы, билгә тиклем коелган сыннары тантаналы сакка куелган шикелле тезелеп тора. Гыйбадәтханә эчендәге диварлар, кызыл бизәкләр төшерелеп, җирлеге ак төскә манылган. Түбәсе чирәптән, түшәм яны энҗе ялтыравыгы белән каймаланган. Стеналарга балчыктан яндырып эшләнгән аждаһа сурәтендәге битлекләр эленгән. Храм эчендә корбан чала торган һәм учак тергезә торган урын ясалган. Түрдә Күлтәгин һәм хатынының билдән югары өлешенең мәрмәрдән уелып эшләнгән сыны куелган. Күлтәгингә маңгай турына бөркет сурәте төшерелгән биш чатлы таҗ кидерелгән. Күлтәгин бераз кысыграк күзле, бүртмәч йөзле итеп сурәтләнгән. Хатынының нык ихтыяр көченә ия зат икәнлеген кысылган иреннәреннән чамалап була.

Цайдам тоз күлләреннән бу һәйкәл урынына чаклы өч чакрымнар бардыр. Менә шул арага ике йөз балбал тезелгән. Беренче карашка кеше биеклегендәге бу балбаллар кулларын кушырып, әкрен генә атлап барган адәми затлар шикелле тәэсир калдыра.

Шушы кадәр эшне башкарып чыгуыннан  һәм килгән кунакларның да

бу тамашаны күреп мәмнүн булуыннан Билге хан канәгать кала. Ул үзенең улы, мактанычы, варисы, тарихчы, акыл иясе һәм шагыйрь Йоллыг тәгинне югары дәрәҗәдәге кунакларга күрсәтеп калырга тели. *(Билге хан* Кытай императоры яллап җибәргән түрек аксөяге тарафыннан *734 елда агулап үтерелә.* Үлеме алдыннан хан бу сатлык җанның бөтен нәсел-нәсәбен тамырына кадәр корытырга, дип әйтеп калдыра).

Йоллыг тәгиннең һәйкәл ачу тантанасындагы чыгышы:

– Иң әүвәлге сүзем – барча галәмне тәрбия итүче бәрәкәт иясе Тәңрегә!

Тәңре безне халык итеп, Җиһан капкаларын ачып, күктән иңдергән. Без – Күк түрекләре!

Мин Күк белән ант итәм, әгәр ул җирне үз куенына алса;

Мин Җир белән ант итәм, әгәр ул Күкнең күз карасы булса;

Мин яктылык белән ант итәм, әгәр ул караңгылыкны куа алса;

Мин караңгылык белән ант итәм, әгәр ул яктылык тууга сәбәпче булса...

Тәңре безгә – дулкын кагышыннан, кошлар сайравыннан, яфраклар шыбырдавыннан, таулар аһылдавыннан, дала тыныннан яралган моң сүрүенә биләүләп, тел хәзинәсе иңдергән. Кояш чыгышыннан алып, кояш баешына кадәрге кыйтгада тау-үзәннәргә, урман-суларга мәңгелек атамалар бирегез, дигән.

Әгәр без үзебезгә бирелгән кыйтгадагы җирләребезне җуйсак, бүтән кавемнәр, яулап, ул җир-су исемнәренең төсен, тәмен, моңын үзгәртеп, исраф итмәсләрме? Түрек халкы телендә тирбәлгән бу дөнья нинди хәлгә калыр?

Таулар тәбәнәгәеп, сулар ярын ташлап, кошлар сакауланып, җилләр моңын җуеп, япан дала моңаеп калмасмы?

Күзләре күргәннәр – күрер, колагы ишеткәннәр – ишетер, зиһене булганнар – зиһенләр...

Без тау куышларына үз исемнәребезне яздык – ул мәгарәләр җимереләсен белмәдек.

Без кабер-курганнар эченә алтын-көмештән үрелгән хәзинәләребезне куеп калдырдык – аларга угрылар кулы сузыласын белмәдек.

Без тау маңгаендагы ташларга сурәтле истәлекләр ясап калдырдык – тау-ташлар убылыр дип белмәдек.

Без дан-шөһрәтебезне мәңгелек дип уйладык. Бар кылган гамәлләребез Җиһан хәтеренә кушылып, киләчәк дәверләргә барып җитәсенә ышандык.

Хәтер... Нинди асылташ мәңгелеге бу сүздә. Хәтере барның кадере бар...

Ана-Ил теленнән ваз кичкәннәргә бүтән кавемнәрдә йотылып, үз имен оныту язгандыр.

Түрек телендәге шифалы сүзләрне җуйган тән тибеше хастадан азардыр.

Түрек телендәге аһәңле сүзләрне оныткан тел моңыннан язардыр...

Түрек телендәге Мәңге Күк катына арналган дога сүзләренә хыянәт иткәнне Тәңре ярлыкамас...

Әгәр без уяу булмасак, җир өстендәге хәзинәләребезгә, җир астындагы хәзинәләребезгә комсыз кавемнәр ябырылыр. Әгәр без яшәү канунын бозсак, атларыбыз сөрлегер... Өзәңгеләр өзелер... Хәтеребез өзлегер... Без ул чакта бар булмабызмы?! Тау-кыя түбәләрен ак болытлар сыйпар, кош сайравына манылып, урманнар шаулар, дала йөрәген кытыклап,

тояклар тупырдар, ефәк юлыннан дөя кәрваннары узар... Ул чакта без булмабызмы?

Әгәр без булмасак... Җир йөзе үксез калыр.

Әгәр без булмасак... дошманнар үпкәләр.

Әгәр без булмасак... Тәңре үзе ни әйтер?

Без булганбыз! Без барбыз! Без булачакбыз! Күтәрик әле югары алтын бүре башлы ак байрагыбызны, күкрәтеп җилфердәтсен мәңгелек җиле!

Тередән дә терерәк нинди халык бар Җиһанда –
Тередән дә терерәк Түрек халкы – без!
Эредән дә эрерәк нинди халык бар Җиһанда –
Эредән дә эрерәк Түрек халкы – без!
Төрледән дә төрлерәк нинди халык бар Җиһанда –
Төрледән дә төрлерәк Түрек халкы – без!
Бүредән дә бүрерәк нинди халык бар Җиһанда –
Бүредән дә бүрерәк Түрек халкы – без!

Без бүз бүре сөягеннән яралганбыз. Бишегебез – бөек дала. Җире барның җиме бар, Иле барның име бар. Табынганыбыз – Җиһан таҗы – Мәңге Күк-Тәңре!

* * *

Әйтергә генә ансат, бу давыллы дәверләр узганга мең ике йөз елдан да артык вакыт үтеп киткән инде югыйсә; һаман шулай: Алтай, Саян, Урал таулары, Һималай, Арарат, Илбарыс кыялары, күккә үрелгән Карпат, Алып түбәләре түрек бабаларыбыз кушкан исемдә җиргә тамыры белән береккәннәр. Байкүл, Балкаш, Алтын күлләр, бормаланып ага торган көчле елгалар – Катын, Инәсу, Иртеш, Ана, Җаек, Аму-Дәрья, Сыр-Дәрья, Агыйдел, Кама, Идел, Тын кебек елгаларга коючы тагын йөзләгән инеш исемнәре дә төрки телдән калган ядкарьләр. Түрек яугирләре заманында түзеп булмаслык эссе комлы Такла Макан, Кара ком, Кызыл ком чүлләрен кичеп чыкканнар. Тарбагатай, Кыпчак, Чыңгыз, Кубан далаларына тәңгәл килгән исемнәр биргәннәр. Шушы иксез-чиксез кыйтгада, һаман шул төбәкләрдә түрек халкы төрле исемнәр алып яши бирә. Бер караганда, бар да элеккечә шикелле, ә икенче карасаң... бик үзгәргән инде, бар да үзгәргән...

* * *

Җәйнең матур бер көнендә (1974 ел) Монголиядә хезмәт итүче совет солдатлары, ату күнегүләре үткәрә торган полигонга барышлый, Селенга елгасы ярына җитеп, ялга тукталды. Штыгын йомдырып куйган СКС карабиннарын, бер-берсенә терәтеп, чатыр-пирамида итеп куйдылар да, кырын ятып, тәмәке кабыздылар. Җиңелчә сүгенү сүзе кушып, анекдот, мәзәк хәлләр сөйләү башланды. Тәмәке төтенен сөймәүчеләр яр буенда, алтын табарга җыенган сыман, ташлар арасында йөренә. Ә ташлар монда чынлап та хикмәтле иде, вакыт шаукымы, җил-су шомартып, аларга ниндидер серле, борынгылык төсмерен кызганмаган, кайсыларының өслеген куныклы гөмбәчекләр белән бизәп куйган иде.

Шул вакыт Колчурин фамилияле солдат кычкырып җибәрде. Аның

көр тавышы үзеннән алда йөри, Украинаның көнбатыш ягы – Ивано-Франковскидан иде ул. «Сез бит чормагызда бандеровчылардан калган пулемёт асрыйсыз», – дип, кайчакта аны үртиләр иде.

Колчурин кыр-кырлары шома бер ташны күтәреп турайтырга маташа, иптәшкә кеше чакыра икән.

– Монда андый ташлар күп. Әзер мишень бит бу, егетләр! Әйдә, ату ярышы уздырабыз!

Монда җәмгысе уналты солдат, взводның калган яртысы бүген кич каравылга керәчәк, шуңа күрә взвод командиры лейтенант Кәмбиев алар белән калып, командалыкны беренче отделение командиры кече сержант Пётр Колоколовка тапшырган иде. Колоколов урманнан әле генә дөньяга чыккан кешегә охшаган, йокымсыраган кыяфәтле, беркемгә беркайчан тавышын күтәреп дәшмәс, гомумән аңа командирлык сәләте тумыштан ук бирелмәгән иде. Колчуринның бөердән чыккан гөрелдәвек тавышы барысын да буйсындырды бит үзенә, Колоколов «уяна» да алмый калды. Солдатлар ул арада карабиннарын кулга алып, патрон магазиннарын көйләп, чыкы-чыкы затворын тарттылар. Ул арада кыргый тавыш чыгарып, акыра-бакыра атыш башланды. Мәхшәр купты. Ядрәләр, таштан тайпылып, рикошет ясап, чыелдап оча, яралы таш кыйпылчыклары ыңгырашкан аваз чыгарып куба, бер-берсенә бәрелеп чәчри дә комга сеңә иде. Елга буен әчкелтем дары исе басты.

Һәр карабин магазинындагы җидешәр патрон бик тиз атылып бетте, иңрәп тынлык иңде. Солдатлар бер-берсенә күз салмаска тырышып, бер мәл тын гына басып тордылар.

Йөз дә биш патронның нинди максатка сарыф ителүен ачыклауны лейтенант Кәмбиевкә тапшырдылар. Ул чын хәрби кеше түгел, быел гына Казан университетының тарих факультетын тәмамлаган, шунда ук хәрби кафедрада укып, лейтенант дәрәҗәсе алып чыккан иде. Диплом алуга, аны ике елга офицер булып хезмәт итәргә Монголиягә җибәргәннәр иде. Менә хәзер четерекле хәл килеп чыкты. «Җинаять» эшләгән ярты взвод солдатны ул, машинага төяп, Селенга елгасы ярына алып килде. Буш гильзаларны җыярга команда биреп, ул ташларны карый башлады һәм шаккатып калды. Борынгы рун язулы ташларны атып, харап иткәннәр икән бит! Егетләр лейтенантның кинәт чарасыз калуын агарып чыккан йөзеннән шәйләделәр.

– Монда бит борынгы язулар булган... – диде лейтенант Кәмбиев. Боларны нишләтергә? Кычкырсаң – кычкыру була, сүксәң – сүгү була. Болар баш мие кубарып алынган нindидер кыргый җанварлар шикелле тоелды лейтенантка. Юк, ярсып бернигә дә ирешеп булмаячак, киресенчә, сабыр күңел белән якын килеп карарга кирәк түгелме?..

Кәмбиев солдатларны машинага утыртып, тузанлы юлдан шактый ерак алып барды. Архан елгасы буендагы түбәҗирдә тукталгач, ул түрек каганатының сәргаскәре Күлтәгингә арналган бу төрбәнең 732 елда төзелүе хакында сөйләде. Бу тарафларда бик борынгы һун, түрек халыклары ил-дәүләтләр корып яшәгәнлеге хакында бәян иткәндә, ул япь-яшь солдатларның күзендә икеләнү, ышанып бетмәү шаукымын да сизде. 1917 елгы инкыйлабтан соң гына тарих башланып, халыклар бәхеткә

ирешкән дип, печелгән тарих өйрәнгән әлеге буынны ничек хакыйкать ягына борырга?

Солдатларны ул сакланып калган ике мәрмәр таш янына алып килде.

– Менә, төрекләрнең монда тарихы язылган. Ике телдә – төрекчә һәм кытайча**.** Моны рус һәм чит ил галимнәре XIX гасырда гына табып укый алуга ирешәләр.

Саф тарихи-тылсымлы һаваны тәүге тапкыр сулаган солдатлар, бер мәлгә шаккатып, изге су йоткан кебек тынып калдылар.

Лейтенант кичәге атыш мәхшәрен оештырган солдатларның исемлеген барлап, һәрберсенең бүгенге милләтен күрсәтеп, университетның уку залында борынгы чыганакларны метекләп өйрәнергә күнеккән гадәте белән, һәр фамилия артында нинди борынгы исем ятканын ачыклап язып куйган иде. Бераз икеләнеп торганнан соң, шул исемлекне укып чыгарга булды.

*– Иван Колчурин – украин (Колчура – кыпчак-татар исеменнән).*

*– Святослав Кучма – украин (Күчмә – кыпчак-татар исеменнән).*

*– Даниил Деникин – украин (Диннеке – кыпчак-татар исеменнән).*

*– Казимир Тазиев – белорус (Тази, Таҗи – кыпчак-татар исеменнән).*

*– Дмитрий Муртазин – рус (Мортаза – кыпчак-татар исеменнән).*

*– Семён Салтыков – рус (Салтык – кыпчак-татар исеменнән).*

*– Идегәй Аппаков – карачәй.*

*– Самат Батталов – татар.*

*– Пётр Колоколов – рус.*

*– Бабур Үтәгәнов – үзбәк.*

*– Максим Турчин – гагауз.*

*– Иван Пиктимиров – чуваш (Биктимер – кыпчак-татар исеменнән).*

*– Виктор Голованов – рус.*

*– Тактагул Тукаев – төрекмән.*

*– Станислав Хабаров – рус (Хәбәр – кыпчак-татар исеменнән).*

*– Абиш Талдаяков – казакъ.*

Лейтенант Кәмбиев борын астыннан мыек әсәре дә чыкмаган солдатларга сынап карады.

– Дөресен әйткәндә... Бу исемлектә рус милләтеннән икәү генә бар. Колоколов белән Голованов кына. Калганнарыгыз... Барыгызның да фамилияләре кычкырып тора: сез – шанлы төрек халкының варислары! Сез кичә, үзегез дә белмичә, бөек бабаларыгызның истәлекле кабер ташларын җимергәнсез икән бит!

Тарихтан бөтенләй хәбәрдар булмаган солдатлар, башларын иеп, ниндидер хәтәр бер хакыйкатькә кагылып, борынгылык җенен уяткан шикелле, тәшвишләнеп, тын калдылар.

Шулвакыт Иван Колчурин командир янына килеп, атыш булган урыннан бүген табып алган таш кыйпылчыгын кесәсеннән чыгарды. Учындагы таш кисәгендә өч япьле рун хәрефе чокылган иде.

– Бу безнең нәсел тамгасы. Әти агачтан ни генә ясаса да, шушы тамганы уеп куя иде, – диде Колчурин. Шунда лейтенант искәреп алды: моңарчы бөтенләй уй-гамьсез, гаугалы бәндә булып күренгән мәһабәт гәүдәле егетнең күзләре дымланган иде бу мизгелдә...

Әхәт
Гаффар

# КАРАЧКЫЛАР

хикәя

Зират каеннарына кичкырын кара каргалар килеп кунган иде инде. Әсхап үзләренең яшелчә бакчаларына карачкы ясап куйды. Авыл көтүе кайткан, сыер, бозавы, ике яшьлек үгез абзарга ябылган, сарык, бәрәннәр урнаштырылган, тавык-чебеш үз урынында, үрдәк бәбкәләре тук! Акбар кушаматлы эт тыныч кына ята, ике мәче кайда йөри икән – йөрсеннәр! Кызлары Хәдичә телевизор карыйдыр инде. Ә уллары Гаденән мотоциклын төзәтте дә... Кая барасын үзе чамалыйдыр тагын. Иртәгә аның соңгы имтиханы – унынчыны тәмамлый.

Әсхап шуларны уйлый-уйлый да, уйламыйча да, болай гына – бәрәңге белән карлыган арасындагы сажин аркылыга, сигез сажин буйлыйга утыртылып хәстәрләнгән яшелчә бакчасын караштыра иде. Болай тишеләсе әйбәт тишелгән, борнаган, яфрак җибәргән анысы. Тик иртәләрен түтәлләргә үз тавыкларыннан битәр күршедәге Гөлбаһар тавыклары, өстәп, кара каргалар төшеп актарынмасынга, куркытыр өчен әнә нинди карачкы ясап куйды бит әле! Хәйран – тамаша! Нәкъ үзе. «Бу ни бу?» – дигәнгә ул борылып та карамады. Ире инде – Сәгыйт. Кайткан.

Әсхап юеш, балчыклы кулын күлмәк итәгенә сөртеп куйган булды. Ире кайтканда, кулын итәгенә ничек итеп сөртәсен чамалый ул. Редисканың җирдән калыккан кызыл өлеше сыман, кояшка янган сыйракларыннан тез югартын шалкандай ак төшен чак-чак кына күрсәткәндәй итеп.

Сәгыйт үзенең солдат киемен элеп ясалган карачкыга ымлап:

– Бу ни бу? – дип сорады.

– Син, – диде Әсхап.

– Күрәм. Ә бу киемнең эшкә җарарлыгы да барые бит әле.

– Җарар сиңа, бар! Эретеп җабыштырасың да җабыштырасың. Утында иләк булып беткән бит инде.

– Бетсә суң. Моңынчы ул тишекләрдән төшереп калдырган нәрсәм жугые әле.

– Тишәргә сиңа бир инде анысы.

Сәгыйт хатынының күлмәк изүендәге төрән шикелле күгәреп күренгән төшкә кырын гына карап куйды да:

– Анысы ярый инде, – диде.

– Нәрсә анысы? Ни җитмәгән? – диде Әсхап.

– Җитүе җитеп бара бугай инде анысы, – диде Сәгыйт.

Әсхап, күлмәк итәген югарырак күтәреп, кулын сөртте дә:

– Таныдыңмы суң? – диде.

– Нәрсәне? – дип сорады Сәгыйт.

– Бу ни бу, дидем ич!

– Син, – диде Әсхап.

– Минем гвардия сержанты киемемнән башкасын тапмадыңмыни?

– Шушысы әйбәт, – диде Әсхап.

– Суң?

– Син әрмиедән кайткач, мин синнән курыкканыем.

– Суң? – дип кабатлады Сәгыйт.

– Менәтерә, хәзер тавык, каргалар курыксын инде.

– Курыксын? – диде Сәгыйт. – Бәлки алар мине... ни... яратып кунакларлардыр.

– И, и, и! – диде Әсхап.

Сәгыйт түзмәде: су сипкечне мичкәгә чумылдырып алды да шуннан сарымсак түтәле буйлата сиптереп узгач, кырыс төстә:

– Аш пешкәнме? – дип сорады.

Әсхап тыныч, сабыр, ягымлы гына итеп:

– Мунча да әзер инде, – дип җавап бирде.

Кичке тузан басылган, тулган ай калыккан, шомырт, чия, алмагачларның ботаклары төнгә каршы турайган иде. Сәгытдин, соңгы тапкыр шикелле итеп, сигарет суыра-тарта, яшелчә бакчасына чыгып басты. Яланаяклап. Ак күлмәк-ыштанлы килеш. Рәхәт иде. Шомырт, канәфер чәчәге, инеш суы исе килә. Абзардан тирән итеп сыер сулаганы ишетелә. Ә кысыр җирдәге кыргый чиялектә бетеп-бетеп сандугач сайрый. Тын. Тып-тын. Мунчала күлендә бер-берсен бүлдерми генә бакалар сайраганын тыңламасаң. Әйбәт. Әнә, карачкы да ап-ачык шәйләнә. Шәп. Солдат киемле карачкы. Аныкы. Торсын. Яхшы. Шәлперәек түгел бит. Асылынып, хәлсез-әхвәлсез тормый. Сак тора. Һәрвакыт әзер булып. Мунчала күленә салып казыклаган юкә кабыклары шикелле җебергә, аннан ары таралырга, сүтелергә дигәнмени? Бигрәк тә мунча кереп чыкканнан соң. Әнә бит: ай ничек тулган. Әйе, тын. Улы Гаденәннең капка төбендәге мотоциклы сүнгәч бигрәк тә. «Иеме, Ай?» – дип уйлады ул. Ай: «Ие», дисенмени инде?! Ул дәшми. Эндәшми. Тәгәри шунда. Май ае себеркесе белән изеп, таптап, «Аh! Аh!» дидертә-дидертә чабынганнан суң, Әсхапнең ләүкәдән әллә ишелеп төшүе, әллә күтәрелеп китүе шикелле.

Сәгыйт сигаретын актык мәртәбә суырды да анда-санда борнаган бәрәңгеләргә таба чиертеп җибәрде. Күрде: утлы төпчек тулган Айга җиткән бер мәлне... әйе, күрде: күршесе Вәдүтнең хатыны Гөлбаһар да үзләренең яшелчә бакчаларына карачкы куйган икән. Зәңгәр күлмәк кидертеп. Сәгыйтнең солдат киемен көтеп-көтеп тә киелмәгән, тузмаган-туздырылмаган крепдешин күлмәген.

Тулган ай нуры шул күлмәктәге түм-түгәрәк ак борчакларга үтәли төште дә эреде дә бетте. Сәгыйтнең кырыс кына саркып чыккан ике бөртек күз яше сыман.

Ул йокларга кереп китте.

***

Ай тәмам калыккан, шомырт, чия, канәфер, алмагачларның ботаклары кояш чыкканчыга хәтле шәлперәйгән иде әле.

Зират каеннарындагы кара каргалар әледән-әле бер-берсен бимазалаштыргалап йоклый да йоклый. Авылда бер араны сандугач та тынып торды. Шул чакта солдат киемле карачкы:

– Нихәлләреӊ бар суӊ? – дип эндәште.

Зәӊгәр крепдешин күлмәкле карачкы:

– Менә, жуып, үтүкләп чыгарганнарые әле, – диде.

– Син һаман әүвәлгечә икәнсеӊ, – диде солдат киемле карачкы.

– Син дә шундый, – диде зәӊгәр күлмәкле карачкы.

– Нинди?

– Мин сине өзелеп көткән, ә син кайткан көндәге шикелле.

– Нинди?

– Үпкәләмә инде.

Ике карачкының бер-берсенә, ниһаять, якынаюын, кочаклашуын тулган ай гына карап торды.

Җир уянып килә иде инде.

*2003, №1*

## *Безне котлыйлар*



**Эрдни ЭЛЬДЫШЕВ,**
Калмыкия Республикасының халык шагыйре

*Кадерле дуслар!*

*Легендар татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил калмык шагыйре Давыт Көгелтинов өчен туган илгә һәм шигърияткә тугрылык һәм мәхәббәт үрнәге булган. Ул аның турында: «Муса Җәлил һәлак була, ләкин аның тормышы җырга әверелә», дип яза. Үзенең 1958 елда язган «Моабит тоткыны» дигән иң күренекле әсәрләренең берсен Муса Җәлилгә багышлый. Күренекле татар шагыйре Зиннур Мансуров Давыт Көгелтиновка багышланган бер шигырен очраклы рәвештә генә язмаган.*

*Татар шагыйрьләрен калмык теленә Лиджи Инджиев, Басанг Дорджиев, Бося Сангаджиев, Алексей Балакаев кебек күренекле калмык шагыйрьләре тәрҗемә иткән. Мин үзем дә, хәлемнән килгәнчә калмык әдәбияты ветераннары башлаган традицияне дәвам иттерергә тырышам. Татар әдәбияты классигы Габдулла Тукай әсәрләрен, бүгенге заман шагыйрьләреннән Ркаил Зәйдулла, Рафис Корбан шигырьләрен калмыкчага әйләндереп, алар үзебезнең әдәби-нәфис «Теегин герл» (Дала нуры) журналында басылып чыкты.*

*Калмыкия язучылары исеменнән Татарстан язучыларын һәм аларның үзәк матбугат органы булган «Казан утлары» журналы коллективын олуг юбилейлары белән чын йөрәктән котлыйм. Аның әле шулай озак еллар буе татар укучыларын гүзәл әсәрләр белән сөендереп торуын телим.*

Фәүзия Бәйрәмова

# СИРЕНЬ ЧӘЧӘГЕ

хикәя

Әле яз җитмәгән иде. Аның хакында беренче хәбәрне уйнаклап искән җил малайлары алып килде. Алар, томырылып, сирень куакларын чорнап алдылар, нечкә ботаклар көязләнеп иелгән-бөгелгән булдылар, кар астында яткан тыгыз бөреләргә кинәт эссе булып китте, алар сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп куйдылар, тыгыз тәннәренә җил малайлары килеп кагылган саен, серле генә аһылдашып алдылар.

«Башланды инде», – дип уйлап алды корыган чәчкә. Чөнки ул бу күренешне инде һәр яз саен күзәтә, һәр яз саен яшь бөреләрнең, кабыкларына сыеша алмыйча, ашкынуларын, хисләнүләрен күрә. Күрә дә көлә. Корыган тәлгәшләрен чымырдата-чымырдата, рәхәтләнеп көлә ул алардан. Йә, кая шулкадәр ашкыналар инде бу җүләр бөре кызлары? Шул азгын җил егетләре килеп кагылганга чыркылдашкан булалар. Менә аңа кагылып кына карасыннар – ул зәһәр кыштырдавы, көйгән кисәү кебек караңгы чырае белән аларның котларын алачак. Ник кагылганнарына үкенерлек булып. Ул бит инде карт чәчкә, белә бу язгы кети-метиләрнең нәрсә белән тәмамланасын. Аның күз алдында гына да шулай алгысыган күпме бөре кызларын ботаклары-ниләре белән ботарлап киттеләр. Матурлыкларына кызыгып, шашып-шашып өзгәләделәр аларны. Башта алар җилләр белән шаярдылар, аннары кояш нурын күреп аһ иттеләр һәм бер кичне, тәмам өзгәләнгән хәлдә, адәм балалары кулына күчтеләр. А-а, күп күрде карт чәчкә мондый аянычлы хәлләрне. Аны хәзер алдый алмассың инде!

Бу язда да шулай булды. Мәхәббәттән һәм сокланулы карашлардан тәмам тулышкан яшь бөреләр, язгы иртәләрнең берсендә назланып кына ачылдылар да үзләренең сафлыклары һәм гүзәллекләре белән таң калдырдылар. Хәтта, адәм балалары булып, алар да, бу кадәрле матурлык каршында туктап, бер мәлгә тынып калдылар.

– Абау, нинди матур чәчкә! – диде үзе дә чәчкә кебек сылу бала. – Телисеңме, хәзер мин аны сиңа өзеп бирәм, – диде егете, ашкынып.

«Өзәләр, өзәләр хәзер теге кыланчык нәрсәне, – дип ләззәтләнде корыган чәчкә. – Шулай була ул, бик чекерәеп күзләренә кереп торсаң. Ышыкта, күләгәрәктә яшәсәң дә әле...

Ул арада егет, куе ботакларны аралап, теге ымсындырып торган чәчкәгә үрелде. Корыган чәчкә, коты чыгып, яфраклар арасына кереп посты. Ләкин егет аңа таба әйләнеп тә карамады, аның күзләре, сихерләнгәндәй, дымлы авыр тәлгәшләрен чак күтәреп тулышып утырган ян чәчкәгә төбәлгәннәр

иде. Егет, тагы дә үрелә төшеп, зур саклык белән, назлап кына, сирень чәчәген өзеп тә алды. Чәчкә үзенчә: «Аh!» – итеп куйды да тынды. Егетнең кулына әллә яшь, әллә чык тамчылары тамды...

– Менә... сиңа... – диде егет, Мәҗнүндәй, сөйгәненең күзләренә карап.

– Аh, нинди матур чәчкә! – диде кыз, тәлгәшләрне күкрәгенә кысып. Аннан ул аларны иреннәренә тидерде, аларга нидер пышылдады, үзе, чәчкә арасыннан көлеп, бәхет, наз тулы карашы белән егетне иркәләде.

«Ул нинди гүзәл! – дип уйлады егет. – Ул мәхәббәт алиһәсенә тиң зат». Алар, бер-берсенә сыенып, йортка кереп киттеләр. Корыган чәчкә аларны үрелә-үрелә карап калды. «Бу юлы да исән калдым, – дип уйлады ул җирекүге белән сөенеп. – Тыйнаграк яшәргә кирәк шул дөньяда, тыйнаграк». Бу көнне бу ботакта берүзе калган булса да, аңа игътибар итүче күренмәде. Хәер, корыган чәчкәнең кемгә кирәге бар иде соң?

Сирень куагы гашыйклар яшәгән йортның тәрәзә каршында ук үсә иде. Кич җитү белән, корыган чәчкә кача-поса, бүлмәгә күз салды. «Йа, Хода, ниләр генә кыланмыйлар бу адәм балалары!» дип уйлады ул, яшьләргә карап. Егет сөйгәнен назлап кулларына күтәргән иде. Ә тегесе, тәмам ышанып, яратып, аның күкрәгенә сыенган. Егет аны бик зур саклык белән, кадерләп, урынына илтеп салды. Ә үзе, идәнгә тезләнеп, башын аның кайнар күкрәгенә куйды...

Корыган чәчкә, гаять кызыксынып, тәрәзәгә тагы да иелә төште. Ә, әнә теге кыланчык яшь чәчкә дә бүлмәдә икән әле. Әй утырган була әллә кем булып пыяла вазада! Әйдә, көязлән, көязлән, әмма бу көязлегең бер генә төнлек инде синең, иртәгә таңга син шиңәчәксең, инде сиңа берәү дә сокланмас, сине урамга чыгарып ташларлар...

Корыган чәчкә, kahkahә белән көлеп, шап та шоп тәрәзә пыяласына бәрелде. Егет, бу сәер тавыштан сискәнеп, башын күтәрде, урамга карады, җил икән дип, тәрәзә пәрдәләрен ныклабрак ябып куйды... Корыган чәчкә, күпме генә тырышса да, башка берни дә күрә алмады...

...Ә бүлмәгә сирень чәчәге исе таралган иде. Вазадагы чәчкә төне буе ике гашыйкның чиксез мәхәббәтенә ялгыз шаһит булып утырды...

Корыган чәчкә дә ул төнне йокысыз уздырды. Ул, салкыннан һәм ачудан тагы да нык бөрешеп, җылы өй эчендәгеләргә мең ләгънәтләр яудырып, кара көеп, таңны каршылады. Менә алсу тәрәзә пәрдәләре җиңелчә генә дерелдәп куйдылар һәм корыган чәчкә шуның ярыгыннан комсызланып, бүлмәгә күз салды. Аның, адәм балаларыннан бигрәк, кичә өзелгән яшь чәчкәнең шиңеп, мескен хәлдә шәлперәеп утырганын күрәсе, күрәсе дә шуңа сөенәсе килгән иде. Ләкин пыяла ваза буш, ә сирень чәчәге... Сирень чәчәге яшь хатынның ачык күкрәге өстендә иртәнге татлы йокыга талган иде. Бу искиткеч күренеш иде, хәтта корыган чәчкә булып, аның да кипкән йөрәге бу илаһи манзарадан тетрәп киткәндәй булды. Яшь хатын сулыш алган саен, күкрәк өстендә таралып яткан чәчкә дә тибрәнеп-тибрәнеп куя. Гүя ул да бу мизгелдә яши, сулыш ала, хыяллана, саташа, сөя һәм сөелә иде. Инде тамырыннан өзелеп кәүсәсеннән аерылса да, инде бу ят дөньяда башы әйләнеп, тыны кысылса да, сирень чәчәге бүген искиткеч бәхетле иде. Бу мизгелдә ул мәхәббәтнең иң изге, иң гөнаһсыз һәм иң бөек билгесенә әйләнде. Ул мәхәббәт киченең истәлеге булып, адәм балаларының бүгенгесеннән киләчәгенә күчте.

«Хәтерлисеңме, теге сирень чәчәге өзгән кичне?» – дияр, еллар узгач, инде шактый олыгайган ир кеше. «Аһ, мин ул кичне мәңге онытасым юк,– дияр әле һаман сылу, һаман бәхетле хатын. Мин бит ул сирень чәчәген әле һаман саклыйм. Туй күлмәгем белән бергә».

...Ә корыган чәчкә? Корыган чәчкә бу бәхетне, бу олы мәхәббәтне читтән генә, кача-поса гына, үзенең бу шыксыз тормышына бәлки үкенер, ә бәлки үкенмәс тә, ияләнер, күңеле катыр...

Тик язларын яшь бөреләргә дәшмәс, аларның хисләреннән зәһәрләнеп көлмәс инде ул. Чөнки дөнья корыган чәчкәләре белән түгел, ә тынгысыз яшь бөреләре, аларның саф мәхәббәтләре белән мәңгелек икәнен анлады инде ул... Аңлады.

*1997, №1*

## *Безне котлыйлар*



**Гаврил АНДРОСОВ,**
*Саха (Якутия) Республикасы «Чолбон» иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналының баш мөхәррире, Россия Язучылар союзы идарәсе сәркатибе*

*Хөрмәтле Рөстәм Госман улы һәм «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре!*

*Якутия Республикасының «Чолбон» иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналы коллективы һәм үз исемемнән сезне 100 еллык юбилеегыз белән котлыйм.*

*Журнал тарихы Татарстан АССР Наркомпросы органы булган «Безнең юл» журналын оештыручы күренекле татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов исеме белән тыгыз бәйләнгән. Безнең «Чолбон» журналы да 1926 елда Якутия Наркомпросы һәм «Саха омук» мәдәни-агарту җәмгыяте органы буларак оештырыла һәм аның беренче редакторы итеп Анемподист Иванович Софронов – саха халкының символик шәхесе, рухи лидеры һәм әдибе билгеләнә. Бер гасырлык тарихы булган өлкән татар әдәби журналында әледән-әле рус һәм башка милләтләр язучыларының, шул исәптән якут авторларының да әсәрләре тәрҗемә ителеп басылып килә.*

*«Казан утлары» битләрендә әледән-әле якут язучыларының әсәрләре татар телендә, ә «Чолбон»да татар язучыларыныкы якут телендә дөнья күрә. Рөстәм Галиуллинның чыгышы белән татар булган якут баһадиры Боссоойко турындагы хикәясе һичшиксез ике кардәш халыкның дуслыгын символлаштыра. Безнең басмалар үзләренең элгәреге әдипләре урнаштырган традицияләрне лаеклы дәвам иттерерләр дип ышандырасы килә. Шунысы сөендерә: без гаять мөһим эш белән шөгыльләнәбез, үз халыкларыбызның рухи мирасын саклыйбыз һәм арттырабыз.*

*«Казан утлары» журналы коллективына хезмәттә яңадан-яңа уңышлар, иҗат дәрте, алга таба да эшләренең гөрләп баруын телибез.*

# КАЛЫН ЖУРНАЛ

## Гасырлар чигендә яшәргән «Казан утлары»

«Казан утлары»нда үзгәртеп корулар белән бәйле тагын бер яңарыш дулкыны 1988-1990 еллардан башлана. Цензура юкка чыгарылу, партиянең мәйданнан китүе, СССР таркалу, татарлар арасында милли үзаңның гаять көчле үсеп китүе әдәбиятны да, аның көзгесе булган журналның эчтәлеген дә тамырдан үзгәртә. Шушы чордан милли юнәлешле үткен публицистика әһәмиятле урын алып тора башлый: ил кайнаган бер чорда басма татар халкы белән аның мәнфәгатьләре хакында ачыктан-ачык сөйләшү мәйданына әйләнә. Ул иң үткен, уйлы-фәһемле материаллар биреп барырга омтыла, әдәбият чикләреннән – гомуммилли мәсьәләләргә күчә. Әйтик, И.Таһировның «Кем ул Солтангалиев?» (1989, № 4) язмасы, М.Мөлеков белән әңгәмә (1990, № 4) – шундыйлардан. Т.Әйди, Т.Миңнуллин, И.Таһиров, А.Хәлим, Р.Юныс һ.б. фикер ияләренең материаллары халыкның дөньяга карашын формалаштыру, милли үзаңны кузгату, милли-мәдәни үсеш юнәлешләрен билгеләү ягыннан гаять зур эш башкара.

Гомумән алганда, журналдагы татар әдәбияты – шигырь-поэмалар, проза яки драма әсәрләре дә татар дөньясы, милли рух турында сөйләшүгә, үз халкын борчыган проблемаларга өстенлек бирә. Ил белән бергә өр-яңа вазгыятькә килеп кергән татар язучысы бу дәвердә дә үз милләтенә хезмәт итү юлын сайлый! Шунысы мөһим: катлаулы сәяси-иҗтимагый шартларда басма татар әдипләрен берләштерүче булуын тагын бер кат исбатлый, яшь ягыннан гына түгел, шәхес булып формалашу шартлары, дөньяга карашлары да капма-каршы булган буыннар өчен уртак бер рухи-мәдәни үзәк булудан туктамый. Югыйсә кайбер халыкларның мәдәниятендә нәкъ менә карашлар төрлелегенең – төркемнәр оештырып бүлгәләнүләргә, яңа ачылган әдәби «калын журнал»ларның төрле юнәлешле булып үсүенә китерүе дә күз алдында!

Татар мәдәниятендә киресенчә: «Казан утлары» өлкән, урта, яшь буын каләм әһелләрен, әдәбиятка килүчеләрне – барысын да милли әдәбиятны үзгәртү, аны камилләштерү, сүз сәнгатендәге традицияләрне кайтару, шул ук вакытта дөнья әдәбиятында барган яңа тенденцияләрдән калышмау кебек бурычлар тирәсенә җыя. Татар әдәби барышында традицияләрне яңарту, өр-яңа мәгънәви тирәнлекләргә чыгу да өлкән буын (Г.Ахунов, Ә.Баянов, Р.Батулла, Г.Бәширов, А.Гыйләҗев, А.Хәлим, Ф.Яруллин һ.б.) белән янәшәдә алардан соң әдәбият мәйданына килүчеләр (Ф.Бәйрәмова, Р.Вәлиев, Р.Зәйдулла, В.Имамов, З.Мансуров, Ф.Садриев, Ф.Сафин һ.б.) тарафыннан бергәләп башкарыла. Үзгә сурәткә, романтизм һәм модернизмга, шартлы-метафорик һәм постмодернистик эзләнүләргә өстенлек бирү дә һәм совет, һәм «советтан соңгы» дәвер иҗатчыларын (М.Галиев, М.Гыйләҗев, Н.Гыйматдинова, И.Иксанова, М.Кәбиров, Р.Миңнуллин, М.Мирза, Р.Харис, З.Хәким һ.б.) журналда туплап, аларның иҗади фикере басма катнашында һәм йогынтысында формалаша, үсә. Бүген инде үзләрен талантлы каләм әһелләре итеп танытган Р.Аймәт, А.Әхмәтгалиева, Р.Галиуллин, Л.Гыйбадуллина, Йолдыз, Р.Мөхәммәтшин, Л.Шәех, Л.Янсуар һ.б. шушы төрлелекне хуплау шартларында үз әдәби сукмакларын таба.

Тагын бер яңалык – моңа кадәр яшерелгән яки җитәрлек игътибар бирелмәгән әдәби мирасның кайтуы. Бу яктан, М.И.Әхмәтҗановның журналдагы татар мәдәниятендә моңа кадәр билгеле булмаган өр-яңа табышларны туплаган язмаларын аерып билгеләп

---

*Дәвамы. Башы 18, 76 нчы битләрдә.*

үтәргә кирәк. «Шиһабетдин Мәрҗани шәҗәрәсе» (1989, № 7), «Мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәси хакында яңа мәгълүматлар» (1990, № 7), «Хат калыплары» (1993, № 4), «Кулъязма китапларда кече жанрлар» (1994, № 4), «Шагыйрь Габдессәләм» (1995, № 6), «Шагыйрь Миңлекәй» (1995, № 12), «Шагыйрь Әхмәтҗан Тубылый» (1997, № 1), «Татар зиратлары» (1997, № 12), «Фатих Кәрими мирасына яңа сәхифәләр» (1999, № 6) һ.б. язмаларда татар дөньясының узганына караган нинди генә мәсьәләләр күтәрелми дә мәгълүматлар китерелми!

«Казан утлары»нда Гаяз Исхакый мирасын күрсәтү белән бәйле төпле, системалы эш алып барылганны, басманың күренекле әдибебез иҗатын кайтаруны әйдәп баручылардан булуын әйтергә кирәк. Бер яктан – аның әдәби әсәрләре журнал аша тиз арада халыкка барып ирешә: 1990 елгы 1нче санда – «Сөннәтче бабай», 1-2 саннарда «Ике йөз елдан соң инкыйраз», 1992 елның 2нче санында – «Көз» повесте, башка әсәрләре дөнья күрә. Икенче яктан, аның шәхесе, халкы өчен башкарылган хезмәтләре, милләткә багышланган гомере хакында зур сөйләшү башланып китә. Әйтик, Х.Миңнегуловның күренекле язучыбызның милләтенә васыятен яңгыраткан «Гаяз Исхакый хаты» (1991, № 5) язмасы – шушы сөйләшүне кузгаткан сәбәпләрдән дип аерып бәяләнергә лаек.

«Казан утлары», әйтерсең лә, үз тарихындагы, татар әдәбияты һәм мәдәниятендәге куркыныч хәлләр өчен халыктан гафу сорау – тәүбә итү юлын да аңлы рәвештә сайлый. Журналда шәхес культы белән бәйле әдәби әсәрләр – И.Салаховның «Тайгак кичү» (1988, № 4) Г.Тавлинның «Афәт» (1990, № 3) романнары дөнья күрә. Г.Кашаповның Х.Туфанның үлем сорап язган хаты турындагы язмасы (1989, № 2), Ф.Баһаветдиновның «Кәрим Тинчуринның соңгы көннәре» (1990, № 2), Ф.Баһаветдинов белән А.Әхмәдуллинның «Фәтхи Бурнашның соңгы еллары» (1990, № 10), Б.Солтанбәковның М.Солтангалиевнең аяныч көннәре турындагы «Гаделсезлек тантанасы» мәкаләсе (1993, № 2), М.Солтангалиевне гаепләгән ике утырышның протоколлары («Солтангалиев эше», 1993, № 2-3), кызы А.Сагайдак әзерләп биргән Ш.Усманов көндәлеге (1994, № 11) һ.б. материаллар – шундыйлардан. Бу исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде.

«Җидегәнчелек» турында Р.Вәлиев белән М.Мәһдиевнең «Болганчык еллар авазы» (1992, № 1), Р.Мостафинның Ф.Кәрим язмышына кагылышлы «Өзелергә җитеп сыкрый күңелем...» (1990, № 7), шул ук авторның Х.Туфан фаҗигасе турындагы «Бер "зарарлы әсәр" тарихы...» (1991, № 5) кебек язмалар да, узган вакыйгаларга әйләнеп кайтып, аларга тарихи бәя бирергә ярдәм итә.

Шуның белән бергә, әдәбият тарихына, теориясенә караган проблемалы, аналитик язмалар бик нык кими. Акрынлап, инде 1950 еллар уртасыннан башлап, алар урынын юбилейларга нисбәтле әзерләнгән мактау мәкаләләре яулый бара. Чын әдәби тәнкыйть юкка чыгу чигенә җитә, акрынлап, аның бөтенләй кирәге юк дигән фикер урнаштыру омтылышы калкулана. Үз чиратында, әдәби тәнкыйтьнең булмавы моңа кадәр «эзоп телен» куллану, яшерен эчтәлек тудыру юнәлешендә камилләшә барган һәм гасырлар чигендә ачыктан-ачык тасвирлау мөмкинлеге тууга – югалып калган татар әдәбиятында яңа перспективалар барлауны акрынайта. Бу, бигрәк тә, XX гасыр ахыры татар әдәбиятында аермачык күренә.

Бу нисбәттән, 1960 еллардан башланган – фактларга, вакыйгаларга нигезләнеп үткән тарих турында сөйләү тенденциясенең әдәбият фәненең җитди проблемаларын журнал битләреннән кысрыклап чыгаруын да әйтмичә булмый. Инде бүген, татар җәмгыятендә тарихи-мәдәни мәгълүматларны җиткерү мәйданнары гаять тә киңәйгән бер вакытта, журналның үз өлкәсен – татар әдәбияты хакында фикерләшүне төп бурычлардан итеп санавы күпмедер күләмдә хәлне үзгәртә барганлык та күренә.

«Казан утлары» – традицияләргә тугры калырга омтылган журнал: бу аның көчле ягы булып тора. Басма төрле исемнәр белән чыкканда да кабат-кабат әйләнеп кайтылган темалар да юк түгел. Шуларның берсе – Тукай турында истәлекләр бирү.

Бу традиция «Безнең юл» журналыннан ук башлана: аның 1923 елгы 8-9нчы саны Г.Тукайның үлеменә 10 ел тулуга бәйле нәшер ителә. Шуннан соң инде даими, ел саен әйләнеп кайтып, яңа материаллар белән байый торган бер өлкәгә әйләнә. Тукай исеме иҗатчыларга мәдәни кысрынкылык вакытларында да XX гасыр башы татар әдәбияты хакында даими сөйләшеп тору өчен җирлек була.

Борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты да – шундый темаларның берсе. Журнал татар укучысын әдәбиятның борынгы, урта гасырларына караган истәлекләр белән таныштыруны гел күз уңында тота. Әйтик, 1940 елгы вакыйгалардан соң шактый озак тыелып килгән текст – «Идегәй»нең фольклорчы галимә Ф.Әхмәтова кереш сүзе белән (1989, № 1) һәм соңрак дастанның Н.Хәким варианты (2003, № 9) басылу, әйтерсең лә, 1940 елларда башланган тарихны, XX гасыр ахырында һәм XXI гасыр башында кабат әйләнеп кайтып, йомгаклап куя.

Әмма иң мөһиме – журналда аның тарихының һәр дәверендә дә игътибар үзәгендә тотылган, басманың йөзен билгеләүче, аерым бер чорларда активлашып-көчәеп китә торган, беркайчан да өзелмәгән тенденция – милләтнең, татар мәдәниятенең мәнфәгатен кайгырту, дөнья буйлап сибелеп яшәүче татарлар өчен аларны борчыган көнүзәк мәсьәләләр хакында сөйләшү мәйданы булып калу! Күрәсең, басманың озын гомерле булуын тәэмин иткән төп сыйфат шушыдыр.

Үз чиратында, бу урында А.Гыйләҗевнең 1992 елда язган сүзләрен дә искә төшереп үтү урынлы булыр: «Журнални әдипләр генә түгел, журнални сәяси белгечләр генә түгел, журнални шагыйрьләр генә түгел, журнални татар яклады. Журнални татар ясады, татар рухсытты, татар яшәтте» (http://kazanutlary.ru/news/tarih/zhurnalybyz-turynda).


XXI гасырда татар әдәбияты тагын бер кат үзенең тирән тамырлы-тармаклы иҗат традицияләрен яңарта алырлык көчле, үзенчәлекле һәм фәһемле сүз сәнгате булуын исбатлап яши. Әдәбиятның үсеш-үзгәреше «Казан утлары» журналына да тәэсир итә, алар арасында ике яклы бәйләнеш бар: әдәбият журнални үстерә, журнал исә – милли әдәбиятны яңа үрләргә әйди. Журналның соңгы еллар басмаларында мин «Аң» журналыннан ук килә торган бер матур күренешнең кабатлануын күрәм: ул да булса – милли мәдәнияттәге яңалыкларны күрсәтү белән чикләнмичә, шуларны тудыручы, уйлап табучы, әлеге яңалыкларны әдәби формага төрерлек иҗатчыларны барлаучы-табучы, үз тирәсенә туплаучы, бер сүз белән әйткәндә – татар иҗади-мәдәни фикеренә йогынты ясаучы булырга омтылуы. А.Гәрәева-Акчура, Л.Ибраһимова, Ә.Ситдыйкова, А.Суфиянов, С.Якупова һ.б. бик күп исемнәрне, әлеге талантлы ул-кызларның иҗатын «Казан утлары» танытты. Чит төбәкләр белән эшләү рәвеше дә, язучыларны туплавы, хәтта алар белән бергәләп әдәбиятта яңа күренешләргә юл сабуы да хуплауга лаек. Әйтик, Башкортстан җирлегендә иҗатка канат куйган Д.Булатова, Х.Исмәгыйлев, К.Кара, В.Мәҗитова, Г.Мирһади, Р.Сөләйманов, А.Хәлиуллина, И.Фазлетдинов һ.б. каләм әһелләрен Казанга, татар дөньясына шушы журналыбыз күрсәтте! Яшьләр иҗатын пропагандалау һәм алар өчен осталык мәктәбе булдыру ягыннан да аңа тиңнәр табылмас: Г.Батталова, Б.Ибраһим, З.Камалова, А.Сабирова һәм башка бик күп яңа исемнәр һәм алар иҗаты хакында фикерләр шушы басмада яңгырыйлар.

Үзгәртеп коруларның шифалы йогынтысында татарча яңа әдәби, мәдәни, фәнни-популяр журналлар ачылды – бу хуплауга лаек. Әмма «Казан утлары» татарларның төп басмасы булып кала. Моның сере ачык – ул бит гадәти вакытлы матбугат органы гына да, әдәби «калын» журнал гына да түгел. «Казан утлары» – милли журнал, милли мәдәниятне, иҗади фикерне, фәлсәфәне үзәккә куйган татар энциклопедиясе, татар дөньясын берләштерүче, аңа кыйбла билгеләүче сүнмәс җылылык һәм яктылык чыганагы да. Гомере озын булсын олы юбилеен билгеләп үтүче басмабызның!

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

Рәфикъ
Юныс

# РЕФЕРЕНДУМ: ХАЛЫК «ӘЙЕ» ДИДЕ



*Рәфикъ Юныс «Казан утлары»ның 1000 саны чыгу уңаеннан үзе төзегән «Сүнмәс утлар балкышы» китабы белән.*

Парламентыбыз, Татарстанның дәүләт статусын күтәрү максатыннан чыгып, «Татарстан Республикасының Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы договорлар нигезендә коручы суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты булуына сез ризамы?» дигән сорау белән җөмһүриятебездә яшәүче гражданнарга мөрәҗәгать итәргә, ягъни 21 мартта референдум уздырырга дигән карар чыгарды. Куелган сорауга халык «әйе» яки «юк» дип җавап бирергә тиеш иде.

Татарстан Республикасының референдум үткәрү буенча Үзәк комиссиясе референдумның цивилизацияле илләр үрнәгенчә тыныч шартларда узуын билгеләп үтте һәм тавыш бирү нәтиҗәләре турында хәбәр итте. Сайлауда катнашкан гражданнарның 61,4 проценты референдумдагы сорауга «Ә Й Е» дип тавыш биргән.

Шулай итеп, референдум Татарстан Республикасында яшәүче төрле милләт вәкилләре Татарстанның тулы мөстәкыйльлеген, бәйсез дәүләт булып яшәргә тиешлеген тагын бер кат раслады. Референдум барышына күзәтчелек итү максаты белән, дөньяның күп кенә илләреннән рәсми вәкилләр, күпсанлы журналистлар килгән иде. Соңыннан алар референдумның демократик шартларда узуын билгеләп үттеләр.

Әйтергә кирәк, референдум алды көннәре зур фикер каршылыклары, көрәш, төрле яклап басым ясау шартларында узды.

Россия Федерациясе Югары Советы 1992 елнын 5 мартында Татарстан Республикасы Президентына, халкына, Югары Советына мөрәҗәгать белән чыкты, Татарстан җитәкчелеген сепаратизмда, татар халкының башка халыклар белән гасырлар буена килгән элемтәләрне өзәргә һәм Россия Федерациясе составыннан чыгарга омтылуда гаепләде. Россия Федерациясенең Конституцион суды исә, Татарстанда уздырылачак референдум законга каршы килә, дип нәтиҗә чыгарды. Татарстанның мөстәкыйльлеккә омтылуын, бөтен халык референдумын үткәрүне беренчеләрдән булып Башкортстан Югары Советы Президиумы хуплап белдерү белән чыкты. Аңа Чечен Республикасы Президиумы да кушылды. Татарстан Президенты М.Шәймиев, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Премьер-министры М.Сабиров исемнәренә АКШ, Финляндия, Төркиядән, Санкт-Петербург, Мәскәү, Киев, Рига, Уфа, Оренбург һ.б. бик күп шәһәрләрдән килгән хат-телеграммалар төрле илләр, төбәкләргә сибелгән татар халкының бердәмлеген раслады. Ә Россия демократик

партиясенең Казан бүлекчәсе, «Согласие» төркеме, Мәскәүдә чыгучы күпсанлы газета-журналлар, радио-телевидение тапшырулары референдумның максатын төрлечә бозып күрсәтергә тырыштылар. Татарстан Президенты М.Шәймиев берничә мәртәбә Татарстан халкына мөрәҗәгать белән чыкты. Мәскәү телевидениесе аша чыгышлар ясап, ул, референдумның төп максаты Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турындагы Декларацияне раслау, дип белдерде. Татарстан Югары Советының 18 мартта узган чираттан тыш сессиясендә дә бу хакта ачык әйтелде. Анда Россия Федерациясе Югары Советының Милләтләр Советы рәисе Рамазан Абдулатипов та катнашты һәм Татарстанның бәйсезлеккә омтылуын хуплап чыгыш ясады.

Референдум алды көннәрендә Татарстан язучылары да актив эш алып бардылар. Аларның гомуми җыенында кабул ителгән Татарстан халкына мөрәҗәгатьләрендә референдум үткәрүнең төп мәгънәсе ачык чагылдырылган иде.

*1992, №4*

## *Безне котлыйлар*



**Әскәр ДОДУЕВ,**
Кабарда-Балкар Республикасы «Мәңге-Тау» әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журналының баш мөхәррире, Карачай Республикасының халык шагыйре

*Татар әдәбияты ерак гасырлар түрендә үк тамыр җәйгән борынгы әдәбиятларның берсе. Ул әхлакый тамырлары һәм кешелек кыйммәтләре белән бөек төрки әдәбиятның мөһим бер тармагы.*

*«Казан утлары» әнә шушы кодрәтле әдәбиятның көзгесе һәм шул ук вакытта рупоры булып тора. Журнал битләрендә татар язучыларының, шагыйрьләренең, тәнкыйтьчеләренең һәм әдәбият белгечләренең бөтен татар дөньясының рухи һәм мәдәни үсешен чагылдырган үзенчәлекле, югары сәнгатьле әсәрләре дөнья күрде. Журналның тагын бер ихтирамга лаеклы эше – ул үз битләрендә төрле халыкларның әдәбиятыннан әсәрләрне дә теләп һәм даими бастырып килә, шуның белән үзара элемтәләрне булдыруга, дуслыкны ныгытуга үз өлешен кертә.*

*С.М.Аксаков, И.С.Тургенев, М.А.Булгаков һәм башка күренекле әдипләрдән башлап күпме генә татар халкы вәкилләре рус әдәбиятына хезмәт иткәнен әйтеп тә торырга кирәк түгел. Шуларның берсе Михаил Салтыков әйткәнчә: «Әдәбиятка пыскып утыру хас түгел. Ул үлемне кабул итми». Иманым камил, дөнья әдәбияты нинди генә түбәнлеккә төшсә дә, «Казан утлары» татар әдәбиятына пыскып урырырга юл куймаячак. Без татар әдәбиятының бөеклегенә ышанабыз, шуңа күрә татар классик язучыларының, бүгенге әдипләренең әсәрләрен «Мәңге-Тау» битләрендә рәхәтләнеп басабыз, шулай ук журналыбыз китапханәсенең аерым җыентыклары итеп бастырып чыгарып киләбез.*

*«Казан утлары» үзенең бер гасырлык юбилеен билгеләп үткәндә, зур әдәби мирасы булган журналга озын гомер, хезмәткәрләренә күтәренке кәеф, нык сәламәтлек, сүрелмәс иҗат ялкыны, бәхет телибез!*

## Ркаил Зәйдулла

### Юл

Юллар чуалган чорларда,
Чуалып зиһен, акыл да,
Хыялый булып, саташып
Җирдәге җәннәт хакында,
Безнең юл, менә безнең юл! –
Кем дәшкән? Кемнәр сөрәне?
Фетнәдән азган киләчәк
Тырнагы күзгә терәлде.
Сүзләрне тезеп кәгазьгә,
Әйтерсең гаскәр тезелә! –
Тартышып яшибез һаман,
Хак бар яшәргә безнең дә.
Өзелә гомер бу юлда,
Гарьлектән үзәк өзелә.
Җил искәнне көтә кузлар
Тузгыган учак эзендә.
Караңгыда адашсак та,
Төн әле безне йотмады:
Очкын бар каләм очында,
Эч тулы – гыйсъян утлары...

*«Казан утлары». 2017 ел, 5нче сан.*

## Ләис Зөлкарнәй

***

*Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов,*
*Тукай – өч йолдыз ул.*
Г. Тукай.

Бар дөньяның ямен, гамен җыеп,
Яна шагыйрь, ут бөрки тәннән.
Шагыйрь өчен шушы дөнья – оҗмах,
Шушы дөнья – утлы җәһәннәм.

Шаулаган да җиргә иңгән, дибез,
Ә кабердә ята тән генә,
Утлы җан ул дөрләп күккә аша,
Йолдыз була – яна мәңгегә.

Ә күкләрдә инде күпме йолдыз!
Кайсы газиз, безгә кадерле?
Дәшми әйләнәләр, үзәктә күк
Казык Йолдыз – Тукай бәгыре.

Бик биеккә менеп янсалар да,
Төшенәләр җирнең гаменә.
Йолдыз атылганда килдек җиргә,
Җаннар шул ук, бүтән – тән генә.

Баштан ашсын ләззәт, утлы газап,
Янсын бәгырь, көл калсын тәннән.
Безнең өчен шушы дөнья – оҗмах,
Шушы дөнья – утлы җәһәннәм!

*«Казан утлары». 1981 ел, 4нче сан.*

## Газинур Морат

### Карт һәм чабак

Җилкәннәрдә җилләр черем итә,
Калкавычка кунган төклетура.
Кабан күлдәй кадим каегында
Йокымсырап ялгыз карт утыра.
Каек төбендәге күлдәвектә
Чәбәләнеп ята сыңар чабак.
Сыңар чабак – гүя соңгы өмет,
Сыңар чабак – гүя соңгы чара.
Чабак чаклы гына соңгы өмет
Бәргәләнеп ята күлдәвектә.
Казан казнасының алтыннарын
Юкка гына күлгә күммәдек лә?!

Хан йөзеген йоткан картлач чуртан
Капмый калмас кебек кармагыңа.
Су кызлары табып бирер төсле
Ханбикәнең алтын тарагын да.
Сөйрәп чыгарыр күк албастылар
Казаланган Казан байлыгын да...
Йокымсырап утыра карт шулай
Кабан күлдәй кадим каегында.
Җилкәннәрдә җилләр черем итә,
Калкавычка кунган төклетура.
Кала чыр-чуына оеп, ярда,
Чабак көтеп, әнчек эт утыра.

*«Казан утлары». 2009 ел, 8нче сан.*

## Рафис Корбан

***

Яши идем туган ягымда мин
Тыныч кына үскән тал кебек.
Талга оялаган сандугачтай
Күңелемә урнаштың кереп.

Нурга тулы, моңга тулы хәзер
Минем өчен таңнар-иртәләр.
Кешеләр дә миңа карап гүя
Сандугачлы тал дип үтәләр.

*«Казан утлары». 1986 ел, 1нче сан.*

## Рифә Рахман

### И Кешем!

Өметләрең сүнсә,
килер нинди көннәр?
Кайсы комлы ярга
борнын төртер көймәң?
Авыр томан басар,
ишкәгеңне ишсәң.
Ашыгып йөзеп китмә,
кемдер исеңә төшсә.

Көтмә аннан ярдәм,
Кеше – ялгыз юлчы.
Дулкыннарга ятса
өметеңнең кошы.
Хәлсезләнгән кулың
үзе алсын аны!
Сулык-сулык дулкын,
ул бит – елга тәне.

Гомер елгасының
шадра дулкыннары,
Комлы, ташлы, сазлы,
сөзгәк, текә яры.
Һәркем соңгы шул яр
өчен яши өркеп:
Булмый дөньялыктан
җиңел генә китеп.
Нинди дулкыннарда
чыгар көймә ярга(?).
Бер өметсез итеп,
бер өметсез итеп...

*«Казан утлары». 2000 ел, 4 нче сан.*

# Ләбиб Лерон

## Бүгенгедән – килер көнгә

Беркем белми аның төгәл яшен
(Яшендәй тиз уза ел-гасыр!).
Борынгыдан бүгенгегә ага
Яшел елга – Урман елгасы!..

Ага... ага... Тып-тын гына ага...
Дулап ала кайчак дулкыннар,–
Шул чагында агачларның шәрә
Тамырлары куя сулкылдап.

Ага... ага... Язгы бозлар сыман,
Кайнап-кайнап, ярга моң таша!
А, сукмаклар – урман урамнары, –
Шул моңнарга барып тоташа.

Җилләр киереп ача изүләрне –
Чәчрәп оча ярык төймәләр...
Су өстендә көз шәүләсе йөзә
Һәм уйнаклый яфрак-көймәләр.

Ага... ага... табигатьнең шашып
Бер көләсе килә, еласы...
Бүгенгедән килер көнгә ага
Яшел елга – Урман елгасы!..

*«Казан утлары». 1985 ел, 7нче сан.*

# Нияз Акмал

## Мәхәббәт

Алдыгызга алсу гөлләр җәям,
Юлыгызга – яшел аланнар:
Мең мәртәбә бәхетледер җирдә
Мәхәббәтен таба алганнар.
Мәхәббәтнең күге – гел кояшлы,
Тугайлары – һәрчак тургайлы.
Мәхәббәтнең таңы – гел былбыллы,
Мәхәббәтнең төне – гел айлы.
Әгәр күңелең мохтаҗлыкка чыкса,
Һәм теләсә синнән бер аклык, –
Бу гөнаһлы җирдә яши алган
Мәхәббәттә генә гөнаһ юк.
Мәхәббәтнең яралавы – дәва:
Язмыш җиле үтсә яралап.
Тик мәхәббәт саклап кала безне,
Тик мәхәббәт кала аралап.
Мәхәббәтнең күге – гел кояшлы,
Тугайлары – һәрчак тургайлы.
Мәхәббәтнең таңы – гел былбыллы,
Мәхәббәтнең төне – гел айлы.
Алдыгызга алсу гөлләр җәям.
Юлыгызга – яшел үләннәр.
Мең мәртәбә бәхетледер җирдә
Мәхәббәтен таба белгәннәр.

*«Казан утлары». 1981 ел, 2нче сан.*

# Факил Әмәк

***

Даһилар җүләр була дип, үз-үзен юаткан җан.
Акыл сатып йөри торгач, үз-үзен югалткан җан.
Һәй, даһилык мөнбәре, күзләр нурсыз, муен төз.
Почмактагы пәрәвездә чебен дулый «без дә без»...
Мүккә поскан үрмәкүч: «Тынуыңны көтәбе-з-з-з!»

*«Казан утлары». 1995 ел. 10нчы сан.*

# Мөхәммәт Мирза

***

Газәл – гүзәллек бакчасы, уз, сылу:
Гөлләр сәламли, кулларың суз, сылу;

Сафлыкка чумган мең төсле манзара
Чакырып тора: икеләнмә – уз, сылу;

Тиңнәрең бар да: сызылган җәя каш,
Иреннәр – ачылган бөре, бүз сылу;

Тик тәкъдирдән кем дә китәлми качып,
Көнчеләр күзе көйдерер – түз, сылу;

Мәрхабәдән бер адымда – мәсхәрә.
Зинһар, үзеңә бул колак-күз, сылу...

Тиңе юк бәхет – сафлык һәм матурлык.
Газәл – гүзәлләр бакчасы, уз, сылу!

*«Казан утлары». 2005 ел, 1нче сан.*

# Фирүзә Җамалетдинова

## Мәйдан

Батырларын, һай, таныйсы килә,
Җиңүләрен килә барлыйсы.
Көрәшләргә мәйдан бүлә халык,
Мәйдансыз да юкса ярыйсы...

Даннар өчен бүлгән мәйданмы бу,
Гыйбрәт өчен бүлгән мәйданмы?
Батырларын заман кемнән сорар,
Ярлыданмы, әллә байданмы?

Мәйдан – энә күзе. Халык бүген
Ир затларын шуннан үткәрер.
Маңгайлардан салкын тир бәрер дә,
Йөрәкләрдән ялкын-ут бәрер.

Бу тормышка җылы, якты кирәк.
Маңгай тире кирәк бу җиргә!
Һәм дөньяның ышанасы килә
Үзен күтәрердәй һәр иргә.

Ышанасы килә ир затлары
Җаннарында мәйдан йөрткәнгә.
Ил язмышын бүләк итеп, кулда
Киләчәккә алып киткәнгә.

...Һәм мәгънәсен тоя белү кирәк,
Хәрәкәттә җиргә иңүнең.
Энә күзләреннән үткән чакта
Аклануы кирәк җиңүнең...

Заман – энә күзе. Халык бүген
Батырларын зурлап алкышлар.
Ышанычы булса, матур килер
Алтын көзләр, аннан ак кышлар...

Бер мәйданда! Бер мәйданда, халкым,
Күккә ашу, җиргә иңүең.
Энә күзләреннән үткән чакта
Их, аклансын иде җиңүең!..

*«Казан утлары». 2012 ел, 10 нчы сан*

## Илсөяр Иксанова

* * *

Җиргә нигә килгәнемне белдем –
Күзләреңә бары бер бактым.
Сөю – эзләп килгән, сине эзләп,–
Яшәү серен ачтым, – Яраттым.

Бер дә юкка яшәү түгел җирдә, –
Мең газабын кичим – үкенмәм,
Җирне җылытырлык сөю калыр
Күзләреңә баккан ул көннән.

*«Казан утлары». 1994 ел, 6нчы сан.*

## Нәҗибә Сафина

### Үз-үземә генә...

Үз-үземә генә ачуланам:
Дулкын кебек «кайта-китәле» мин.
Килеп бәреләм дә ярларыма,
Кабат дәрьяларга китәмен мин.

Үз-үземә генә ачуланам:
Табигатьнең нәни баласы мин.
Үзем генә ярган ярларымда
Елга җыры булып агасы, дим.

Үз-үземә генә ачуланам:
Үз жаныңны тыеп, кыеп кара...
Үз-үземнән киткән мизгелемнән
Җанымдагы һәрбер кыен яра.

*«Казан утлары». 1996 ел, 2нче сан.*

## Җәүдәт Сөләйман

***

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак дөньяга,
Тәңре яралткан җаннармы
Тәңре корган ояда?
Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак үзеңә.
Акыл канат таккан микән
Телгә кунган сүзеңә?

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак җиһанга.
Җиһан чиксез, җиһан тыныч,
Кемнәрдән – тыз-быз, гауга?
Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак, и адәм.
Кемгәдер орчык кына ул –
Без яшәп яткан галәм...

*«Казан утлары». 2001 ел, 6нчы сан.*

Нәбирә
Гыйматдинова

# «САТЛЫКҖАН»

хикәя

1

...Туйды! Егерме биш ел буе руль боргала әле син. Иртә димә, кич димә, шәһәр урамнарыннан кеше ташы, имеш! Тиздән үзенең исемен дә онытмагае Латыйф, аңа бит кушамат белән генә эндәшәләр: «Мотор», «Тәгәрмәч», «Шакмак», «Кучер»... Иң мыскыллы сүз – «Чәйнек». «Командир» яисә «Шеф» дисәләр, кәефе күтәрелә анысы. Хәер, кушамат мәсьәләсендә үзе дә калышмый, аның да пассажирларга тамгасы сугылган. Калтырана-калтырана соңгы тиеннәрен санап бирсә – «додик». Ә кыяфәте! Йа Ходам, тәхеткә кунаклаган патшамыни, күкрәген киереп, алгы утыргычка җәелә. Хәрбиләр – «афанас», үтә дә саран халык, ким дә түгел, артык та түгел, счётчик буенча гына түли. Солдат – «швейк», аңардан коры рәхмәт кенә ишетәсең. Ә менә гаҗәп, йөз-кыяфәте белән җә укытучы, җә галим-голамәгә охшаган затлар бик юмарт, алар чәйлек-шикәрлек калдыра, шуңа күрә Латыйф аларны хөрмәтләп, «галстуклы» дип атый. Көн дәвамында кемнәр белән генә очраштырмый Ходай! Үзара сугышкан ир белән хатын, чыркылдык кыз-кыркын, салонда (караваты диярсең!) селәгәен агыза-агыза гырылдап йоклаган исерек, адресын бутаган хәтерсез карт-коры, колак төбендә «без дә без» безелдәгән «бал корты», ул сиңа туктаусыз нидер сөйли дә сөйли.

Нишлисең, түзәсең. Таксида үзгә дөнья, һәм бу дөньяда бөтен кеше дә буйсыныргa тиеш уртак закон язылмаган, чакрымнарга сыйган кыска гына вакытта кем ничек тели – шулай яшәргә хокуклы иде.

Берсендә соңгы пассажир белән хушлашып, өемә кузгалам дигәндә генә, шык-шык тәрәзәгә кактылар. Кайчакта бомжлар биш сум, ун сум теләнеп теңкәне корыта, такси икән – эче тулы акча төялгән, диләр бугай.

Әмма шыкылдатучы ыспай гына ир-ат иде. Моның маңгаенда йодрык хәтле миң! Гүя акылы миенә сыймыйча тышка бүселеп чыккан. Тәҗрибәле Латыйф бер күз ташлау белән бәяләде: «галстуклы!» Чын, ул аларны хөрмәт итә, тик хәзер беркая да бару-кайту юк, эш сәгате тәмам. Хәтта гафу да сорамый, үтереп алҗытты. Ләкин «миңле» абзый бик әрсез нәрсәкәй иде, рөхсәтсез генә утыргычка кереп тә чумды.

– Карале, кем, иптәш, – диде Латыйф, нәфрәтләнеп. – Төш әле син, төш! Минем көнлек нормам тулды, иптәш!

«Галстуклы» алтынсу күзлек пыяласын эретерлек итеп елмайды.

– Зинһар, выжылдатып кына аэропортка илт, господин!

Ә? «Господин» диме? Ялагайланма, яме, иптәш, бездә байбәтчәләр кучер булып эшләми.

– Өчләтә арттырып түлим, господин.

Латыйф авызын ачып иснәде:

– Аптыратма, ардым, йокым килә, дим.

– Йокыңны куарбыз, господин. Миндә кызык тарихлар күп, сөйләрмен. Германиядә яшим мин, Готһа шәһәрчегендә.

Күзе йомылып, борыны белән руль «чукыган» «господин» башын турайтты:

– Кайда яшим дисең, агай?

– Готһада. Немец шагыйре Гёте туган анда. Әйдә инде кузгал, юлда гәпләшербез.

«Галстуклы» тел бистәсе иде, аңардан йокы гынамы, шайтан да туеп, җәяү качар. Кая ул кара-каршы гәпләшү, үзе генә авыз пулемётыннан аттырды:

– Өченче ай Германиядә мин. Бу чүплек оясына төкердем. Бер тиенлек рәхәте, биш тиенлек михнәте монда. Кешегә эт саны, ә тегендә сиңа бөтен шартлар тудырылган, тегендә синең бәяң – оһо-һо! Алтын син! Бездән генә калган күчешме? Элек тә уптым-уптым ил-җир ташлаганнар. Күбесе эзәрлекләүдән качкан яки революциядән соң большевиклар хакимиятен өнәмәгән. Хи-хи, ул чакта килмешәкләрне колач җәеп каршыламасалар да, сыендырган Европа. Сыендырмый ни, безнекеләр аларның күзенә арыш кылчыгы кебек кадалган: «мин синдә, ашат-эчерт!» Урыс качкыннарыннан ансат кына котылырсың, ди! Аптырагач, боларга вакытлыча сурәтен чәпеп, исем-фамилиясен язып, Нансен паспорты әтмәлләгәннәр. Пособие ише нәрсәләрдән мәхрүм ителсәләр дә, ярап куйган ул. Тора-бара алар илнең тулы хокуклы гражданнарына әйләнгән. Шәп бит! Чүплек оясында кортлар казынсын, әйеме?

Латыйф үзалдына җенләнде. Беренчедән, Готһа турында төпченмәкче иде, кая ул, пулемёт сиптерепме сиптерә. Икенчедән, бәбәген терәп, шушы чүплек оясына кайткан бит әле. Типтем төшердем машинадан, буржуй!

– Башындагы шөрепләре коелмаган кеше моннан табан ялтырата, господин.

– Һа, һа! Синең (илен тамак хакына саткан адәмгә ничек олылап, сез дисең ул?!) табаның киредән безгә табан ник ялтыраган соң, агай?

– Бюрократлар белән көрәштем.

– Үз мәнфәгатьләреңне кайгыртыпмы?

– Оһо, күршенекен кайгыртыргамы әллә? Үземнекен, конечно. Мең бәла белән фатирны саттым.

«Тел бистәсе» сулыш алырга дип, ярты гына секундка тынган арада баядан бирле эче кытыклаган Латыйф соравын кыстырып өлгерде:

– Готһага ничек эләктең, агай?

– Җиңел генә. Бүген чикләр ачык, миллионнар кордон артына агыла.

Яхшы белешем чакырды. – «Галстуклы» муенчагы белән авызыннан бөркелгән кайнар сулыштан тоныкланган күзлеген сөртте. Күзлек ни, машина тәрәзәсе парланды. Лыгырдыкның да иң азгыны бу! – Туксанынчы елларда Вальдемар Казанга килгән иде. Мин бит...

Шушы паузадан тагын файдаланды Латыйф:

– Синәмы? Кунаккамы?

– Бүлдермә, яме? Мин бит экскурсияләр уздыра идем. Җитәкчем әйтә, бер немец ике генә сәгатькә Казанга тукталган, аны шәһәрнең истәлекле урыннарында йөрт, ди. Тарихчы икән кунак, Мәскәүдә халыкара симпозиумда катнашкан да тиз генә Казанга очкан. Русча кылтый-пылтый тәтелди. Моның безгә килүенең сәбәбе дә ачыкланды. Әсир атасын безнең якларга җибәргәннәр, имеш. Ул сугышка алынганда, миңа дүрт кенә ай булган, ди, әтисез үстем, ди. Каберен эзли. Шулай таныштык мистер Вальдемар белән. Миңа ул үтенечен белдерде, әти кайда үлгән, кайда җирләнгән – мәгълүмат җыеп, хат белән миңа юлла, ди. Мин ул чорлар турында әз-мәз хәбәрдар идем, үзем дә мәктәптә өлкән сыйныфларга тарих укыттым. Немец әсирләрен Коры елга бистәсе тирәсендәрәк төрмәдә тоталар. Бер хатын урынын күрсәтте. Бабасы: «Сугыштан соң монда немец солдатлары каберлекләре бар иде», – дигән аңа. Йортка нигез казыганда, кеше сөякләре чыккан, ди. Мистер Вальдемарга монысын язмадым, бигрәк мәнсез халык, каберлекләрне туздырып, өй корганнар димәсен, мәйтәм. Алар да вәхши иде, якламыйм, без күрдек аны... – «Галстуклы» ярасы сызлагандай ыңгырашып, иңбашын уды. – Да-а, күрдек. Без күргәннәре ерткыч фашистлар иде, ә бүгенгеләр ата-бабаларының капма-каршысы, немец яшьләре киң күңелле, мәрхәмәтле, әнә, Вальдемар энекәш мине атасыдай якын итеп, үзендә яшәтә. Бәхет яңгыры яуды миңа, чиләкләп яуды. Аларда кибет киштәләре ризыктан сыгыла, колбасаның гына да унлап төре. Ярлының өйрәсе сыек, байныкы – куе, минем тамак тук, чөнки Вальдемар житештә көн итә. Мин чәчем чаларгач, шушы чүплек оясыннан качтым, ә синең ишеләр безнең белән чагыштырганда, маңка гына, димәк, өр-яңадан тормыш төплисез! Читтә таныш-фәләнең бар икән, икеләнмә, кит!

Бая гына ир «господин» иде, инде менә «маңка». Әмма бу сүзгә үртәлмәде ул, чөнки кытыгы көчәйгән саен көчәя иде. Бәхет яңгыры яуды, ди... Ә Латыйф түбәсенә ни ява? Вак чуерташ!

Авызына җен төкергән агай һава аланына җиткәч тә төшәргә ашыкмады, регистрациясе ике сәгатьтән генә башлана икән. Латыйф юлчының тагын ни-нәрсәләр лыгырдаганын тыңламады да, ишетмәде дә, аның миен бер уй ярып-сызып үтте: «Әгәр без дә китсәк, ә?» Таныш-белеш кенәме, туганлык җепләре белән бәйләнгән кеше яши теге якта... Каядыр китәсең икән, элеккеге заманнардагы кебек «Черек күл»гә чакыртып, колагыңны бормаслар, шәт. Әнә дөньясы капыл гына үзгәрде, Советлар Союзы таркалгач, халык бәйдән ычкынды: демократия, диләр, бәйсезлек, диләр.

...Кулына бөгәрләнгән «йөзлек» йомарлаган ир «галстуклы» артыннан кычкырды:

– Исемең ничек, Миңлеагай?

– Вальдемардан Вилли Траксельгә алыштыртам. Хуш, «Шакмак»!

«Готһа әллә ни зур шәһәрләрдән чутланмый, барган очракта, адреслар кенәгәсеннән табарга мөмкин. Якташ всё тәки!» – дип уйлады ул чакта Латыйф. Ә бу уйдан ни файда иде? Шунда ук тәвәккәлләмәгәч, йә? Аннан соң ике дистә ел узды, һәм хыял, вакыт кыравында өшеп, чәчәген шиңдерде. «Галстуклы» әтисеннән олырак иде, алтмыш җиделәр тирәсе иде аңа. Хәзер менә егерме таяк өстә, димәк миңле агайга сиксән җиде яшь! Балда-майда йөзгәч картаймагандыр Вилли Траксель! Ә Латыйфка нинди исем килешер икән? Ул да үзгәртер, әтисе дә үзгәртер... Иске күлмәк тәнне боза, яңасы кирәк. Ә бит ир тел бистәсенең коткысына тәмам бирешкән, аэропорттан кайту белән китү дәртеннән канатланып, йоклаган әтисен уяткан иде хәтта.

– Әти, әйдә, китик!

Сак йокылы Сәлимгәрәй гаҗәпләнеп:

– Кая? Урамда төн, – диде.

– Төйнәлик тә Германиягә күченик дим, әти!

– Анда нәрсә югалттың, малай?

«Малай» чәчрәп кабынды:

– Монда гомер генә черетәбез, әти!

Әйтерсең, «галстуклы»ның лыгырдык шайтаны аның авызына оялаган иде, Латыйф сүз ташкынына буыла-буыла белгәнен дә, белмәгәнен дә кушып сөйләде дә сөйләде. «Аларда җәннәт... Аларда хөррият... Кешегә хөрмәт... Хезмәт хаклары югары... Кибетләрдә елан итенә хәтле сатыла... Колбасаның гына да әллә ничә сорты... Синең теге кемең безне яхшы йортларга урнаштырыр... Адресы хәтердә...»

Атасы юрганын борынына хәтле тартып менгезде дә кырыс кына:

– Сүгендермә, малай, – диде. – Аш суынмаган, аша да ят!

Ялгышты дуамал ир, бик ялгышты: аңа кисәк кенә «китик» димәскә, күченү идеясен әтисенең күңел туфрагына, җылы яңгыр кебек, әкрен генә сеңдерергә иде.

Вилли артыннан ук «табан» ялтыратмаса да, тормышына бер төзәтмә кертте Латыйф: маршрутын үзгәртеп, аэропорт юлына чат ябышты. Шулай кирәк иде. Озакламый ул да бу «чүплек оясы»ннан арыначак, ә аңа кадәр пассажирлардан күпмедер мәгълүмат туплап, «тегендәге» вазгыятьне өйрәнәчәк. Латыйф инде ике аяклыларны ташый-ташый шактый шомарган, арткы утыргычта кемнең кем икәнен муен чокыры белән тоеп-сизеп бара, нәрсә турында сөйләшәләр яки нәрсә турында бәхәсләшәләр, өтер-ноктасына хәтле мыек очына чорный иде. Чынлап та, биге күгәргән ишек-капкалар ачылгач, ушлы халык чит мәмләкәтләргә ешрак күз төбәде. Башта алар берән-сәрән генә күренсә, ахырга табан шактый күбәйде. Латыйф хәтерли әле: «бәхет иле»нә кыяклаган беренче пассажиры яшь кенә егет иде. Америкадагы иң мәртәбәле уку йортында укыячак, янәсе. Аркасында юка гына биштәр. Кызы, бичара: «Син бүтән кайтмыйсың, американкага өйләнеп каласың», – дип елый-елый озата. «Һи, җүләркаем, точно кайтам», – дип юата егет. Ышанма, кызый, бөтенләйгә кача ул! Сине алдаса да, дипломсыз психолог абзагызны алдарсың, ди!

Ирле-хатынлы Франциягә очты. Икәүләшеп, юл буе шул илне мактадылар. Инженерлар икән, бик солидный оешмага эшкә чакыртканнар

икән. Чакырганнармы, үзләре әрсезләнәме – Латыйфка караңгы, ә менә хыялының бер канаты алар белән һавага күтәрелүе хак иде.

Тегендәге дөньяны ошатмыйча, киредән туган җиренә ашкынучылар булырмы, юкмы? Күзәтте ул. Бәлки андыйларны аэропорт бинасы мәйданчыгындагы коллегалары каршылагандыр, ә аңа, «һай, үз илемне сагындым», диючеләр очрамады. Әлбәттә, кыска гына вакытка кунакка кайтучылар бар иде. «Йә, чит мохит кешене ничек үзгәртә икән! Ашыкмый-кабаланмый ул, тыныч һәм сабыр, машина селкенерлек итеп, ишекне дә япмый. Аның йөзендә һәрвакыт елмаю. Кайчакта бу елмаю сүнеп-сүрелеп ала, оҗмахтан тәмугка төште бит, дөрес, озакка түгел, әмма барыбер шикләндерә...»

Латыйф әнә шундый нәтиҗәләр ясый торды, ә еллар шаулап ага торды. Сәер, китүчеләр арткан саен, кунакка кайтучылар кими иде. Безнең кызлар дәртле икән, «буржуйлар» белән кавышкач сары, ак, кара тәнле балалар табып, эреле-ваклы милләтләрне кинәндерде. Ир күрсәтү модасы башланды. Әйтик, Казан Сабан туенда халык, уеннарга кул селтәп, тәүге негр кияүне генә тамаша кылды. Аклы-каралы парны бәйрәмгә Латыйф үзе илткән иде. Ә берсендә үтә дә таныш сүзләрдән аның зиһене чуалды. Вәт өлгер һәм житез Казан кызлары, немец егетләреннән бала үстерәләр. Әнә, эти-әнисенә сарылган ике юеш борын фатер, муттер диешә. Латыйф шуларга сокланып, әллә ничә тапкыр артына борылды. Каһәр, борылган саен немецның йөзе чытылды. Тыпырчынма, зинһар, ас-таксист юл һәлакәте ясамас!

Заманында «шакмак» дефицит транспорт саналса, соңгы арада ул шактый ук кадерсезләнде. Чөнки кемгә бармак белән төртмә, шәхси машинасында чаба. Аэропортка микроавтобуслар да көйләнгәч, бу маршрутта тиеннәр генә тама иде, ир кабат сөремле шәһәр эчендә болганды. Анда да елгырлар үзбаш эшләүчеләрне кысрыкларга тотынды: таксопарклар оештырып, үзенә куып кертте. Кермәсәң, йә машинаң яна, йә башыңа тимер белән оралар. Йөз сум эшлисең икән, иллесе – бандит «хуҗа»га. Монысына да күнде Латыйф. Ә күнәргә теләмәгән «кучерлар» шыпан-шыпан качкач, аңа ике норма бирделәр. Акчасын икеләтә арттырсалар, хурланмас та идең, юк, әлеге дә баягы: «миңа – учлап-учлап, ә сиңа – чеметем-чеметем».

Тиздән аның бармаклары рульгә берегеп катачак иде. Хуҗаның өстәленә гариза ташлагач, машинасын гаражга бикләп, өенә ашыкты ир! Бу карарына үкенмәде, чөнки туйды! Әле эңгер-меңгер генә, этисе йокламаган иде, моңарчы ялынган төсле: «Китик тә китик» дисә, хәзер ишектән үк гайрәтле тавыш белән шар ярды:

– Китәбез, эти, китәбез! Анда сиңа фатер дип эндәшерләр, Алла боерса. Боерыр, боермыйни! Кая минем солдат альбомы? Биш былтыр актарган юк, тузан кунмадымы икән?

**2**

Тузан кундырмады аңа Сәлимгәрәй, кундырмады. Улы күрмәгәндә яшереп кенә, альбомының дүртенче битендәге сурәткә караса, тәне чемердәп куя, чөнки һаман да төсе уңмаган фотога акай бәбәкле курку оялаган иде. Кәгазьгә җаныннан күчкән, ахрысы. Кызганыч, ул дөньяга

адәм баласы кыяфәтендә туса да, тычкан төсле ярыкка посып яшәде. Җәмгыять аруланып, үткәндәге шомлы төннәр йомылып-йотылып бетте, Сәлимгәрәй генә, иң явыз, иң мәкерле «ата мәче» тишектән чыкканымны сагалап, үткен тырнагын батырыр, дигән шиктән котылмады. Сиксән биш яшендә кеше фанилыктагы мәшәкатьләрен киметеп һәм дә юк-бар уйлардан арынып, «мәңгелек йорты»на әзерләнә. Аның әзерлеге ташка үлчим бугай, югыйсә шушы куркуы йөрәк маен сызмас иде. Ул бу сүзне моңарчы да ишетә, ләкин колагына элми, Латыйфның саташуы дип тынычлана иде, ә бүген хәлләр саташудан узган: улы кабарынган-күперенгән, күзе тишегенә сыймыйча, маңгаена табан атылган, моның эш ташлавы да катгый карар кабул итүенә бер мисал иде.

– Альбомың шкаф тартмасында, – диде карт, мышнап. Мышната иде шул. Латыйфны ниятеннән тыйлыктырырлык контрһөҗүмгә күчәр өчен арыслан койрыгын өзәрлек усаллык кирәк иде.

Барысына да үзе гаепле. Беркем дә авызын җимереп, теленнән тартмады. Баласы – якын кешесе, имеш.

Латыйф та «сурәтләр китабы»ның дүртенче битенә төртелде.

– Да-а, эти, охшасак та охшарбыз икән туганым белән! Әкәмәт инде. Тагын кабаттан сөйлә әле әсирлектәге маҗараларыңны, эти! Җә, сез чолганышта каласыз, һәм һоп-паля, немецлар сезне Германиягә куалый! Шуннан?

Улы аның яралы бәгыренә тоз сибә иде.

– Бер тапкыр сөйләгән – булган! Әкият түгел ул сиңа, малай!

– Җә инде, эти, дулама. Безнең паспортлар шкафтамы? Иртәгә миграция бүлекчәсенә барып, чит илнекенә бланк тутырабыз. Аннары туристик бюрога сугылырбыз. Германиягә сәяхәтчеләр сыйфатында чыгарбыз, эти. Готһаның үзенә үк юлланырбыз, бәлки. Нигә дәшмисең, эти?

Кайсы төштә өзеп кенә дәшәргә соң? Латыйф дәресен ятлаган укучы бала кебек тырылдата:

– Аларда кеше кадерле... Аларның картлары диңгездә, ял йортларында ял итә... Ә синең хәерче пенсияң утка-суга гына түләрлек... Мин эшләп, ни оттым? Хәерче тиеннәргә тир түктем, шуңа хатын да аерылды миннән... Кайчаннан бирле фатир ремонтланмаган... Элгечтәге пинжәгең дә хан заманыныкы! Ыстырам, эти!

– Ул өр-яңа, улым. Тукымасы чыдам аның. Мин аны чистага-рәешкә генә киям, – диде Сәлимгәрәй. Күсәк малайны җиңәрлек нинди дәлилләр китерим дисә, менә сиңа берсе! Башкасы юк, шуңа күрә телеңне тыюың хәерлерәк. – Башымны катырма, улым. Өч көннән безнең репетиция, яңа җыр өйрәнәбез. – Бәрәч, монысы да дәлил ләса: «Ветераннар» хоры яңа җыр өйрәнә!» Улы: «Үзең белән бергә туган», – дип хурласа да, гармун картаерга ашыкмады, ул хуҗасының күкрәк җылысын тоеп, гомер чикте. – Әзрәк бармаклар язылыр, көен уйныйм.

Әмма Латыйфның үз «көе» мөһимрәк иде, ир инде ярага тоз гына сипмичә, үткен пычак белән телде:

– Әти, гарьлек! Бу ил нишләткән сине, йә?! Кырык биштә сатлыкҗан дип, хәрби төрмәгә тыккан! Шуңа полкташларыңның ник берсе синең белән аралашсын, эти!

– Ник аралашмасыннар, ди, батальон командиры белән очрашып торабыз.

Әлеге «очрашу» турында тәфсилләп сөйләсәң, Латыйф: «Тфү, адәм ыстырамы!» – дип төкерәчәк кенә, хәер, аның сөйләрлеге дә юк, гыйбрәт иде ул. Шөкер, улы кызыксынмады, иске гармун күрегенә бармагы белән сызгалап, үзенекен тукыды:

– Китәбез дигәч, китәбез, эти! Бу сәләмәңне тәрәзәдән болгап ат, тегендә нимеч аккордеонында сайратырсың.

Булыр сиңа сәләмә! Аның эчендәге моңнан җиһан тетрәнеп елар иде. Адәм төслүк тере иде ул, тере. Мәрхүм атасы үгез саткан акчага юнәткән иде аны. И, рәхәтләнде клубта кыз-кыркын яшүсмернең бию көйләренә тыпырдатып! Дәрәҗә үсте: туйларда – табын түрендә әүвәл гармун белән Сәлимгәрәй кунаклар иде. Зур томшыклы сугыш каракошы бөртек итеп, алар авылындагы ир-атларны да чүпләде, унсигез яшьлек егет тә фашистлардан үч алырга фронтка ашкынды. Хуш, сәгать сукты, Сәлимгәрәй стансага хәтле атасы җиккән колхоз аты арбасында гармунда уйнап барды. «Сакла» дигән иде, саклаган атасы. Авыл капкасыннан көтү-көтү чыгып киткән ирләр төркеме сыекланган: кайсы кулсыз, кайсы аяксыз, кайсы күзсез иде. Сәлимгәрәй дүрт саны да сау-сәламәт килеш кайтачак иде дә... Туган җирләргә юл киселде шул. Икенче Белоруссия фронтында сугышканда, аларны төрле яктан немецлар камады. Җүнләп дары исе дә иснәмәгән егет чапкан камыш төсле берәм-берәм егылган иптәшләренең мылтыгын җыйды, ядрәләр әз, соңгысы – үзенә... Дошман ут чәчә, күккә тузан болыты күтәрелә. Әйе, соңгы ядрә үзенә... Кинәт янында гына берәү ыңгырашты. Батальон командиры! Ике кулыннан кан саркый. Аны солдатлар яратмый, үзара «бирән» дип тиргиләр иде. Кыр кухнясы ниндидер сәбәпләр белән тоткарланса, сугышчылар биштәрендәге каты-коты белән генә чикләнә, ә менә офицерларның тәгаме мул да, туклыклы да, аларга өстәмә паек бирелә һәм бу паекта авыз суларын китергән сары май була иде. Ипиенә калын итеп яга иде шуны «бирән». Ул тәмләп-тәмләп чәйнәгәндә, аңа йөзәрләгән ач күз текәлә... Җитмәсә, бермәлне кичләрен солдатларның күз күреме начарайды. «Тавык күзе бездә», – диде Алёша исемле абзый. – Май ашасаң әйбәтләнә, ди, үзе». Менә командирның терсәк тиңентен умырылган «майлы кулы»ннан кан ага. Алда немецлар акыра, артта авылдашы Әмирҗанның тавышы:

– Сәлимгәрәй, урман ешлыгына үрмәлә!

Егет яралыны чокырга сөйрәп төшерде дә учлап-учлап, ярасына туфрак сипте. Балачакта аяк табанын пыяла киссә, әниләр шулай «дәвалый» иде.

– Кымшанма, үлгәнгә сабыш, командир!

...Үрмәли, үрмәли, үрмәли... Бәй, нишләп гәүдәсе авырайды икән соң?

Машина әрҗәсендә генә аңына килде ул. Сукканнар, үтереп баш чатный иде. Сәлимгәрәй – тоткын, димәк, соңгы ядрә атылмаган. Әрҗә тулы әсирләр. Ул күзе белән генә Әмирҗанны эзләде. Юк Әмирҗан... Кая илтеп атарлар икән дисә, атмадылар. Илләр-җирләр аша концлагерьга кудылар. Беркөнне әсирләрне ишегалдына тезделәр. Кайберәүләр ачлыктан хәлсезләнеп, шап та шоп егылганда, егет үкчәсен җиргә ныграк кадарга тырышты. Ничек тә аумаска! Ауса – бу ерткыч бүреләр үлекләр барагына ыргытачак. Капкада

гражданский киемнән өч немец күренде. Ник атмаганнары беленде: Германиянең икътисады өшәнгән, эшче куллар кирәк икән.

– Безне коллыкка саталар, – дип пышылдады янәшәдәге әсир. – Может яхшырактыр монысы, может качып булыр, товарищ?

Өчәүнең берсе кол сайлап вакланмады, туп-туры Сәлимгәрәйгә табан атлады. Тәбәнәк буйлы, такта корсаклы ябык фрицка кизәнеп сугар дәрәҗәдә нәфрәтләнгән егетне немец офицеры сафтан этеп чыгарды. Саттылар... очсыз гына бәягә... «Качып булыр» дип җилкендергән өмет томандай таралды: «колбиләүче» алдан ук чарасын күргән, мотоцикл бишегенә чак кына сыйган Сәлимгәрәйне аяк-кулын чылбыр белән богаулады, чәнчелеп киткере! Тынчу барактан соң борын канатларын киереп, саф һава сулаган егет йокыга талды. Кара син, кызлар аның көенә ничек матур бии! Клубның идән тактасы чыдасын гына!

Дырыт-дырыт... Идән сынды... Юк, Сәлимгәрәй төшләнә иде. Мотоцикл дыр-дыр юл читендәге сарай сыман корылма турысында шып туктады. Немец богауларны чиште һәм ишарә белән генә торырга кушты. Озак килгәннәр, ахрысы, аяк оеган. Капчыкмыни, җиргә ишелде егет. «Колбиләүче» сарайдан кәтмән алып тоттыргач кына, ул айныды: вәт могҗиза, бәрәңге басуы! Хуҗа аңлатмаса да, бурычы ачык иде: бәрәңге җирен йомшартып, төбенә өясе. Авыл баласына таныш һәм дә ки тансык эш. Ашказаны талапмы талый, мәгәр немец сакламаса, казып чи бәрәңге кимерер иде Сәлимгәрәй. Ашау мәсьәләсендә бу саран кинәндермәс, үзе дә бауга элеп, җилдә киптергән балык төсле.

«Такта корсак» аның ниләр уйлаганын сизенгәндәй, халат кесәсендә капшанып, кәгазьгә төргән ипи кисәге сузгач, җиде бармагын бөкте, әһә, кичке җидегә кадәр эшлисең, димәкче. Сакламый, шөкер.

Ипи телеме каткан иде, аны төкерегә белән юешләтә-йомшарта тамагыннан шудыргач, ниндидер көч инде. Ашаудан түгел, ул тәгам кече телгә дә җитмәде. Сәлимгәрәй кырда япа-ялгызы, еракта – ике-өч чакрымда утар шәйләнә. Качарга! Тик ничек качарга? Җәяү генә әллә ни элдертмәссең, постларга юлыгуың да ихтимал, кичкә хәтле түзсә... Әйе, түзсә, «колбиләүче» аны кирედән концлагерьга илтәчәк.

Кулда тимер кәтмән, шалт моның баш чүмеченә! Төрмә киемнәрен җиргә күмәсең, җирәнсәң дә аныкын киясең. Мотоцикл инде синең карамакта. Кай тарафларга юырттырасың – анысын уйлама. Их, туган илкәй-бәгырькәй, кошка әверелсә, корыган талыңа да очып кунар иде Сәлимгәрәй.

Нигәдер бәрәңге казып ашарга базмады ул, аның өчен урлашу түбәнлек иде. Һава белән тукланды бугай, аннары качу хәсрәте тамактан хәтәррәк иде.

Тыр-тыр... Тыр-тыр... Әһә, фриц калдыгы әҗәленә ашкына. Мотоцикл якыная башлагач, гаҗәпләнүдән кат-кат күзен уды егет. Җен алыштырганмы соң, моның пеләш башына чәч үскән, дисә... Яшь кенә хатын-кыз! Немец фраулары дөньяның бер явызы: әсирләр урамнан узганда, өсләренә шакшы әйберләр ыргыталар иде. Сәлимгәрәй кәтмәнне тагын да ныграк кысты. Синнән мыскыллатмас ул, битеңне ярыр!

Кыз мотоциклдан төшкәч, аңа кул изәде. Кил, ди, явыз. Теге «колбиләүче»нең йә кызы, йә сеңлесе бу. Хуш, ир-атка караганда, моның

белән «исәп-хисап» ясавы җиңелрәк. Үтерерлек сукмас Сәлимгәрәй, миңгерәтеп кенә калдырыр.

Егет буразна арасыннан айкала-чайкала (хәлсезлек!), фрау хозурына килеп басты. Кыз шоколад ялый иде. Менә ул яртысын сындырып, аңа бирде, менә Сәлимгәрәйнең сугарга җыенган кулы аска салынды.

– Хелло, ихь хайсэ фраулеин Софи, – диде кыз.

Сәлимгәрәйләрне мәктәптә әзрәк немецча укыттылар, ул укыту, билгеле, бик начар иде, алай да кайбер сүзләр хәтердә. Фраулеин икән, кияүдә түгел.

– Ви хайст ду?

Әче шоколад авызны бөрештерде. Мин – Софи, ә син ни атлы дип сорый бугай. Ни пычагыма сиңа минем исемем, фраулеин-мраулеин?!

Ул күкрәгендәге 1520 санына төртте. Укы, сукыр!

– Рус манн?

Егет сүгенмәкче иде дә, яхшысынмады, ни дисәң дә кыз бала бит. Ул аңламаса – җил аңлар, бәлки бу җил туган илкәйләрдән үк исәдер.

– Нинди урыс? Татар малае мин, – диде әсир татарча.

Софи искәрмәстән генә бармагында эрегән шоколадны аның иренենә сылады. Шаяра, әкәм-төкәм, шаяра! Яшьлек яшьлек икән шул, бермәлне Сәлимгәрәй үзенең кол икәнен дә, дошманның бәрәңге басуында әлсерәп торуын да онытты, күңел сыздырып, гармун уйнап җибәрде. Бие, әйдә, фраулеин Софи, бие! Кызды егет, куллар гармун төймәләренә баскаласа, авыз көй такмаклады: иллә-лә, иллә-лә... Ниткән фриц кызы, ди, үзләренең авыл чытыгы Әлфия ич! Аякларын чалыштырып, тыпыр-тыпыр биюләренә кадәр җанга ятышлы. Нишләп аның болай да ап-ак йөзе агарды әле? Тими сиңа Сәлимгәрәй, тими.

– Фатер, фатер! – Кыз юлга күрсәтте. Ә аннан велосипедта теге «колбиләүче» җилдерә иде. Фатер... әтисе икән. Немецның күзе-башы тонган иде, ул кызына акырды-бакырды, Софи мотоциклга утырып киткәч, колның да язмышы хәл ителде: бая гына гармунда өздереп уйнаган кулларын богаулап, сарык төсле сарайга яптылар аны. Өем-өем капчыклар өстенә ауды егет. Өн белән төш буталды. Акбур йөзле Софи (чирләшкәдер, мөгаен), хыялдагы гармун, шашкан фатер... Бәлки, Сәлимгәрәй икенче үлчәмдәге дөньяда адашкандыр, ә? Концлагерьга озатканда качарга! Ничек тә качарга!

Мәрхәмәте уяндымы икән, кичкырын немец аны тавык боты белән сыйлады. Аркан аварлык таланты да ачылды: урысча сөйләргә маташуы кызык та, көлке дә иде:

– Кача солдат кая... Сак күп... Асалар солдат... Үлә солдат...

Өтек-өтек сүзләрдән Сәлимгәрәй төзек җөмләләр төзеде тагы. Моның өченче буын әбисе унсигезенче гасырдагы Русьта ун ел гувернантка булган. Атасы урысча сукалаган, ул да сукалый, имеш. Софига бу телнең хаҗәте юк, ул затлы немка, имеш.

Мактан-мактан, калай әтәч, хәзер сарайда ук муеныңны борачак колың. Тавык боты хәлләндерде бераз. Кинәт тышта мотоцикл тырылдады. Немец мәче җитезлеге белән сикереп, егетнең кул-аягына богау кигезде. Шатор-шытыр ишек тә бикләнде. Күзен кысып, такта ярыгыннан караган Сәлимгәрәйнең шунда ук өмет шары шартлады. Чынлап та, адым саен сак.

Төнлә дә юлда тыз-быз чабыштылар. Иртән тагын тавык боты (ярый әле йорт кошы ике тәпиле!) китерде хуҗа.

– Ник мине кунарга концлагерьга кайтармыйсың? – диде тоткын, аның «колбиләүче» белән аралашу дәверендә бу беренче соравы иде.

Йә уртасында, йә койрыгында «ватылган» сүзләрне бергә укмаштыргач, куркыныч җөмләләр оешты. «Анда минем яхшы таныш. Сине ярты елга алдым. Кичә тикшермәкчеләр иде, солдат, шул танышның исемен әйтеп кенә коткардым үзеңне. Ерткыч алар, кыйнап имгәтерләр иде. Алар шуннан тәм таба».

«Алар ерткыч», – дип, нишләп үз кавемен хурлый әле бу? Немец аңа кулын сузды:

– Ганс.

Егет күкрәгендәге саннарга ияген тидерде:

– Мин – 1520!

Немец белән дуслашуның хаҗәте юк, ул дошман иде. Ганс абзыкай норма билгеләгәч тә, балчык изгәндәй, бер урында таптанды. Кайгысы күкрәгенә бөялгән икән. «Софиның абыйсы Гитлерга каршы оештырылган яшерен оешмада торган. Баганаларга нацистларга каршы листовкалар ябыштырганда, аны тоталар һәм сеңлесе күз алдында җәзалап үтерәләр. Софи шуннан соң җүләрләнә. Акылга җиңеләймәсә, урыс солдаты янында бөтерелер идеме, балакай...»

Кызганмады Сәлимгәрәй, андый хис аңарда корыса да, гаҗәпмени, ул бит үзе дә карчыга тырнагында тыпырчына иде. Алга табан вакыйгалар куерган саен куерды. Бәрәңге казылып, саклагыч базларга тутырылгач, хуҗа әсирне утарга кайтарды. Ашау рәтләнде, Ганс инде эткә ыргыткан кебек сөяк кенә ташламады, табындагы тәгаме белән бүлеште. Егет көрәйде. Әгәр туган җирен, әти-әнисен, моңлы гармунын сагынып саргаймаса, шушы Готһада исән-имин Җиңү көнен каршыларга мөмкин иде. Һичшиксез җиңәчәк иде безнекеләр... Гармун дигәннән, Софи аңа абыйсының аккордеонын чыгарып бирде. Билгеле, кызының тотык солдатка сырпалануын өнәмәде Ганс, әмма элек йә шаркылдап көлгән, йә үкереп елаган тилемсәнең үзенә юаныч табуы, хәтта ки олылар сыман җитдиләнүе ата кешенең күңелен йомшартты. Аккордеон ят нәрсәкәй булса да, тиз өйрәнде Сәлимгәрәй. И, сибелде татар көйләре утар ишегалдына, и, очып-очып биеде фраулеин Софи!

Төнлә даң-доң утар капкасына типтеләр. Кышка җылытылган өйалдында йоклаган егетнең күзе чагылды: унлаган мотоцикл фарасы хуҗаларның тәрәзәсен яктырта иде. Ганс, акылдан язгандай, аны аягыннан сөйрәде:

– Солдат... Арткы ишек... Баз... Софи, син кач! Палачлар... Тыгынырга йөри... Алар улымны үтерде... Алар котырган... Сезнекеләр җиңә, солдат...

Тирән казылган баз зур иде, Сәлимгәрәй өч капчык бәрәңгене янәшә куеп, кызга урын әзерләде. Ә үзе почмактагы салам өеменә сузылды. Бәрәңге исе таралган дымлы һава ютәлләтә башлагач, Софи торып, учы белән аның авызын томалады. Янәсе, ишетмәсеннәр. Өйдә ишетерлек түгел, исерек немецлар бәйрәм итә иде. Кыз кочакка ук елышып, аның янәшәсенә ятты. Кытыршы яңакны сыйпаган куллар каз мамыгыдай йомшак иде...

«Сезнекеләр җиңә, солдат...» Әлеге куанычлы хәбәр ешрак кабатланды. Апрель башында Ганс зарыгып көткән бер сүз әйтте: «Гитлер капут». Ә берсендә кайдадыр йөреп кайткан хуҗа аны тышка әйдәде. Тагын аяктан егарлык хәбәр: Американнар концлагерь әсирләрен азат иткән! Гансның тәкъдиме исә бөтенләй акылга сыймады: «Бездә кал, солдат. Илем-җирем дип, монда яшә. Син кызымны терелттең, мин сиңа мәңге бурычлы. Бөтен мал-мөлкәтемне Софи белән икегезгә бирәм».

– Рәхмәт, калмыйм, – диде Сәлимгәрәй. – Авырсынмасаң, концлагерь капкасына хәтле илт! Туган ил бер генә була, абзыкай. Хәзер Софи белән хушлашам да.

Ганс колак төбендә ысылдады:

– Хушлашма... Кит, солдат.

Ә илдә хәлләр мөшкел, әсирлектә җәфаланганнарны тикшереп, җелегеңне киптерәләр иде. Сатлыкҗан, шпион, дезертир... Кайсы белән «бүләклиләр?» – ризалаш. Кырык җиденче елда гына ул туган авылына кайтты, аңа хурлыгы да ияргән иде. Иң әүвәл авылдашы Әмирҗан:

– Немечләргә син үзең бирелдең, без калдык-постык исәннәр урманга качканда, син юри артта мыштырдадың. Минем тәндә өч ярчык, синең тырналган җирең дә юк, син – сатлыкҗан, – диде. Соңра колхоз рәисе буявы кыршылган өстәлгә йодрык белән сукты:

– Бездә сиңа нинди эш! Син – сатлыкҗан!

Өйдәгеләр сау-сәламәт улларына бер сөенсә, ике көенде. Авыл шаулый... «Сәлимгәрәй сатлыкҗан икән!» Атасы:

– Гармуныңны кыстыр да калага кит, улым, – диде. – Кит тә үз көнеңне үзең күр.

Кайда сиңа табагы белән аш сосканнар соң? Шөкер, өйләнде, хатыны сырланмады, чөнки сугыш ир затының санын нык киметкән иде. «Көн күрүләр» җиңел түгел, «үткәндәгеләр» җүнле эшкә урнашырга аяк чалды. Казанның Мехчылар клубында җыр ансамбле оештырганнар иде, аны шунда гармунчы итеп алдылар. Алтмышынчы еллар тирәсе иде бугай, ул урамда командирны очратты. Исән «майлы кул»! Чаттагы ашханәдә тамак ялгадылар. Көйгән котлет белән бәрәңге боламыгына Сәлимгәрәй түләде. Аның каравы Тарасовның зары бушлай иде.

– Сугыш ветераннарына мөнәсәбәт начар, әйеме, Камалов? Ни фатир, ни акча. Шушы ил өчен кан койдыкмы без, әйеме, Камалов?

– Ил үзе дә тернәкләнмәгән әле, яңа туган бәбкә кебек ул, йонын йолкымыйк, безгә дә чират җитәр, – диде гармун остасы.

Командир ыржайды:

– Миңа җитәр, ә сиңа врядь ли, син бит сатлыкҗан, Камалов!

Сәлимгәрәй өстәл аша гына үрелеп, «бирән»нең якасыннан каптырды:

– Рәхмәтең шушымы, бәдбәхет! Сине коткарганда, башка сукканнар!

Этҗан артка табан тартылып, аңардан ычкынды:

– Кызма, Камалов! Әгәр ике кулын күтәреп, үзе немецлар каршысына чапты дип, органнарга тишсәм, хана сиңа!

Ачудан сабын сындырган алюмин кашыкны Тарасовның бушаган тәлинкәсенә бәрде ул. Моннан ары юллар кисешмәс дигән иде, кисештерә икән язмыш. Җиңү көненең егерме биш еллыгы уңаеннан Сәлимгәрәйләр

хоры (ул инде икенче оешмада штатта иде) патриотик җыр җырларга тиеш, алар соңгы репетициягә үзәк мәйданга – Ленин һәйкәле каршысына җыелды. Чыгышлары тәмамланганда гына, үзәктә почык борынлы экскурсия автобусы туктады. Гидның теле телгә йокмый, кулындагы таягы белән әле опера театрына, әле юлбашчыга күрсәтеп сөйли дә сөйли. Чү, таныш тавыш! Тавыш кынамы, таныш йөз! «Майлы кул» Тарасов! Күзе очлы икән, ул да Сәлимгәрәйне күрде һәм төркемгә:

– Бу безнең ахыргы тукталыш, таралышабыз, иптәшләр, – диде. – Исәнме, Камалов?! Теге чактагы өчен гафу ит, яме? Шаярттым мин, нишләп органнарга чагыйм, ди, сине! Тәки ветераннарга сан юк, ни ташламасы, ни дәвасы. Үги балалар без бу илдә, әйеме? Ил башта тернәкләнсен, дисең, тернәкләнми, Камалов! Мин Германиягә таям. Әйдә, минем белән, калган гомеребез рәхәттә үтәр, әйдә!

Сәлимгәрәй гармунын аркасына асты. Шушы адәмгә кәлимәм корыган дисә, күңел төпкелендә бер сүз бар икән:

– Туган җир бер генә була!

Тормыш дәфтәреннән бу этрәк-әләмне сызып атса да, беркөнне Кирмән тирәсендә йөргәндә, ул төркем иярткән экскурсовод хатыннан:

– Тарасов сездә эшлиме әле? – дип сорады. Ялгышып, әлбәттә, «майлы кул» аның өчен бер тиенлек бакыр иде.

– Валерий Тихоновичмы? Ул күптән Германиядә яши бит, – диде марҗа.

Өченче мәртәбә очраштырма дип теләгән иде Сәлимгәрәй, Ходай: «Чү, быжгыма, колым!» – дигәндер, егерме биш елдан соң кабат күреште алар. Кайда? Әйтергә дә оят...

**3**

Әтисе ничек үтләми икән: иртә дә гармун, кич тә гармун. Картаерга исәпләми, ахрысы. Картаймасын! Алда тылсымлы дөнья ишекләрен ачкач, һай, яшәүнең чын тәмен татыр картлач! Латыйф та уяу, йоклар иде, хыялы керфеген кургашын белән катырган.

Ир караватастындагы солдат чемоданында актарынды. Бил каешы, портсигарет, пәке кебек вак-төяк арасында кадерле әйбер: нейлон немец күлмәге бар иде. Кызлар янына барганда да киде аны Латыйф, өйләнгәндә дә, өстендә шул иде, тузмады-черемәде күлмәк, хуҗасы тазаргач, кечерәйде генә. Күрәзәче икән ул! Белеп ертмаган күлмәкне! Аның тарихы да кызык иде. Германиядә совет гаскәрләре төркемендә хезмәт итте егет. Беренче танк армиясенең ракета дивизионы Эйзенах таулары юнәлешен һава һөҗүменнән саклады. ФРГ чигенә кадәр нибарысы унсигез чакрым. Җәен дә, кышын да ап-ак тау өстендә әледән-әле тилгәннәрмени, Америка очкычлары әйләнә, андый чакта кизүдәге батареяга әзерләнергә боералар: тәгәрмәчле җайланмалардагы ракеталар АКШ очкычларына төбәлә, әмма ике як та тыныч кына «аерылыша». Сентябрь аенда Латыйфларның батареясы кизүдән азат иде. Командир: «Бөркетләр, немец кооператоры бәрәңге алышырга ярдәм сорый. Дусларга булышасы иде. Кемнәр барырга тели?» – дигәч, унлап солдат төялгән машина Готһага кузгалды. Шәһәргә якын гына база янында аларны хуҗа көтә иде. Шунда шаккатырлык хәл булды,

«служаклар» карашын әле немецка, әле Латыйфка күчерде. Алар бер-берсенең күчермәсе кебек, алман ире аңардан олырак кына иде. Ике «күчермә»дән кала барысы да көлешергә тотынды. Нинди генә фаразлар кылмады шаяннар: «Бу немец Берлинны яулаган совет солдаты малае... Ә солдат кем? Камаловның атасы! Сугышта катнашкан, точно ул!»

Латыйф иң якын дусларына да әтисенең ничек пленда газаплануын ычкындырмый, чөнки әсирлек – нәсел хурлыгы иде.

Көлештеләр дә эшкә тотындылар. Бурыч гади генә иде: транспортер лентасыннан тәгәрәгән бәрәңгене капчыкларга тутыру. Җайланма тиз хәрәкәтләнә, капчык тиз тула, аның авызын бәйләп тә өлгерергә кирәк, арыды «служаклар». «Җир алмасы»н эрегә-вакка аеру белән мәшгуль Латыйф техника авызы алдына басты. Кырык минут эшләде егет, тәнәфестән соң тагын җайланманы кабызды. Хуҗа канәгать иде. Арадан аны гына сайлап, киемнәр кибетенә алып киткәндә, хезмәттәшләре көнләшкәндер, мөгаен. Бик матур күлмәк бүләк итте аңа немец! Юл уңаенда салонда икәү фотога да төштеләр. Атна-ун көннән сурәтне командирга китереп биргән юмартҗан.

Күлмәге дә, фотосы да вакытлар узу белән әһәмиятен югалтыр иде, әгәр дә ки... Икейөзле әтисе ничәмә-ничә еллар битлек астында коточкыч серен яшермәсә. Латыйф хәрби бурычын үтәп, Казанга кайткач, Сәлимгәрәй Габбас улы бик сәерләнде. Кат-кат кооператив базасы турында сорашып интектерде, солдат альбомы да аның бүлмәсенә «аякланды». Әллә битлеге йөзен кырды, әллә вөҗданы уянды, беркөнне ул:

– Тыңла әле, малай, – диде. – Мин концлагерьда озак җәфаланмадым бит. Теге фотодагы немец синең абыең булмагае...

Әтисенең маҗаралы хикәяте Латыйфның тәнендәге бала йоннарын кабартты.

– Дөньяда өч кеше бер-берсенә охшап туа, диләр. Туа, пычагым! Синең төсле орлык чәчеп йөрүчеләр әзмени! Ник биш былтыр ук, әни исән чакта боларны сөйләмәдең, әти?!

– Курыктым, малай. Әле дә шүрләтә. Безнекеләр төрмәгә япканда, төбенә хәтле казынып тикшерсәләр, эш харап иде.

– Менә ни өчен син гомер буе бөрешеп-куырылып яшәгәнсең икән, әти. Синең хәтта сугыш ветераны кенәгәсе дә юк! Әнә аларга хөкүмәт әз-мәзләп акча тамызгалый, ә син бер хәерче гармунчы!

– Дөньяга чәчә күрмә, ни ишетсәң – йотып җибәр, малай!

Йотар, ди, Латыйф, йотмады. Дөньяга да чәчмәде. Сөенечле хәбәрмени! Ир-ат сугышта кан койганда, әсир Сәлимгәрәй фраулеин назыннан «эрегән»... Башта хурланган иде егет, ил-көндәге кискен үзгәрешләр, социаль гаделсезлек, кемнәрнеңдер халык милкен үзләштереп (урлап!) баюы, ә кемнәрнеңдер күтәне чыкканчы эшләп тә хәерчеләнүе фикерен үзгәртте, моңа таксида аэропортка илткән пассажирларның ни өчен туып-үскән җиреннән «табан ялтыратуы» да өстәлгәч, Латыйф үз-үзенә: «Тиле син, егет, бай абыең табылуына шатлан», – диде. Әнә теге миңле абзый бөтенләй чит-ят кеше йортында оялаган, ә монда кан туганың!

Шуннан бирле «китик» дия-дия атасын игәүләп, күпме вакыт сарыф

ителде. Инде игәүне ныгытып үткенләде ир: таң аткач та «фатер» белән юл хәстәренә керешәчәкләр.

Киребеткән атасын җиңел генә бөгәрсең, ди. Иртән аның караваты буш иде инде. Җәймә өстендә дүртенче битендәге фотосы куптарылган солдат альбомы... Әбәттә генә «борынлады» картлач. Ул чабышкы аты кебек әлсерәгән иде. Латыйф шелтәләгән тавыш белән:

– Кайда идең син? Паспорт бүлекчәсендә халык көтүе, кояш белән бергә чират аласы! Абый белән безнең фотоны син нишләттең, әти?! – диде.

– Челтерәмәле, малай! – Сәлимгәрәй карт тезләрен угалады. – Шәһәрдәге чүплек әрҗәләрен әйләнә-әйләнә буыннар сызлый. И картлык галәмәте! Атна элек былчыракта актарына иде. Знамы, ашарга эзләп. Таныш приют директоры китер дигән иде. Юк кына бит!

– Кем юк, әти, кем? Мәчеме?

– Ниткән мәче! Командир Тарасов! Герман иленнән Казанга кайтып егылган. Хуҗам урамга куды, ди. Өсте-башы пычрак, елый, мескен.

– Ул Тараслар сиңа пычагымамы, әти?!

– Җан иясе бит, мескен.

– Син үзең мескен, әти. Ни пенсияң, ни һөнәрең, ни...

Сәлимгәрәй карт таягы белән идәнгә кадады:

– Акыл сатма, малай! Куркып яшәсәм дә, мин тормышыма шөкерана кылам. Суласам – үземнең һавам, бассам – үземнең җирем! Артыгы кирәкми миңа!

Латыйфка ничек тә әтисен көйлисе-җайлыйсы иде. Мәгәр бәхәсләшсәң, тәртәгә шалт иттереп тибәчәк, һәм аннан хуш, ымсындырган бәхетләләр иле!

– Әти, чәй эчәсеңме?

– Эчмим, әйдәле, машинаңны апкайт, улым. Тарасовны табып, приютка урнаштырыйк.

...Шәһәрдә урам саен чүп савыты иде. Унберенче «әрҗә» кырыендарак әтисе туктарга кушты.

– Әнә ул, чүплектә актарына! Фото дисеңме? Ерттым мин сурәтегезне! Беркая да китмибез, малай. Туган ил бер генә була, – дип, карт машина тәрәзәсен аска шудырып, сукбайга кычкырды:

– Әй, туган, кил, утыр!

Имәнгеч кыяфәтле сукбай аларга табан борылган иде, Латыйф шунда ук маңгаендагы зур миңеннән аны танып алды...

*Июнь-август,*
*2021 ел.*

# 100 ЕЛЛЫК ӘДӘБИЯТ БАКЧАСЫ

Мин «Казан утлары» битләренә һич тә көтмәгәндә килеп эләктем бугай.

1985 елның 5-6 декабрь көннәрендә Язучылар берлегенең Бауман урамында урнашкан бинасында зур семинар узды. Аңа әзерлекне ике ай алдан ук башлаганнар, моның өчен берлек идарәсе Татарстанның төрле почмагыннан иң өметле дип саналган яшь прозаикларның әсәрләрен җыеп алган иде. «Өметлеләр» саны унике килеп чыккан, папкаларның һәркайсын берлекнең иң мөхтәрәм икешәр әдибеннән укытып тикшерткәннәр. Әүвәл аерым бүлмәләрдә «аксакаллар» бездәй «чебешләрнең» әсәрләрен «сүтте», аннары инде үзләренең «хөкем карарын» Тукай исемендәге клуб мөнбәреннән дә яңгыраттылар. «Ир канаты» дигән повесть белән ун хикәядән торган папкамны Гариф абый Ахунов белән Рашат Низами «сүтеп» аткан иде, шул семинар азагында унике автор арасыннан фәкать минем әсәрләрне генә аерым китап итеп бастырырга карар чыгардылар. Тәүге папкамдагы «Таныш тыкрык» атлы хикәя, шул ук семинар тәкъдиме белән, 1987 ел башында «Казан утлары» журналында да дөнья күрде. Менә шулай итеп, һич тә көтмәгәндә, зур әдәбият мәйданына «борын тишеп» чыктым.

Ә аннары, әлбәттә, «Казан утлары» журналында басылу чире йокты. 1988 елда ук журналда «Күке», бераздан «Нәзер» повестьларым дөнья күрде. 1991 ел башында «Казан утлары» редакциясенә «Кәнәфи» атлы повесть кулъязмасын да китереп биргән идем, аны сентябрь санында бастырырга дип планга да керттеләр, мәгәр анысы белән көтелмәгән матавык килеп чыкты. Нәкъ шул 1991 елда Чаллыда «Аргамак» журналы нигезләнде, аның тәүге санын 15 октябрь – Хәтер көненә туры китереп, дөньяга чыгарырга карар иткән идек. Редактор итеп билгеләнгән Айдар Хәлим белән редакция егетләре ду китереп эзли, тик тәүге санга бирердәй «бик шәп» повесть юк бит! Айдар абый минем «Кәнәфи» повестеның эчтәлеген белә иде инде: ул Чаллыда уянган милли хәрәкәт һәм тагын да зәһәре – шәһәр халкын фенол белән агулау турында. «Синең бу әсәрең Чаллы халкын уяту өчен менә дигән, ул «Аргамак»та басылырга тиеш!» – дип, Айдар абый туктаусыз кытырдата. Түзә алмагач, «Кәнәфи»не «Казан утлары»ның инде җыелып ята торган саныннан алдым да «Аргамак»ка кайтарып бирдем. Инде утыз ел үтеп киткән булса да, һич үкенмим. «Аргамак»ның татар телендәге сынау саны – 10 мең, ә русчасы 5 мең данә булып дөнья күрде. Бер уйласаң, Чаллы төбәге өчен 15 мең тираж аз да түгел сыман, ләкин «Кәнәфи»дә тасвирланган барча вакыйга Чаллы турында бит, һәркем белә. «Аргамак»ның сынау саны ай буена кулдан-кулга йөрде, кала башлыклары мин фәкыйрегез белән кул бирешеп исәнләшүдән качты...

Гомер үтә тора, 2000 нче еллар үренә якынайгач, «Казан утлары»нда «Япон татары» дигән тарихи романым басылды. Анысының да алдагы тарихы бик гыйбрәтле булды. Халыкта әдәби әсәрдә язылган вакыйгаларны үз төбәкләрендә булган чын хәлләр белән чагыштыру, моның өчен хәтта үпкә белдерү дигән чир дә бар бит. Әгерҗе районының Дивәтирнә авылында гомер итүче мөгаллимә Рәйсә Фәррахова «Япон татары»нда сурәтләнгән вакыйгаларны үзе туып-үскән Салагыш авылындагы чынбарлык дип

кабул иткән дә, «Казан утлары» редакциясенә рәнҗеш тулы махсус хат юллаган. Аны редакциянең ул чактагы егетләре ашыга-кабалана бастырып чыгарды. Романда, асылда да, Салагыш авылында туган һәм 1919 елда яшь ярым көе әтисе Нәҗметдин кочагында әүвәл Харбинга, аннары бөтенләй Япониягә качып киткән Тәминдар агай язмышы сурәтләнә. Ул үзе соңыннан 12 ел буе Япония императорының мөселман илләре буенча ярдәмчесе булып тора, ә улы 30 елга якын Германиядәге «Мерседес» фирмасының Япониядәге филиалында генераль директор булып эшли. Татар, кайда гына яшәмәсен, барыбер самими, беркатлы бит. Тәминдар ага да 1990 елда игълан ителгән Суверенитет турындагы декларацияне «Татарстан тулы бәйсезлек яулады», дигән сыманрак кабул итә һәм туган авылы Салагышта мәчет төзү өчен 100 мең доллар күләмендә «сәдака» да юллый. Сүзсез дә аңлашыладыр: Тәминдар агай юллаган валютаны бездәге елгыр җитәкчеләр күз ачып-йомганчы урлап бетерә, хуҗасын әллә кайдагы Япониядән кайтып төшәр, дип уйлап та карамыйлар. Мәгәр Аллаһы Тәгалә бар бит. 1994 елда Япониягә барып чыккан мөфти Тәлгат Таҗетдин Тәминдар аганы туган җиренә кунакка дәшә. Япон императорының ярдәмчесе кайтасын ишеткәч, салагышныкылар яртысын – силикат кирпечтән, яртысын – балта белән юнылган бүрәнәдән мәчет әвәләргә мәҗбүр була... Тәминдар ага мондый «шедеврны» бәяләми калмый: улы җитәкләгән «Мерседес» филиалыннан Татарстан мәчетләрен яңарту өчен бүленә башлаган ике миллион доллар... Төркия мөфтиятенә юл ала...

Туфан ага Миңнуллин белән Разил Вәлиев Япониягә кунакка барыр алдыннан миннән «Япон татары» китабын махсус соратып алды. Токиода Тәминдар абый янына да кергәннәр һәм китапны бүләк иткәннәр. Китешли янә хәлен белергә кергәч, Тәминдар ага тик бер сорау биргән: «Бу егет минем биографияне нечкәлекләренә чаклы каян белә икән?..»

Аллаһка шөкер, ике томлы «Утлы дала» да, «Казан дастаны», «Сөләйман солтан» атлы тарихи романнарым да «Казан утлары» журналында дөнья күрде. «Казан дастаны» – Казан каласы нигезләнүнең 1000 еллыгына багышланган. Кульязма белән танышып чыккач, редакциядәге Камил Кәримов биргән киңәшне дә тыңладым. «Без үзебез дә, ерак бабаларыбыз да йортларны бер үк төрле – кулга балта тотып салганнар бит инде. Казан нигезләнү турында сүз бар, ә менә бабаларыбызның кулларына балта тотып, маңгай тирләрен сөртә-сөртә көч куюлары турында эпизодлар җитми», дигәч, аерым бүлек өстәдем, каләмдәшкә рәхмәт!..

«Казан утлары» журналы үзенең 100 еллык юбилеен бәйрәм итә. Ул минем өчен дә бәйрәм. Каләмем тутыкмаган, Ходай ярдәменнән ташламаса, газиз журналыбыз битләрендә янә минем дә романнарым дөнья күрер әле.

**Вахит ИМАМОВ**

# ТАТАР УТЛАРЫ

Милләт нигезендә һәрчак берничә асыл таш була. «Казан утлары» журналы шуларның берсе дип исәплим. Хәер, аны журнал дип атыйсы да килми, һәр саны затлы Китап аның! Менә бер гасыр буена татар укучысы ай саен үз телендә яңа китап укып сөенә. Бу пафос түгел, бу – реаль чынбарлык.

Укучы буларак әйткән дә юк, язучы сыйфатында шәхсән әлеге басма минем иҗат тормышында искиткеч зур роль уйнады һәм әле дә ул каләм иясе өчен кадерле мөнбәр. Як-ягыбызга әйләнеп карыйк. Башкалар белән чагыштырыйк: 140 миллионлы урыс телле укучысы бүген үзенең «Новый мир» кебек журналларын укымый. Аларның тиражы юк, алар үлә, бетә! Соң... алар бит юктан түгел, укучысы булмаганга бетә түгелме соң?! Уйлап карасаң, коточкыч хәл ләбаса бу! Ә татар укый. Татар гомере буе белемгә омтыла, татар гомере буе әдәбияты ярдәмендә үзенең рухиятен баетып, сафландырып тора, моңа затлы «Казан утлары» – төп шаһит!

Минем беренче хикәям ошбу журналда дөнья күрде. Басмаханә оештырган бәйгедә «Кичү» хикәясе призлы урын алган иде әле ул чакта яшь язучы дип исәпләнгән авторның.

Исемле язучылар яшьләргә хәер-фатихасын да әлеге журнал битләрендә бирде. Шәхсән, үзем өчен А.Гыйләҗев, М.Хәсәновтан алган матур сүзләр аеруча кадерле булды. Туксанынчы болгавыр еллар бит: күңел төшенке. Әдәбиятның гына түгел, илнең, милләтнең дә киләчәге юк кебек. Ләкин шул вакытта журнал безгә күңелне төшерергә ирек бирмәде, бүгенге кебек төрле бәйгеләр оештырып, үсендереп торды.

Сүзем буш булмасын. Алда әйткән фикерләрне мисаллар белән дә дәлиллисе килә. Заманында, «Белая газета» дигән медицина басмасы нәшер иткән чакта, табиблар белән еш аралашырга туры килде. «Медицина»ның урысча сөйләшкәне һәркемгә мәгълүм. Шулай берчак «марҗа» табиб белән очрашкан чакта, теге әйтеп куймасынмы: «Гарасат» романыңны укыдым, ди. Күзләр маңгайга менә язды! Үзе табиб. Үзе яшь ханым, үзе рус телендә сөйләшә. «Кайдан?» – дип сорыйм моннан аптырап. Баксаң, «Казан утлары»н укый икән! Шул чакта, үземнән бигрәк, мәртәбәле басма өчен сөенгәнемне күрсәгез икән!

Тагын бер искиткеч матур хатирә. Без мәктәпкә өч чакрым араны күрше авылга йөреп укыдык. Әле дә яхшы хәтерлим, юлда еш кына яңа укыган әсәрләр хакында сөйләшкән чаклар да булгалый иде. Хәзер уйлыйм: мәктәп елларында ук «Казан утлары»н укып барганбыз икән! Югыйсә яшүсмерләр өчен башка басмалар да нәшер ителә. Юк, юлда кайтканда нәкъ менә әдәби журналда танышкан әсәрләр хакында сүз куерып китә торган иде.

Тагын бар әле күңелдә берегеп калган хәлләр. Авыл халкы, гади халык, фермаларда, басуларда хезмәт куйган кешеләр дә укый иде безнең авылда «Казан утлары»н. Бервакыт М.Мәһдиев әсәрләре нигезендә авыл клубында китап укучылар җыены булганлыгын хәтерлим.

Татар бәхете, аның яшәеш рәвеше һәрчак көрәш икәнлеген яхшы беләбез. Әлеге көрәш гыйлем эстәү, әдәби әсәрләр ярдәмендә җанны сафландыру белән гел бергә бара. «Казан утлары» татар хәятендәге сүнмәс ут ул дияр идем.

**Зиннур ХӨСНИЯР**

# *«Казан утлары» архивыннан*



*Г.Тукайның 100 еллыгы бәйрәмендә катнашучылар Арча районы, Яңа Кырлай авылындагы Г.Тукай музей-комплексында. 1986 ел.*



*Язучылар (сулдан уңга): Мәдинә Маликова, Кояш Тимбикова, Фәрваз Миңнуллин, Рафаэль Мостафин, Илдар Юзеев, Абдулла Сәлахетдинов, Әхәт Гаффар. Алда – Рәшит Гәрәй (сулда) белән Барлас Камалов. Узган гасырның 70нче еллары.*




*Татар җәмәгатьчелеге вәкилләре Гаяз Исхакый каберен зиярәт кыла.*
*Төркия, Әдернә Капы зираты. 1994 ел, июнь.*




*Миргазиян Юныс.*



*Сулдан уңга: Гәрәй Рәхим, Илдар Юзеев, Рөстәм Мингалим.*



*«Казан утлары» хезмәткәрләренең һәм авторларының төрек язучысы Яхья Акынгөн белән очрашу истәлеге. 1991 ел.*



*Каләмдәшләр (уңнан сулга): Равил Фәйзуллин, Айдар Хәлим, Гәрәй Рәхим, Марсель Галиев. 2013 ел.*



*Татар ПЕН-үзәгенең бер җыелышы «Казан утлары» редакциясендә үтте. 2003 ел.*



*Рабит Батулла (уңда) белән Галимҗан Гыйльманов.*



*Язучылар, әдәбият галимнәре Тәлгат Галиуллин (уңда) белән Фоат Галимуллин. 2004 ел.*



*Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов Санкт-Петербург шәһәрендә Габдулла Тукай һәйкәле янында һәйкәлнең авторы Әхнәф Зыякаев белән. 27 апрель, 2008 ел.*



*«Казан утлары»ның бүгенге коллективы Тукай музеенда. 2022 ел.*

## Рәмис Аймәт

### Мин әле тумаган

Мин әле тумаган, мин әле
Үрелеп бакмаган дөньяга.
Мин әле Мәңгелек иренендә
Бөрегә төйнәлгән бер Дога.

Мин әле тумаган, әмма мин
Карында кайнаган бер Дәвам.
Кайдадыр җил булып исәм дә
Кайдадыр кар булып мин явам.

Мин әле тумаган, ишетәмсез
Җанымда галәмнең гүләвен?
...Дулкыннар ияртеп киткәндер
Тибрәтеп минем ак биләвем.

Мин әле тумаган, ә инде,
Ә инде... арылган яшәп тә.
Ничә кат туамдыр? Язмышым
Күгендә гел тимер рәшәткә.

Бу дөнья – гарасат мәйданы,
Әллә соң яшәү дә – бер җәза?!
...Мин әле тумаган, ә инде
Күкләрдә укыйлар җеназа.

*«Казан утлары». 2002 ел, 1нче сан.*

## Марат Кәбиров

### Сәер мизгел

Әллә нинди сәер мизгел бу,
Аңлый торган мизгел түгел бу.
Сәер мизгел хуҗа дөньяга –
Әллә яңгыр, әллә кар ява.

Әллә көлә, әллә елый ул,
Әллә йоклый, әллә уяна...
Сәер мизгел хуҗа дөньяга –
Әллә яңгыр, әллә кар ява.

Әллә нинди сәер мизгел бу,
Аңлый торган мизгел түгел бу.
Әллә нинди халәт җанда да –
Әллә яңгыр, әллә кар ява.

Әллә көләм, әллә елыйм мин,
Әллә йоклыйм, әллә уянам...
Сәер мизгел хуҗа җанга да –
Әллә яңгыр, әллә кар ява.

*«Казан утлары». 2020 ел, 8 нче сан.*

## Луиза Янсуар

### Сер

Төнге күктә ниндидер бер якты йолдыз
Күзен кысып уйнамакчы минем белән.

Күзләремә көлтә-көлтә нурын сибеп,
Пышылдый ул: «Серләреңне беләм. Беләм!»
Карашымны яшерәмен оялудан. Кара инде!
Уйларымны хәтта нәни йолдыз белгән.
«Яратам» дип пышылдадым эчтән генә,
Ә ишеткән бөтен Галәм!..

*«Казан утлары». 1999 ел, 3нче сан.*

# Айрат Суфиянов

***

Мизгел булсын, вакыт узды:
Ишеттеңме шуны кешем?..
Исәнләштең... Сөенечең
Бер сапламга якынайтты
Бәхилләшү көенечен...

Алдагысын кем соң белгән:
Ходай күпме гомер биргән?..
Йөрәгемдә янганда шәм,
Мин, кешеләр, сезнең белән
Исәнләшеп бәхилләшәм.

*«Казан утлары». 2005 ел, 4нче сан.*

# Ленар Шәех

## Без икебез бербөтен

Алдагы юл өзелсә дә,
Хыяллар булса төтен,
Сүндермик без, сүрелдермик
Җанда яшәү өметен.

Әгәр дә иртәгә калса
Гомерем бер чиметем,
Белеп тор: син – минем җаным,
Бәхетем һәм өметем.

Без икебез бербөтен бит,
Без икебез бербөтен.
Син минем сыеныр кыям,
Ә мин синең бөркетең.

*«Казан утлары». 2006 ел, 5нче сан.*

# Йолдыз Миңнуллина

***

Синең тәрәзәләр күккә карый,
иркә сабый булып, ярым үпкә белән – күккә...
Шыгыр-шыгыр кыргый шәһәр чаганнарын,
шул чаганда көздән калган таган барын
син белмисең.
Таган тактасына гыйнвар кары хәбәр ташый
синең хакта.

Тәрәзәңә сеңгән бармак эзең октавалар буйлап
каттан катка
ашыга-оча...
Оча бирсен әйдә.
Исем китми генә
Тәрәзәләр саныйм астан өскә –
дүрткә кадәр...

*«Казан утлары». 2006 ел, 11нче сан.*

## Гөлүсә Батталова

### Гафу итмәс тарих

Дары исе сеңгән җилләр аша
Хәтер төпкелләрен урадым.
Без кардәшләр түгел идекме соң,
Төне буе буран дулады.

Бүрәнәләр авыр шыгырдады,
Айга карап, этләр улады.
Инде дуслар дошманмыни хәзер,
Төне буе буран дулады...

Йорты, курасында сыену тапкан
Мөһаҗирләр рухын уйладым.
Якын ара кинәт ерагайды –
Төне буе буран дулады...

Фал ачканмы әллә Исхакыйлар –
Инкыйразны күптән юрады.
Үз илендә һаман үги шул без,
Төне буе буран дулады...

Хаталарны гафу итмәс тарих –
Дары исле җилләр елады.
Канга баткан кансыз уен бара.
Төне буе буран дулады...

*«Казан утлары». 2016 ел, 5нче сан.*

## Рүзәл Мөхәммәтшин

### Ярымай

Минем өмет. Минем сагыш. Каргыш...
Югалтылган хакның бер ташы.
Җилдә уйнап өзгәләнгән байрак,
Һәм кемнеңдер үчле карашы.
Меңнәр-меңнәр башын күтәрәчәк...
Тик әлегә бары кош кебек,
Күкрәгемне ертып чыгар өчен,
Йөрәк кенә тибә интегеп.
Безнең күктә ак ярымай яна:
Татар буылганда төтендә,
Ул – соң өмет безнең бу төндә...
Хәтере юк милләт – киләчәксез...
Әмма хәтер белән күз килде,
Меңләп-меңләп башын күтәргәннәр
Меңләп-меңләп янә баш иде.
Һәм югалды кыйбла, ятим милләт
Мәңгегә ваз кичте барсыннан.
Йөрәк кенә тибә хакыйкатьнең
Югалтылган ташы астыннан.
Безнең күктә ак ярымай яна:
Татар буылганда төтендә,
Ул – соң өмет безнең бу төндә...

*«Казан утлары». 2008 ел, 9нчы сан.*

## Рифат Сәлах

### Каләм-чакматаш

Кулларымда нәни каләм – чакма ташы,
Салкын җилләр исеп сүнә шәм.
Берьялгызым аяз күккә карап,
Мин йолдызлар белән сөйләшәм.
Әй йолдызлар, әйдә, җырлыйк әле,
Әйдә, биик әле бергәләп.

Бөтен хисләремне шигырь итеп,
Мин таратам сезгә, бүлгәләп.
Утсыз чакма ташы күккә гашыйк,
Әнә күктә Йолдыз атыла.
...Шигырь ага җиргә йолдызлардан,
Ә алдымда кәгазь ак кына.

*«Казан утлары». 2006 ел, 7нче сан.*

## Булат Ибраһим

***

Нигә салкын бүген кояш нуры?
Ник сусауны басмый чишмә суы?
Наздан бүген никтер күңел ярсый,
Җәйдән тәнем тынычлыкны тапмый.
Берүзем мин, ләкин ялгыз түгел,
Гөл-чәчәктән генә тормый безнең гомер.
Тынычлыкны эзләп узып бара еллар,
Тик башларда һаман җилле уйлар.
Яуган яңгыр юешләтми тәнне,
Авыз сизми ризыктагы тәмне.

Тизләнәбез, куган булып дөнья,
Тик табабыз нәни генә оя.
Никтер чайкалабыз без җилләрдә,
Ни соң җитми безгә бу җирләрдә?
Күрәзәче тик юрасын киләчәкне,
Тик аңламас ул тиле йөрәкне.
Күтәрелгән тузан кире төшми юлга,
Унга дигән юллар каерыла сулга.
Төче дигән сулар тозлыланган,
Әллә кеше, әллә дөнья соң бозылган?

*«Казан утлары». 2009 ел, 7нче сан.*

## Фәнил Гыйләҗев

***

Ничә гасыр ярларына тулып
Сабыр гына аккан Казансу
Кечерәеп калган, суы кимеп.
Чикләре тар! Бик тар! Ямансу!!!
Чуерланган кирмән ташын юып,
Төпкеленә серен сеңдергән
Тарихыбыз ачылсынга дипме,
Казансуның суы кимегән?!
Яманнарын гына язма, Хода!
Иркенлек соң кемнәр кулында?!

...Хәтта елга яры кысанайган,
Кимсетелгән кирмән буенда.
Яр буенда уйга батып йөрим:
Казансуның төбе күренә...
Тар үзәнле халык түгел лә без,
Болай булу тиеш түгел лә!
Мин ышанам – кайтыр әле язлар!
Үзәннәр бит әле кипмәгән:
Ярлары бер тулыр, ташкын булыр,
Җимерелер дамба-киртәләр...

*«Казан утлары». 2011 ел, 2нче сан.*

Айгөл
Әхмәтгалиева

## КАЙТАВАЗ

хикәя

Каяндыр ишетелер-ишетелмәс кенә моң агыла иде. Урал тауның ташлы итәгендәге мәгърур кыяфәтле сылу каеннар шавында идеме ул, әллә инде тау күкрәген ярып, кылтык кызлар тавышы белән челтерәгән инеш агышында идеме – ничек кенә булмасын, колакны иркәләгән әлеге моң таң калырлык иде.

– И Ходай Тәгаләнең кодрәте! Җирдәге оҗмахтыр бу, балалар. – Ана, машинадан төшкән шәйгә, аякларының авыртуын да онытып, тирә-яктагы илаһи матурлыкка текәлде. Үзе гомер бакый кыр-дала ягында яшәп, күккә ашкан тауларны, таш өстендә бии-бии аккан инешләрне тәүге тапкыр күргәч, сокланудан телсез калды. Яфракларын җәйге җилдә җилпәзә урынына лепердәтеп, иркәләнеп серләшә-серләшә болытларга үрләгән агачлардан карашын аермый гына, берара билен уып торды. Чал чәчләрем күренмәсен әле дигәндәй, ак яулыгын маңгаена ук төшереп, кысып бәйләде, камзулын төймәләде.

Кияве белән кызы исә җыелма өстәл белән урындыкларны җиргә куеп, табын әзерләү хәстәренә керештеләр. Аларга ни, бу якларга беренче тапкыр гына килүләре түгел шул, тау түбәсенә карап, авыз ачып тормаслар.

– Әнкәй, әйдә, тау елгасына төшеп, юынып меник тә чәйләп алырбыз. Әлләни озакламабыз, ят җирдә кем килеп чыкмас…

Ана, кызының сүзен җөпләп:

– Шулай, балам, юл кешесенең юлда булуы хәерле, – дип өстәп куйды.

– Ашыкма, иркенләп ял ит, әби, – диде кияү кеше, кечкенә өстәлгә кыяр-помидор, кыздырылган тавык, пәрәмәч ише ризык тезә-тезә. – Әле күлгә барып җиткәнче, күз күгәрер. Рәхәтләнеп аякларыңны язып ал, кузгалырга җитешербез.

Соңгы елларда ананың аяклары сызлап интектерә иде, шуңа да кияве белән кызы үзләре йөрергә яраткан тозлы күлгә алып барырга күндерде аны. Карчыкны юл ераклыгы, ару-талу куркытмады, мәчесен, тавык-чебешләрен сылтау итеп киреләнде. Янәсе, күрше-күләннең генә күз-колагы җитешмәс. Дөресен әйткәндә, балаларына артык мәшәкать тудырасы килмәгән иде, олы кешенең олыларча, яшьләрнеке яшьләрчә дигәндәй… Шулай да, ай-ваена карамыйча, тәки үзләренекен иттеләр: кияве машинаның арткы утыргычына йомшак мендәрләр түшәп, анага патшабикәләр урыны әзерләде, кызы

җәһәт-җәһәт юл төенчеге хәстәрләде, йорт-кураны күршеләргә тапшырды. Төн пәрдәсен ертып, таң нурлары шәйләнә башлаган сәгатьтә юлга да кузгалдылар. «Мине кадерләгән кебек, үз балаларыгыз сезне кадерләсен» – ананың юл догасына изге теләк-фатихасы кушылды.

Ана һәм кыз гөлҗимеш куаклары белән каймаланган сукмактан җитәкләшеп су буена төштеләр. Дуамалланып, ярсып аккан елганың боздай салкын суында бит-кулларын югач, арыган тәннәренә мизгел эчендә көч, сихәт өстәлгәндәй булды, ананың ирен читендәге буразналарына якты елмаю эленде.

– И Ходайның хикмәте! – Аның соклануы, сөенүе, рәхмәте шушы сүзләргә сыйган иде.

Кызы эндәшмәде. Кайнап торган елгага карагач, авылның язгы ташуда кодрәтле дәрьяга әверелгән, җәйләрен чыпчык тезеннән генә булган нәни инеше, әнкәсенең яшь, үзенең сабый чагы күзалдына килеп, кинәт кенә күңеле нечкәрде. Кул сузымы арада гына иде ул чак, керфекләргә эленгән яшь пәрдәсен бармак очы белән тирбәтеп җибәрсәң, аермачык булып, тып итеп каршыңа килеп басар кебек иде…

Яр куенына язгы ташудан боз кисәкләре, чыбык-чабык, салам чүпләре сыенып калган. Авыл башындагы әлле-мәлле агач күперне, һәр елдагыча, ташу үзе белән алып киткән; аргы якка чыгыйм дисәң, үз кыюлыгыңа чытырдатып ябышырга һәм өстенә кадәр су менеп җиткән торба-басма аша тәвәккәлләргә генә кала. Кардан арчылып кына килгән бакчаның капкасы ачык калганмы, ишегалдыннан чыгып тайганмы – бүген-иртәгә бәрәнлисе олы сарыклары ниндидер могҗиза белән аръякка ук килеп чыккан иде. Хикмәт димә инде, шунда бәрәнләп тә куйган җитмәсә. Кемдер күреп, хәбәр итүгә, әнисе зур кунычлы резин итекләрен киеп, өйдән чыгып та чапты. Сабыйлыгы беләнме, кызык күрергә өметләнепме, кыз да аның артыннан иярде. Әнә аның әнисе, ашыга-кабалана инеш буена йөгерә. Шундый яшь, житез, чәчләрендә көмеш бәсләрнең эзе дә юк әле. Аръяктагы сарыкның бертуктамый ачыргаланып мәэлдәве, күз күреп ияләнгән бер карышлык инешнең олы дәрьяга әйләнүе, әнкәсенең басма башында икеләнеп, чарасызлыктан кулын угалап торуы сәбәп булдымы – кызның күңеленә кинәт кенә шом йөгерде. Басма дисәң хәтере калырлык бу торбага аяк басса, әнкәсе таеп китәр дә каралып күренгән әлеге төпсез дәрья аны мәңгелеккә йотар кебек тоелды кызга. Кисәк кенә чәч төпләре тирләп чыкты, аркасына исә салкын йөгерде.

– Әнкәй! – Кызның ачы тавышы инеш буен яңгыратты. – Мин куркам, теге якка чыга күрмә!

– Бәрәне җәл бит, балам, апчыкмасак, өшеп үлә бит нарасый. Ходайга тапшырып, чыгып карыйм.

Бу ярда күзләрен чытырдатып йомган кыз секундларның, минутларның никадәр озын икәнен шул мәлдә аңлады… Әнкәсе яңа туган бәрәнне пәлтә изүенә тыгып, теге ярдан басмага атлыйм дигәндә, янә бер үлеп терелде.

Баласыннан аералар дип коты очкандыр, әлегәчә ярда арлы-бирле йөренгән сарык кинәт кенә җан-фәрман су буена атылды.

– Әй бу инәйләр… Бала дип бозлы суларга төшәргә дә әзер шул… – Әнкәсе, бәрәнне күкрәгенә кыскан килеш, көйле тавыш белән сарыкка

эндәште. – Төч-төч-төч, кил әле, җанкаем, көтеп кенә тор менә шушында, сине дә чыгып алырмын. Язгы суларга төшеп әрәм буласың киләмени, бәрәнеңне ятим калдырып…

Малда да адәм акыллары бар диярсең: сарык бертуктамый кычкырса кычкырды, үзе басма башыннан кузгалмады.

Әнкәсендә куш йөрәк микәнни соң – башта бәрәнне чыгарып, кызның куенына сыендырды, аннан, каяндыр килгән көч белән сарыкны ябык иңнәренә салып, тагын басмага аяк басты.

Әнкәсе белән ике арада, күп булса, ун-унбиш адым яткандыр. Ул араның чакрымнардан күпкә озын һәм карышлардан күпкә кыска икәнен кыз соңрак, үсә-үсә аңлаячак. Әлегә – якынаймый тилмерткән ике яр арасы. Әнкәсенең суга карамаска тырышып, аягын шуыштыра-шуыштыра ипләп кенә атлавы, җилкәдәге сарыкның тыпырчынып куюы, бу икәүне үз кочагына алырга теләгәндәй, инеш суының гөрелдәп агуы кызның котын очырды. Баягы кебек күзен йомып утырса, әнкәсе басма өстеннән юкка чыгар һәм ул шушы бәрәнне кочаклап, яр буенда гына түгел, гомумән, бөтен җиһанда берүзе калыр кебек тоелды. Кыз үз-үзен белештермичә, күзләрен шар ачып, кинәт сикереп торды да, бәрәнне җиргә яткырып, басмага таба атлады. Дөньядагы иң газиз кешесен югалтудан курку хисе өстенрәк булып чыкты – аяклары торба өстеннән бер… ике… кечкенә адым ясады.

Шул мизгелдә ул әнкәсенең куркудан күгелҗем төскә кергән күзләрен күрде, аның «Кермә!» дип ыңгырашкандай тешен кысып эндәшкәнен ишетте. Басма өстеннән тасмадай шуышкан агымга иелеп карауга, башы әйләнеп киттеме – ә дигәнче карасу ташкын аны үз кочагына алды. Калганында төш белән өн буталды. Ташудан соң тынычланырга өлгермәгән инеш-дәрья йөзендә әнкәсенең җанга якын күзләре генә чагылгандай булды…

…Елганың ике яры болытларда кушыла икән. Алай дисәң, ул болытларга нигәдер аларның өй исе, өй түсе сеңгән кебек. Ул болытларда яңа туган бәрәннең бөдрә йоны да чагылган кебек. Ул болытларга әнкәсенең: «Әй бу инәйләр… Бала дип бозлы суларга да төшәргә әзер шул» дип йомшак кына кабатлавы сарылган кебек… Кечкенә кызчыкның гелән дә зурларча итеп: «Әнкәем, газизкәем, кирәксә, мин дә синең өчен утка-суга керермен», дип, үзалдына пышылдавы да кайтаваз булып болытлар итәгенә барып бәрелә кебек…

Соңыннан, авыл халкы бу вакыйганы «үзегез генә түгел, малларыгыз да күлмәк киеп тугандыр», дип, шаяру катыш искә төшергәндә, кызның башында бер генә сорау бөтерелә иде: гаҗәп, ә ул сарык бәрәнләгәнче аръякка басмадан ничекләр чыкты икән?..

Менә хәзер, тау елгасының шомарып беткән ташлар өстеннән дулый-дулый акканын күзәткәндә кызның күңелендә әлеге сорау тагын баш калкытты: гаҗәп, ә ул сарык аръякка басмадан ничекләр чыкты икән?..

– Балам, – диде шулчак әнкәсе кызны уйларыннан бүлдереп. – Кияү аптырагандыр анда, киттеләр дә югалдылар ди торгандыр, теркелдик булмаса.

– Әнкәй, сукмакка чыгыйк та, таудан аркага кочтырып менгерермен, аякларыңа көч килмәсен.

– Инде болай да бөтен авыл халкы «кызың белән киявең кулларында гына күтәреп йөртә», дип, аһ итеп сөйли, балам. – Ананың тавышы калтырап китте, ул, бәхеттән мөлдерәмә күзләре ташып түгелә күрмәсен дигәндәй, башын югары күтәреп, бөдрә болытларга текәлде. Шул болытларга түбәләре тигән мәгърур таулар, әйтерсең, ана горурлыгы алдында баш ияргә теләде – кинәт кенә чүгеп, тәбәнәкләнеп куйды. Әле генә зекер әйтеп, шаулашып утырган агач яфраклары да, «бәхеттән елыйлар микәнни» дип аптырап, бермәлгә тын калды. Хәтта тау елгасының гөрелтесе дә шул мизгелдә тукталгандай тоелды. Гүя барысы да каяндыр ишетелер-ишетелмәс кенә булып агылган, колакны иркәләгән моңга, җил канатында тибрәлгән кайтавазга мөкиббән иде.

## ЖУРНАЛНЫҢ КҮЛӘМЕ ҺӘМ ТИРАЖЫ

*«Казан утлары» баштан ук айлык, ягъни айга бер мәртәбә чыга торган журнал булып оеша. Әмма, төрле сәбәпләр аркасында, бигрәк тә баштагы елларда, бу тәртиптән читкә китүләр дә булгалаган. 1924 елда, мәсәлән, журналның 3 кенә, ә 1923 елда 9 саны гына чыгып кала. 1933 елдан алып бүгенге көнгә кадәр журнал даими төстә айга бер тапкыр чыгып килә.*

*Ярты гасыр вакыт эчендә журналның күләме өзлексез арта бара. Безнең юл» журналының беренче саны урта кул форматта, 84 бит күләмендә басыла, 5 саны исә 64 кенә бит булып чыга. «Яңалиф» журналының күләме беркайчан да 5,5 басма табактан артмый, «Атака» исә тагын да юкарак була. «Совет әдәбияты» 5 басма табак чамасында чыга башлый. Шулай да беренче елларда аның күләме еш кына үзгәргәләп тора. 4 табакка кадәр кимегән чаклары да, 6 басма табакка җиткән саннары да була. 1950 елда журнал 8 басма табак күләмендә чыга башлый. 1962 елда аның күләме 13 басма табакка җитә. Бүгенге «Казан утлары» – 16 басма табак күләмендәге, 192 битле калын журнал. Күләме ягыннан ул илебездәге иң калын әдәби журналлар белән тигезләшеп килә.*

*Журналның тиражы турында да шул ук сүзләрне сөйләргә туры килә. Баштагы елларда тираж гел тирбәлеп, үзгәреп тора. Ике, өч меңгә күтәрелгән еллар очрый, мең-мең ярымнан артмаган вакытлар күп була. Журналның тиражы Бөек Ватан сугышы елларында аеруча нык арта. 1941 елда ук тираж биш меңнән узып китә. 1944 елда 10 000 гә җитә. Шулай да үсешнең иң зур өлеше 60нчы елларга туры килә. Әле 1965 елда гына «Казан утлары» нибары 20000 данә тираж белән чыгып килә иде. 1967 елда бу сан – 57 000 гә, 1968 елда – 65 000 гә, 1969 елда – 84 000 гә, ә 1970 елда 88 000 гә җитте. Хәзер ул тираж ягыннан «Дружба народов», «Волга», «Сибирские огни», «Урал» кебек журналларны артта калдырды. «Казан утлары» журналының тиражы якын елларда 100 000 гә җитәр дип өметләнергә тулы нигез бар.*

*1972, №1*

*Шаян сәхифә*



Зөлфәт Хәким

# УЙЛАР УЙНАВЫ...

***

Ирешмәде ул бернинди дәрәҗәгә –
Тыйнак иде җанбиздергеч дәрәҗәдә.

***

Елганың берьюлы ике ярында да басып тору мөмкин түгел. Йә бер ярында, йә аръягында гына тора аласың.

***

Ике мескен очрашса, һәрвакыт өченче мескенне мыскыл итеп сөйләшерләр.

***

Иң яраткан кешеңнең кимчелекләре күренми, диләр.
Шуңа күрәдер инде кеше үзенең бик күп кимчелекләрен күрми.

***

Ачуымны ачсам, ачуланма –
Ачмый калсам, тагы да ачылана.

***

Ул үз бәхетенең бәхетсезлеккә илтүен аңламаслык дәрәҗәдә үк бәхетле иде.

***

Начар кешеләр юк. Бары тик синең күңелеңә хуш килмәүчеләр генә бар.
Яхшы кешеләр дә юк. Фәкать синең күңелеңә хуш килгәннәре генә бар.

***

Бай кешене бай булганы өчен яратмыйлар.
Ярлы кешене ярлы булганы өчен яратмыйлар.

***

Йөзгә кызыллык килер өчен дә үз йөзең булу кирәк.

***

Гел дөрес сүз сөйләүче – дөрес кеше түгел.

***

«Үз дөньясы»н булдыра алмаган язучы гына «әдәбият дөньясы» дигән төшенчәне ярата һәм еш куллана.

***

Кырык ел элек килгән хатларда мин бүген шулкадәр күп яңалык табам... Үзем турында.

***

Саргаеп беткән иске фотолардан миңа шелтә катыш кызгану белән карыйлар шикелле.

***

Үзең булып калыр өчен, үзеңне табу кирәк.

***

Сүз иреге тел ирегеннән башка була алмый.

***

Аның күңеле коточкыч киң иде...

***

Кар яуганга оныгы куанганда, бабай кар яуганга түгел, оныгы шат булганга куана.

***

Яшәүнең чын мәгънәсен тапкан кеше белән очрашырга язмасын...
Кем белгән аның мәгънәне нидә тапканын...

***

Сине берәрсе мактаганда сөенергә ашыкма.
Иң элек үзеңә сорау куй: «Ник мактый икән бу мине?..»

***

Ап-ак күлмәк кер күтәрми,
Бер каралса, пакь ителми.

***

Акны карага буявы җиңел.
Караны ак итү авыр.

***

Затлы әйбер тутыкса да кыйммәт була.
Затлы кеше картайса да әйбәт була.

Печән Базары

*Сатирик әсәрләр*

Камил
Кәримов

# МИН ДӘ БУЛДЫМ...

ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ

Язучы халкы һәр атнаның бишенче уку көнендә, җыелышка дигән булып, әдәби җомгаларга йөрергә күнегеп китте. Бүген тагын җомга. Иске матбугат йортының Г.Тукай исемендәге клубында аяк басар урын юк – шыгрым тулы шул ук тамашачылар, сәхнәдә шул ук язучылар...

Партия җыелышыннан калган президиумда Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Рафаэль Мостафин, Мәдинә Маликова, Әхмәт Рәшитов, Әхәт Гаффар һәм Марсель Галиевләр кысылышып утыра. Башларына кәләпүш кимәгәннәр, конспирацияне нык саклыйлар, чукынчыклар...

Ахшам вакыты җиткәнне белдереп, Ә.Гаффар теге мыегын сыпырып куйды. Шуны гына көткәндәй, Ә.Рәшитов сикереп торды, торды да ясин чыгарга гына яраклы тавышы белән башлап җибәрде:

– Татар халкы элек-электән йөремсәк, зимагур инде ул. Әле күптән түгел генә бер өер язучылар чит җирләрдә йөреп, андагы мөселман кардәшләребезнең хәлләрен белеп кайттылар. Иң әүвәл Мәдинә Маликованы сөйләтәсем килә. Юкса чит илдән кайтканнан бирле өйдә минем белән юньләп сөйләшкәне дә юк.

– Кая барасың килә? – дип сорадылар. – Әлбәттә, Парижга! – дидем.

Мәдинә ханым дулкынлануын тыеп торыр өчен пауза ясап алды. Бу кадәр озын тынлыктан соң, залдагы һәрбер дәрвиш Парижны күз алдына китерергә тиеш иде инде.

– Килеп төштек, Франция чип-чиста! Игеннәр бот буе! Анда барысы да мәгъшукалар гына димәгез, парижлылар – эшчән халык. Татар йокысыннан уянганчы, француз эшләп арган була инде... Культура үзәкләренә килеп кердек – мин аны ремонтта дип торам, ул үзе шундый икән. Ә халык бик тәрбияле, кая карама – төрле позада гәҗит укыйлар. Безне Моника Буби озата йөрде. Ә гомумән алганда, мин Францияне үзгәртер идем... Чат саен кызлар басып тора, ә ирләр...

Нәкъ шушы урында сөйләүчене Ә.Рәшитов бүлдерде:

– Ярар, ярар, бу турыда башкалар сөйләсен.

Әхәт Гаффар үзенә сүз бирүләрен түземсезлек белән көтә иде инде.

– Язгы ташулар күперне агызгач, авыл икегә бүленә: син бу ярда, хатының теге якта дигәндәй, нәкъ менә шулай Португалия ягында бүленеп калдым. Андагы татарлар русча шәп беләләр. Урамда эзләнеп йөргәндә, борын төбемнән генә Алвару Куньял үтеп китте. Танымады... Йөзендә татар чалымнары бар иде...

Үзенә сүз бирелгәч, Гариф Ахуновның куенына ук кереп утырган Марсель Галиев, взнос түләргә килгән Марсель Зарипов шикеллерәк ялындырып кына, күз алдына чыгып басты.

– Мин Испаниядән кайттым. – Һәм Марсель, колхоз базарыннан ары китә алмаган залдагы апаларга һәм абыйларга карап, «мескеннәр» дип пышылдап куйды. – Әхәт

зрә генә әллә кем булып сөйләнде, аның Португалиясе минем Испаниянең буш кесәсе хәтлек кенә ул... Ник Испаниягә бардың, дисәләр, әйтермен: җир читенә барып, аяк салындырып утырасым килде. Нәкъ шушы вакытта Гариф абый Африкада, Мәдинә апа Франциядә, Сибгат абый Германиядә нәрсәдер эзләп, чатыр чабып йөриләр. Чатыр дигәннән, Азнакайның Чатыр тавына менсәң, бөтен Җир шары күренә! Һәм менә мин, ниһаять, Атлантик океанның тозлы суына аякларымны тыктым... Нинди шәп ванна!..

О Мадрид!.. Өйләре шикәр кебек, яңгыр юып тора. Юллары безнеке хәтлек кенә булса да, таулары биек. Испаниянең получка алган чагы иде, халкының холкын күрдек. Бабайлары татарларга охшаган. Ә кем белә, бәлки?!. Дөресен генә әйткәндә, яраттылар алар мине, саубуллашканда, «Кам-панерра!» дип, йодрык күрсәтеп калдылар.

Ниһаять, «җәлилчеләргә» дә чират җитте.

– ГДРга мин китаплар алып кайтыр өчен барам, – дип башлады Рафаэль Мостафин, – юкса бездә матур тышлы китап табу проблема бит ул. Биш тапкыр бардым, инде өемдәге китапханәм шактый зурайды. ГДРда иң сокландырган нәрсә – немецларның төгәллеге. Җыелышка киләләр икән – нәкъ белдерүдә күрсәтелгән вакытка төгәл сыешалар. Ә безнең татар язучысын җыелышка сөйрәп тә алып килеп булмый. Килсәләр, төн уртасына хәтле таралышмыйча интектерәләр.

Безне немец язучылары университетка алып керделәр. Анда чит ил әдәбияты кафедрасында Марсель Галиевнең «Ак абагалар» исемле повестен өйрәнеп яталар иде.

Дустым Небенцаль башта ресторанга кертеп ашатты да аннан соң өенә кунакка алып барды. Өстәлендә бер сухой гына иде.

Гариф Ахуновка сүз бирелгәч, залдагыларның берсе-бер калмыйча аягүрә басты (моны союзга керәсе яшь язучылар оештырган иде). Г.Ахунов үзе дә торып басты.

– Һиндстан!.. – дип, идарә рәисе, сүзен башламас борын, туктап калды, гүя ул бүгенге хикәясен менә шушы бер сүзгә сыйдырырга тели иде. – Һиндстан... Җәмәгать, андагы күк йөзен күрсәгез икән! Төсен ни дип тә әйтергә белмим: Шаһидәмнең кофтасы төсенә Маһирә, Сафия, Гөлсинә, Мәдинә, Нурия, Рәмзия, Наилә, Дания һәм Язучылар союзында эшләүче калган хатын-кызларның кофталары төсен бергә кушсаң гына шундый төс чыгарга мөмкин! Самолёт гүя мунчага очып килеп керде. Безне кара тутлы йөзләр каршы алды, үзләренә шундый күнектем, өйгә кайткач, ак тәнле ханымнар да куркыныч булып тоелды. И-е! – дип, тамак кырып алгач, Ахунов тагын дәвам итте: – Нәрсәдә туктап калган идем әле? Ә-ә-ә, Марсель Гали әйтмешли, кесәң исән булсын! Һиндстанда миллион кеше эш эзләп йөри. Бер турист укытучы ханым, кызганып, кайсынадыр рупия биргән икән, башка хәерчеләр килеп, аны сырып алганнар һәм дә ки, күз ачып йомганчы, ханымны чишендереп тә ташлаганнар. Шуңа күрә рупиябезне кысып кына йөрдек... Йогышлы авырулары күп дигәч, Дәһли базарына кергән идек, очрамадылар. Марсель, теге авыруның исеме ничек иде әле?.. Әйе, әнә шул проказа дигәне генә калган иде.

Милли ризыкларыннан иң яратып ашаганым бака ашы булды. Тәмен белер өчен генә яшел кузакларын да капкан идем – күзем маңгаема менде. Шул килеш кайтып киттем.

Докладымны кыскартып, шуны гына әйтәсем килә: Африка! Кырык яшьлек кара хатын баш өстенә кырык килолы йөк күтәргән...

* * *

Ә Сибгат ага Хәкимгә, гадәттәгечә, вакыт калмады. Тамашачылар таралып беткәч, ул әкрен генә президиумнан төште.

– Мин дә булдым, – диде ул, җиң очыннан яртылаш чыккан уч төбен буш залга селтәп...

*1981 ел, 13 гыйнвар.*

Зөлфәт

# ЯШӘР БЕЗНЕҢ ЖУРНАЛЫБЫЗ

Ил язмышын, тел язмышын
Калмый бары көйләп-сөйләп –
Шул язмышның булды үзе
Безнең газиз әдәбият!

Үткәннәрдән киләчәккә
Җиңел түгел юлларыбыз...
Шул юлларда кәрван башы
Һаман – олуг журналыбыз!

Булды һәрчак әдәби сүз
Халкыбызның таянычы.
Ул – аның наз каләме дә...
Һәм ялт иткән шам кылычы!

Гасырлардан гасырларга
Исән-имин күчәр өчен,
Заманнарның давылларын,
Упкыннарын кичәр өчен

Безнең барлык ышанычны,
Өметләрне бара төяп,
Халкыбызның җан аклыгы
Һәм ныклыгы – әдәбият.

Нинди генә булсалар да
Киләчәккә юлларыбыз,
Исән безнең кәрван башы, –
Яшәр газиз журналыбыз!

*2006 ел*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Поздравления от Президента РТ Р.МИННИХАНОВА, Государственного Советника РТ М.ШАЙМИЕВА, Председателя Государственного Совета РТ Ф. МУХАМЕТШИНА, Председателя Союза Писателей РТ Р.ЗАЙДУЛЛЫ, Руководителя Республиканского агенства по печати и массовым коммуникациям А. САЛИМГАРАЕВА, генерального директора АО «ТАТМЕДИА» Ш.САДЫКОВА.*
*Слово главного редактора Р.ГАЛИУЛЛИНА.*
*«Проза»: рассказ Ф. АМИРХАНА «Несите мне цветы!», рассказ Ш.КАМАЛА «Звуки курая», отрывок из повести Г.КУТУЯ «Неотосланные письма», расссказ А.ЕНИКИ «Кто пел?», отрывок из повести М.МАГДИЕВА «Прощание», отрывок из романа А.ГИЛЯЗОВА «Давайте, помолимся!», сатирический рассказ Н.ФАТТАХА «Критик», эссе М.ГАЛИЕВА, рассказ А.ГАФФАРА «Пугалы», рассказ Ф.БАЙРАМОВОЙ «Цветок сирени», рассказ Н.ГИМАТДИНОВОЙ «Предатель», рассказ А.АХМАТГАЛИЕВОЙ «Эхо».*
*«Поэзия»: стихи выдающихся татарских поэтов.*
*«Публицистика»: статья Г.ИСХАКИ, статья Р.ЮНУСА.*
*«История»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Литературная критика»: статья Г.ИБРАГИМОВА.*
*«В письмах – мудрость старейшин»: письма из архива Р.ГАТАША.*
*«Память»: воспоминания А.ШАМОВА, Г.БАШИРА, Г.КАШШАФ, Ф.ХУСНИ, А.ЕНИКИ, Г.АБСАЛЯМОВА, З.НУРИ, А.РАСИХА, Г.АХУНОВА, И.ЮЗЕЕВА, А.ГИЛЯЗОВА, Р.ФАЙЗУЛЛИНА.*
*«Искусство»: Т.МИННУЛИН. «Старик из Альдермеша».*
*«Казан утлары» – в моей судьбе»: статьи В.ИМАМОВА, З.ХУСНИЯРА.*
*«Юмор и сатира»: афоризмы З.ХАКИМА.*
*«Сенной базар»: юмористический рассказ К.КАРИМОВА.*
*Стихотворение ЗУЛЬФАТА «Наш журнал будет жить!».*
*Из фотоархива журнала.*
*На наших обложках: Огни Казани. Фото А.Евстигнеева;*
*коллектив редакции журнала «Казан утлары». 2022 год. Фото А.Арахамия.*

## IN THIS ISSUE:

*Congratulations from the President of the Republic of Tatarstan R.MINNIKHANOV, the State Councilor of the Republic of Tatarstan M.SHAYMIEV, the Chairman of the State Council of the Republic of Tatarstan F.MUHAMETSHIN, the Chairman of the Union of Writers of the Republic of Tatarstan R.ZAYDULLA, the Head of the Republican Agency for Press and Mass Communications A.SALIMGARAEV, the General Director of JSC «TATMEDIA» Sh.SADIKOV.*
*The word of the editor-in-chief R.GALIULLIN.*
*«Prose»: story by F.AMIRKHAN «Bring me flowers!», story by Sh.KAMALA «Sounds of the Kurai», passage from story by G.KUTUY «Untransmitted Letters», story by A.ENIKI «Who Sang?», passage from story by M. MAGDIEV «Farewell», passage from the novel by A.GILYAZOV «Let's pray!», satirical story by N.FATTAH «The Critic», essay by M.GALIEVA, story by A.GAFFAR «Scarecrows», story by F.BAYRAMOVA «Lilac flower», story N.GIMATDINOVA «Traitor», story by A.AKHNETGALIEVA «Echo».*
*«Poetry»: poems of outstanding Tatar poets.*
*«Publicism»: article by G.ISHAKI, article by R.YUNUS.*
*«History»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Literary criticism»: article by G.IBRAGIMOV.*
*«In letters - the wisdom of the elders»: letters from the archive of R.GATASH.*
*«Memory»: memories of A.SHAMOV, G.BASHIR, G.KASHSHAF, F.KHUSNI, A.ENIKI, G.ABSALYAMOV, Z.NURI, A.RASIKH, G.AKHUNOV, I.YUZEEV, A.GILYAZOV, R .FAYZULLIN.*
*«Art»: T.MINNULIN. «The Old Man of Aldermesh».*
*«Kazan utlary» is in my destiny»: articles by V.IMAMOV, Z.KHUSNIYAR.*
*«Humor and satire»: aphorisms of Z.KHAKIM.*
*«Hay Bazaar»: humorous story by K.KARIMOV.*
*Poem ZULFAT «Our magazine will live!»*
*From the photo archive of the magazine.*
*On our covers: Lights of Kazan. Photo by A.Evstigneev;*
*the team of the editorial staff of the magazine «Kazan Utlary» 2022. Photo by A.Arahamia.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан утлары. *А.Евстигнеев фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* «Казан утлары» журналы редакциясе коллективы. *А.Арахамия фотосы.*